Р. Фәхретдинов

КИЧКЕ АЗАН

Р. Фәхретдинов
КИЧКЕ АЗАН

ТКН...ТКИ

R. Фәхретдинов

КИЧКЕ АЗАН

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1997

ББК 84(Р — Тат.) — 4
Ф 97

Фәхретдинов Р.

Ф 97 Кичке азан.— Казан: Татар. кит. нәшр. 1997.— 223 бит.
ISBN 5 — 298 — 00654—X

Бу җыентыкка автор халкыбызның тарихына, матди вә рухи мәдәниятенә багышлап язган очерк, мәкалә, уйлануларын туплады. Китапта җөмһүриятебезнең иҗтимагый-сәяси тормышындагы зур үзгәрешләр дә, яңа карашларның юл яруы да гаять киң чагыла.

Ф $\frac{4702560204 - 019}{М 132(03) - 97}$ 127 — 95 ББК 84(Р — Тат.) — 4

ISBN 5 — 298 — 00654 — X © Татарстан китап нәшрияты, 1997

I. МӘДӘНИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ

Балтачның Габдерәуф мулла һәм Мортаза бай истәлегенә багышлыйм.

Автор

КИЧКЕ АЗАН[1]

(Балтачта мәчет ачылганда яңарган хатирәләр)

Кичке азан!
Кичке азан!
Моңнар, уйлар
Килә аннан;
Төшә искә
Иске әзман...[2]

Г. Тукай

Шушы 1994 елның 12 гыйнварында Балтачта, район үзәгендә мәчет ачылды. Ак һәм кызыл кирпечләрне чиратлаштырып, сәнгать-архитектура теле белән әйткәндә, полихромия ысулын, ягъни төсләр бизәклегән оста файдаланып эшләнгән, монументаль архитектураның менә дигән истәлеге!

Биек манарасы белән бергә мәһабәт тышкы кыяфәте һәм эчке эшләнеше ягыннан бер Балтач төбәгендә генә түгел, ә бөтен татар җирендә диярлек соңгы елларда салынган мәчетләргә үрнәк мәчет. Зурлыгы ягыннан Чаллының «Тәүбә» мәчетеннән генә калышадыр. Сызым-үлчәмнәрен эшләгән һәм, гомумән, төзелеш эшләрен җитәкләгән Ш. Гәрәевкә, төзүчеләргә, булдыра алганча хәләл акчаларын шул изге эшкә биргән балтачлыларга, төрле спонсорларга һәм, әлбәттә, район хакимият башлыгы М. Әхмәтовка, аның ярдәмчеләренә дан вә шөһрәт!

Балтачта зур бәйрәм булды, һәм андый бәйрәмне бу олы авыл күптән күрмәгәндер. Борынгы Болгарда ислам дине кабул итүнең 1100 еллыгын бәйрәм итү бөтен Татарстан өчен нинди зур тантана булган булса, Балтачта мәчет ачу да безнең өчен шундый ук тантана, шундый ук шатлык ул, диде минем авылдашым Вагыйз абый. Хак сүзләр!

---

[1] Бу язманың зур бер өлеше «Ватаным Татарстан» гәзитендә басылды. 1994, 4—5 февраль.

[2] Әзман — заманнар.



Балтач районы Балтач авылы мәчете
Автор фотосы, 1996 ел

Соңгы мәчет манарасын кисеп ташлап, яше сиксәнгә җитеп килүче мулласын карчыгы һәм алты баласы белән җылы өеннән куып чыгарып, җир идәнле ярым подвалда яшәргә мәҗбүр иткәннән соң узган 60 елга якын гомер эчендә нинди иман күрде Балтач? Шул узган вакытта «дин халыкка агу ул» дип бастырып куйган атеистик бастырыкны үз җилкәсендә татып, ике буын алышынды. Инде өченче буын да шуны ук күтәргән булса, болай да ярты мыскалга калган иманыбыздан һәм, менә сүнәм, менә сүнәм, дип торган милли горурлыгыбыздан нәрсә генә калган булыр иде икән?

Һәр явызлыкның бер чиге була шул, һәм менә җир шарының алтыдан бер өлешен ГУЛАГ лагерьларына әйләндереп, ә безнең татарның 12 мең мәчетен ябып-җимереп, меңнәрчә вә ун меңнәрчә муллаларын, байларын, халыкның интеллектуаль көче булган чын зыялыларын туган-үскән җирләреннән куып, Себер тайгаларында череткән большевизм, ул тудырган җүнсез система да җимерелде. Әкренләп булса да, яңа, «демократик» шовинизмга каршы көрәшеп, халкыбыз 70 елга сузылган йокыдан соң кабат уяна башлады. Балтачка да иртәнге һәм кичке азан кайтты, намаз кайтты, кабат изге Коръән сүзе керде.

Авылның кышкы салкын киче. Ап-аяз күктәге җемелдәгән йолдызларга карап капка төбендә басып торганда, күңелләрне әйтеп бирә алмаслык дәрәҗәдә тибрәндереп, мәчет манарасыннан кичке азан яңгырады, һәм моннан 50 еллар элек булган бер вакыйгага искә килеп төште.

1. Габдерәүф хәзрәт. Муллалар тарихы

Сугыш вакыты, әмма елын төгәл хәтерләмим. Җәй көне иде. Әни мине җитәкләп мулла абзыйларга алып

барды. Мулла абзыйлар дигәнем — Балтачның түбән оч мәчетенең мулласы Габдерәуф хәзрәт белән аның җәмәгате Фатыйма абыстай. Алар — минем әнинең әүвәлге каенатасы белән каенанасы, ягъни аның иртә үлгән беренче иренең әти-әнисе (әнинең икенче ире, ягъни минем әти, 86 яшен тутырып дөнья куйган Габдрахман да муллалар нәселеннән, үзе агач эше остасы гына булса да, бабасының бабасы Габделмоталлаб Балтач мулласы булган, бу XVIII йөз ахырларына туры килә). Әнием Нәгыймә мин аны белгәннән бирле тазалыкка туймады, әмма әҗәл җитеп урын өстенә менгәнче намазын калдырмады, ифрат та динле, нечкә күңелле, саф кеше, изге бер җан иде мәрхүмә. Гомере буе үзенең элек мулла килене булганлыгы белән чиксез дәрәҗәдә горурланып яшәде, шул беренче каенатасы белән каенанасын ташламады, җае туры килгән саен аларга барып, хәлләрен белеп, мөмкин булганча ярдәм итәргә тырышып йөрде.

Шулай мулла абзыйларга килеп кердек. Абыстай чәй әзерләп йөри, ә хәзрәт үзе, ап-ак түгәрәк сакаллы һәм ак йөзле кечерәк бер карт, үзе кебек үк ак йон оекбашлар киеп һәм аякларын салындырып, биек агач караватта утырып тора иде. Әни мине аның янына алып килде. Мулла абзый мине алдына утыртып: «И-и, бу бала да зур үскән икән инде»,— дип аркамнан сөйде...

Менә мин боларны язып утырам, ә үземнең тамакта төер, күзләргә яшь тыгыла, чөнки болар — ул вакыттагы нарасый баланың саф күңеленә мәңгегә, гүрләргәчә онытылмаслык булып кереп калган балачак хатирәләре. Тагын да Тукайча әйтсәк:

> И күңелнең шаулап аккан чишмәдән сафрак чагы!
> И гомернең нурланып үскән яшел яфрак чагы!

Мин бая, карчыгы һәм алты баласы белән җылы агач өеннән куып чыгарылып, җир идәнле һәм таш стеналы, ярым подвал сыман бер бүлмәдә яшәргә мәҗбүр ителгән, дип язган мулла — шушы Габдерәуф мулла була инде. Аннан башка Балтачта тагын бер мулла булган — югары мәхәлләнең Сабирҗан хәзрәт. Безнең буын анысын хәтерләми, колхоз чыгып, раскулачивание башлангач, аны «бай мулла» дип сөргенгә сөргәннәр, газиз башкайлары шунда беткән[1]. Ә Габдерәуф хәзрәткә тимиләр, дөресрәге, гадел һәм кешеләргә бик тә ярдәмчел булганы өчен халык аңа кул тидерттерми, алып кала — һәрхәлдә, минем әни белән

---

[1] Монда төгәлсезлек киткән булса кирәк. Икенче бер мәгълүматлар буенча, Сабирҗан мулла Урта Азиядә үлә.

Балтач мулласы Габдерәүф хәзрәт. Паспорт фотосыннан рәссам Э. Зарипов эше

әти шулай сөйлиләр иде, шундый ук сүзләрне авылның башка картларыннан да ишеткәнем булды.

Калдыруын калдыралар, ә яшәүләре инде... Чиктән тыш авыр тормышка һәм властьлар, сәвит куштаннары тарафыннан булган кимсетелүләргә түзә алмыйча, балаларының күбесе Урта Азиягә, Ташкент якларына чыгып китәләр, үзләре исә олы кызлары, авыру кияүләре белән һәм аларның кечкенә улы белән әнә шул таш өйчектә яшәп, сугышның соңгы елларында икесе дә бер-бер артлы дөнья куялар. Җир идәнле йорт булганлыгына хәзерге буын ышанмастыр, әмма мин аны үз күзләрем белән күрдем. Шунысы гаҗәп: ул идән берәр нәрсә белән катырып куйган кебек тип-тигез, чиста итеп себерелгән иде, һич тузан һәм чүп әсәре юк. Стеналары да, миче дә ап-ак итеп акшарланган. Кайчандыр ул, бәлки, аш хәзерләү өе булып хезмәт иткәндер. Олы кызлары (аны «мулла Хәдичәсе» дип йөртәләр иде), әлеге шул тозак өйдә башта чахоткадан ире, соңыннан әти-әнисе дә үлеп китеп, яшәргә һич рәт калмагач, Балтач муллалары нәселенең соңгы вәкиле булып һәм кечкенә улын житәкләп, Урта Азиягә чыгып китә.

Менә шул Хәдичә апа әнигә озын-озын хатлар яза иде. Гади генә хатлар түгел, ә чит-ят жирләргә һич ияләнә алмыйча, туган-үскән илләрне чиксез сагынып, күңел тетрәткеч сагыш вә моң белән тулган, шигырьгә салып язылган, җан әрнеткеч хатлар. Әни аларны «җыру» дип атый иде. Хәдичә апа елап язган, әни көйләп һәм елый-елый укый... Шулар һич күңелдән китми! Минемчә, дистәләгән ул җырулар бәет һәм мөнәҗәтләр калыбына кертеп, мулла кызы тарафыннан чыгарылган чын мәгънәсендәге халык авыз иҗаты әсәрләре иде. Нә кызганыч, шул хатлар сакланмаган.

Балтачның түбән оч мәчетенең манарасы 1937—1938 елларда киселә. Аны Кенә якларыннан бер имансызга авыл советы рәисе аракы эчертеп кистергән, диләр. Әлеге адәмнең тормышы фаҗигале тәмамлана — тагын кайсы-



Анам кабере янында. Авторның авто-фотосы, 1972

дыр авыл мәчетенең манарасын кискәндә түбәдән егылып төшеп үлә. Мәчет манарасын кисүчеләрнең тормышларында бик еш кабатланган табигый, гадәти хәл бу!

Мин боларны кеше үлеменә шатланып язмыйм. Һич юк! Һәркемнең гомере анын үзенә, балаларына кадерле һәм газиз. Әмма дөньяда гыйбрәт бар — кылган начар эшләр өчен Хак тәгалә тарафыннан гадел хөкем ителгәннәрдән гыйбрәт ала белергә кирәк. Мин археолог буларак Татарстанның өчтән ике өлешен, күрше өлкә-республикаларның күп җирләрен җәяү йөреп чыктым, меңләгән археологик истәлекләрне өйрәнүдән тыш, йөзләгән авыллар аша үттем, сакланып калган мәчетләрне, зиратлардагы борынгы кабер ташларын рәсемгә төшердем, бик күп кешеләр белән очрашып сөйләштем. Һаман шул бер үк гыйбрәт: кем мәчет манарасын яки зират каенын кискән, кем кабер ташын ваттырган, зират коймасын ташып яккан, күбесе фаҗигагә очраган — үлгән, гарип калган, акылдан язган, гаиләсеннән аерылган һ. б.

Мөхтәрәм авылдашлар — балтачлар! Бер балтачлар гына түгел, хөрмәтле арчалар, әтнәләр, биектаулар, мама-

дышлар, чистайлар, әлкиләр, кайбычлар, буалар, Казан артында, Кама аръягында, Тау ягында, бөтен Татарстанда, аннан читтә яшәүче татарлар, кадерле милләттәшләр! Моннан ары тимик мәчетләргә, зират коймаларына, кабер ташларына, бүтәннәрдән дә тидертмик! Ул мәчетләрдә дистә вә йөз еллар буенча Аллаһе тәгаләнең җиргә иңдерелгән сүзләре язылган Коръән укылган, кешеләрне бары тик яхшылыкка гына өйрәтеп вәгазь сөйләнгән, ул мәчет баскычларында һәм идәннәрендә ата-бабаларыбызның аяк эзләре калган. Ул зират коймалары менә инде күпме гасырлар һәм еллар буе җир астында ятучы, әмма күңелләре безнең белән булган әти-әниләребезнең, әбибабайларыбызның газиз каберләрен саклыйлар. Ул ташлар астында туган-үскән җиребез өчен изге көрәштә җаннарын биргән каһарманнар, халкыбызның асыл затлары булган би-морзалар, бикәләр, шәехләр, муллалар, башка күп төрле изгеләр — безнең борынгы бабаларыбыз, нәсел очларыбыз ята. Алар — татарның азатлыгы өчен көрәшеп һәм шул азатлык турында хыялланып, моң-зар чигеп бу якты дөньядан киткән адәмнәр.

Бабалар кабре янында күңел зар,
Аталар рухының армандәсе[1] бар...—

дигән халкыбызның икенче бер бөек шагыйре Дәрдмәнд.

Хис-тойгылар, лирик чигенешләр, кайбер гомум сүзләр өчен кадерле укучылар мине гаеп итмәсеннәр. Туган җирдә үткәргән балачак, шуның белән бәйле булган якты хатирәләр, гыйбрәтле хәлләр, авыл тарихы — бөтен татар өчен уртак, гомуми, һәр җиргә вә һәр кешегә хас истәлекләр, гыйбрәтләр, тарихлар, хисләр болар.

Татарның башка җирләре кебек үк, Балтач ягы да күп кенә дин әһелләренә — имам-хатиб һәм мөдәррисләргә бай як. Халкыбыз тарихының соңгырак дәвере буенча турыдан-туры белгеч булмасам да, ул тарих та минем өчен бик якын, кадерле, җитмәсә, ул заманга караган кыйммәтле хезмәт һәм тарихи чыганаклар калдырган, тирән белемле, ышанычлы галимнәр бар. Зур ышану белән ышанып табынган затларымның берсе — халкыбызның олугъ тарихчысы, бөек акыл иясе Шиһабетдин Мәрҗани. Аның мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар...» исемле китабында Казан арты, Тау ягы, Оренбург Каргалысы, Троицк һәм кайбер башка төбәкләрдәге авыллар, мәчетләр, муллалар хакында бәһа биреп бетерә алмаслык мәгълүматлар, беренчел чыганаклар ята. Бөтенләй үк тулы булмаса да, тупланган кадәресе

[1] Армандәсе — теләге, өмете.

дә асылташларга тиң. Үзем ишеткән-белгәннәрдән башка, Мәрҗани китабына мөрәҗәгать итеп, Балтач ягының кайбер укымышлы затларын кыскача гына санап үтәсем килә. Болар — күбрәк узган гасырга һәм кайберләре XVIII йөзнең икенче яртысына кагылышлы муллалар, башка төрле дин әһелләре. Шулар арасында иң атаклыларыннан, мәсәлән, Кариледән — Габдессәлам бине Хәсән, Нормадан — Мөхәммәдәмин бине Мөхсин, Килидән — Сәлих бине Сәгыйдь, Түнтәрдән — Сәгыйдь бине Хәмид, Муса бине Габдерәшид (ул вакытларда муллаларның күбесе исемнәренә ялгап туган яки яшәгән җирләренә бәйле нисбиләрен дә яза торган булганнар, мәсәлән, әл-Карили, ән-Нормавый, әл-Түнтәри, әл-Кили һ. б.). «Габдессәлам хәзрәт» дип танылган Кариле мулласының әле 1768 елда шул авылда мәчет һәм мәдрәсә тотканлыгы мәгълүм, әмма соңыннан ул Минзәлә ягына күчеп китеп, шунда вафат була. Шәкертләре — заманында татарның атаклы имам-хатиб вә мөдәррисләре: Тау ягының Шырдан авылыннан (соңыннан Каюм Насыйри туган авыл) Сәгыйдь бине Әхмәд, Әлдермештән — Хәмид бине Мортаза, Әгерҗедән — Җәгъфәр бине Ягъкуб, бая телгә алынган Салих бине Сәгыйдь. Шушы Сәлих әл-Кили соңыннан Казанның икенче мәчетендә имам вә мөдәррис була. Мәрҗани раславынча, «анда зур мәдрәсә тотып, күп шәкертләрне җыйнап дәрес укыта һәм дан, шөһрәт казана». «Икенче мәчет» ул — «Казанның атаклы Мәрҗани мәчете («беренче мәчет») белән бер вакытларда, ягъни 1770 елларда, салынган һәм, шулай итеп, шәһәребезнең бүгенгә сакланып калган иң борынгы ике мәчетнең берсе, күбрәк Апанай мәчете дип



Балтач районы, Кариле авылының яңа мәчете. 1995 елда ачылды. Автор фотосы, 1995

мәгълүм; К. Насыйри урамында, әлеге Мәрҗани мәчетеннән ерак та түгел, манарасы юк, әлегә анда балалар бакчасы урнашкан. Мәдрәсәсе «Күл буе мәдрәсәсе» дип аталган, бинасы әле дә бар, мәчет турысында, Кабан күле буенда урнашкан. Бу мәдрәсә Казанда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсеннән кала икенче атаклы мәдрәсә саналган, анда татарның мөхтәрәм затлары укыган, шулар арасында күренекле дин галиме, җәдитчелек һәм, гомумән, татар милли-азатлык хәрәкәте идеологларының берсе, Петербургның мәшһүр мулласы Муса Бигиев тә бар (1949 елда Мисырда үлә).

Гомумән, XVIII—XIX йөзләрдә Балтач җирендә яшәп муллалык иткән шәхесләрнең тагын кайберләрен санап кына үтү дә укучылар өчен кызыксыз булмас дип уйлыйм. Шулардан: Ибраһим ән Нократый, 1750 елларда Хәсәншәехта (бу борынгы авыл элек-электән Балтач волостенда һәм районында иде, соңгы елларда гына Арчага кереп калды), 1770 елларда Урбарда (Арбор) имам-хатиб һәм мөдәррис, заманында гыйлемлеге белән танылган затлардан; Габделхәмид әл-Түнтәри, 1758—1805 еллар арасында Мәчкәрәдә (хәзерге Кукмара районы), Салавычта һәм Түнтәрдә, олы улы Сабит Чутай Завод авылында, ә аның бер улы Габделгаффар Яңа Тазларда һәм Түнтәрдә, икенче улы Габделфәттах 1860 елларда — Салавычта; шул ук Салавыч авылында 1820—1860 еллар арасында, ягъни Габделфәттахка кадәр,— Һибәтулла бине Динис, Сәйфулла бине Хәмид; XIX йөз башында Борнак илендә — Габделмәҗит бине Мозаффар; XIX йөзнең беренче яртысында Саснада — Сәфәр бине Исмәгыйль, Таҗетдин бине Габдерәшид; шул ук елларда Арбашта һәм Кариледә — Габид бине Габделгазиз; 1850 елларда Янгулда — Таҗетдин бине Габделсаттар; 1870 елларда Нормада — Габделвәли бине Габдерәхим; шул ук елларда Кариледә — Таҗетдин бине Габделҗәмил.

Балтач ягыннан чыгып, башка җирләрдә имам вә мөдәррис булган затлар да билгеле. Югарыда сөйләнгән Салих бине Сәгыйдьтән башка: Балтачның үз кешесе Габделхәким бине Габбас — XVIII йөз ахыры — XIX йөз башларында Ашыт (Иске Ашыт) авылында, 1810 елда вафат булып, Ташкичү зиратына күмелә, шунда ук Ш. Мәрҗанинең әти-әнисенең каберләре дә бар; Килидән чыккан тагын бер мулла — Габделгани бине Салих Казанның мәгълүм Печән базары мәчетендә имам була, 1871 елда үлә; «Чутай Давыты» дигән берәү (Давыд бине Җәгъфәр) узган гасырның урталарында Казан укымышлылары даирәсендә тирән белемлелеге һәм матур, сәнгати язу оста-

лыгы белән танылган булган. Шаһиәхмәд бине Рафикъ атлы Салавыч кешесе Минзәлә якларында имам була, күп кенә атаклы имам вә мөдәррисләр тәрбияли. Шул ук Салавычтан Тукай бине Урманай хәзерге Башкортостандагы Эстәрлебашка күчеп китә, ә анын оныгы Нигъмәтулла хәзрәт — XIX йөз урталарында шунда ук имам вә мөдәррис, заманында чиктән тыш зур дан вә шөһрәт казанган кеше.

Татар мәркәзләрендә мәчет салдырган кайбер Балтач ягы байлары да билгеле. Мәсәлән, Кариленең Җиһанша бине Бикмөхәммәд Казанда зур сәүдәгәр булып китә һәм 1866 елда соңыннан «Җиһанша мәчете» дип танылган мәчетне салдыра, сонгарак мәдрәсә дә төзетә. Шуларның чыгымнарын каплау өчен базар, зур кибетләр ача, мәчетнең имам һәм мәзиннәре өчен ике кибет, яшәр өчен бер йорт салдыра. «Күпме байлыгын сарыф иткәненә һәм күпме яхшылыклар эшләвенә Алла шаһит», ди Ш. Мәрҗани. Мәчет 1868 елда, шул ук Мәрҗани имамлыгында, өйлә намазы укылып ачыла. Ул мәчет әле дә бар — Тукай урамында, Колхоз базарына якын, 1992 елда манарасын күтәреп яшел төскә буяп куйдылар (элегрәк Казан халкы арасында «Кызыл мәчет» дип йөртелә иде; исеме кайбер даирәләрдә ни сәбәптәндер «Солтан мәчете» дип тә таралган).

Чистай мәчетен узган гасыр урталарында Сасналың Хәсән бине Муса атлы бае төзетә. 1867 елда вафат булып, үзенең васыяте буенча 25900 сум акчасы фидия итеп шул мәчеткә тапшырыла (ул заман өчен бу бик зур акча; бер ат, мәсәлән, шул чорларда 3—4 сум торган). Җеназасын бая телгә алынган Таҗетдин мулланың улы Зыятдин укып, туган авылы Саснада жирлиләр. Анын улы Гомәр — Балтач тирәсенең мәгълүм байларыннан. Сасна ягы урманнарын әле без яшь чакта да Гомәр бай урманнары дип атыйлар иде. Минем әтинең, мәсәлән, ул бай хакында яхшыдан бүтән бер әйбер дә сөйләгәне булмады.

2. Мортаза бай. Фаҗигасе һәм истәлеге

Сүзем, шулай итеп, байларга килеп житте. Әлбәттә, бөтен Балтач төбәгенең байларын санап чыгарга җыенмыйм, әлегә миндә андый тулы мәгълүмат та юк. Киләчәктә авылларның музейлары төзелгәндә һәм тарихлары язылганда бик күп нәрсәләр билгеле булыр, безнең буын һәм яшьрәкләр өчен инде онытылган бу исемнәр кабат калкып чыгар, яңа гыйбрәтләр ачылыр. Мин язмамда Балтачның үзенең һәм, гомумән, Балтач ягынын иң атаклы

бае булган, үз авылында, күрше Нормада, хәтта Казанда да фабрикалар һәм кибетләр тоткан, исеме Балтачта әле дә телдән-телгә йөргән Мортаза бай (Мортаза Мөлеков), бигрәк тә аның соңгы еллары хакында берничә генә сүз әйтеп китмәкче булам.

1918 елда Балтачта бер хәл була, аны күпләр ишетеп беләләр, ул вакыйга хәтта Г. Бәшировның «Намус» романына да бер эпизод булып килеп керә. Үзенең гаиләсе белән Казаннан Малмыжга үтеп баручы бер комиссармыкемме, халыкны аттырырга килә икән дигән ялгыш хәбәр таратылу аркасында, Балтач янында үтерелә (аның кабере озак еллар буена авыл үзәгендә, райбашкарма бинасы янында иде, соңыннан зиратка күчерелде). Ул кеше комиссар түгел, ә акгвардияче офицер булган икән, дигән хәбәрләр дә йөрде. Ләкин берәү дә шуның чынында кем булганлыгын, исем-фамилиясен белә алмады (шул вакытта исән калган улының да язмышы билгеле түгел). Аның турындагы материаллар, булсын Татарстан, булсын Киров өлкәсенең КГБ органнарында, сакланмаган, диделәр (минем үземнең дә ул вакыйга белән якыннан, документлар эзләп моңарчы кызыксынганым булмады). Әмма «комиссар»ны үтерү эзсез калмый, озакламый Казаннан коралланган бер отряд килеп, Балтач халкы арасында репрессия үткәрә: башта авылга каршы булган тау башына туплар куеп һәм шрапнель снарядлар аттырып, халыкны бик каты куркыталар, шуннан соң алты кешене боргычлап алып, бернинди судсыз-нисез басуга алып менеп аталар. Бу хакта, шул атылганнарның исемнәрен дә санап, минем әти еш сөйли иде.

Эш шуның белән беткән төсле була, Балтач халкы да әкренләп тынычлана. Әмма бу вакыйга 10 елдан соң, ягъни 1928 елда, кабат калкып чыга — кемдер: кайбер кешеләр тиешле җәзасын алмый калдылар, анда әле хөкем ителерлек башкалар да бар, дип тиешле органнарга шикаять-донос яза, исемнәрен санап үтә, шулар арасында Мортаза байны да күрсәтә. Җитмәсә, шуннан өч кенә ел элек — 1925 елда — халык арасында беркадәр чуалышлар булып ала, ә алар исә 1921 елда Кронштадтта матросларның баш күтәрүеннән соң бөтен Рәсәйне диярлек чолгап алган крестьян восстаниеләренең соңгы, кечерәк бер кабатланышы булып барлыка киләләр. Менә шул, теге әләкче үзенең шикаятендә Мортаза байны, 1918 ел вакыйгасы өчен җәзасын алмый калган һәм 1925 тә дә авыл халкын баш күтәрергә котырткан, дип гаепли. Мәгълүм ки, ул вакытларда кеше язмышын хәл итү өчен шундый бер донос җитә торган була.

Мортаза байны кулга алалар. Тикшерү эшләреннән соң аңа 1929 елның декабрендә суд була: Татарстан АССР Верховный суды Мортаза Мөлековны атарга хөкем итә. Әмма Мортаза бай М. И. Калинин исеменә үтенеч язуыпрошение җибәрә, һәм аның инде олы яшьтә булуын исәпкә алып, үлем җәзасы лагерь белән алыштырыла.

Әмма ул язмыш хакында минем әти бераз белә иде. 1942 ме, 43 ме елларда сугышта ул очраклы рәвештә әллә Әлмәттән, әллә Минзәләдән булган бер татарны очрата. Әлбәттә, туган яклар турында сөйләшеп китәләр, һәм шул кеше, әтинең Балтачтан икәнлеген белгәч, аңа Мортаза бай турында сөйли, чөнки ул аның белән бергә Себер лагерьларында булган була. «Мортаза агай ачлыктан шешенеп үлде», дип әйтә әлеге кеше әтигә. Үләр алдыннан Мортаза бай аңа: энем, әгәр дә моннан котылып, туган илгә кайта алсаң, Балтачка барып кил, хатыным яки балаларым исән булса, аларга әйт, өй алдындагы шомырт төбенә алай-болай булса кирәк булыр дип кечерәк бер чуен белән «сары» күмгән идем, шуны алсыннар, дигән (чуен савыттагы алтын акчалар дигән сүзе инде).

Ул кеше лагерьдан котыла котылуын, ләкин өенә дә кайта, Балтачка да керә алмый, сугышка эләгә. Әти белән аларның юллары тиздән аерыла, бүтән күрешә алмыйлар. Мортаза бай гаиләсенең язмышын мин белмим, әмма безнең әти сугыштан кайтканда аның хатыны да, балалары да юк иде инде[1]. Шуңа күрәдер дә, әти теге «сары» турындагы сүзне берәүгә дә сөйләмичә үзендә озак саклап йөргән, ул аны күп еллар үткәч кенә миңа әйтте. Бай алтыннары турында сөйләргә курыккандыр да, бәлки; еллары да нинди бит — сталиннар, элеккеге НКВДлар (МГБлар, КГБлар) заманы.

50—60 нчы елларда Мортаза байның йорты урынындагы ташпулатны сүткәндә һәм соңрак шул җирдә төзелешләр алып барганда берничә тапкыр алтыннар чыга. Алар башта бала-чага арасында таралып китеп, хокук

---

[1] Һәрхәлдә, Балтачта юк иде. Гәзиттә шушы мәкаләм басылып чыккач, миңа телефоннан шылтыратып, Мортаза байның кече кызы исән икәнлеген әйттеләр һәм адресын бирделәр, очрашуга чакырдылар. Әтисен алып киткәндә 40 көнлек кенә булып калган Илһамия апа белән күрешеп сөйләштек, аңа хәзер 66 яшь, Казанда яши. Мортаза бай турында мәкалә чыкканына бик куанган, елашып укыдык, диде; әмма үзеннән өстәп әтисе хакында яңа мәгълүматлар бирә алмады: аның хәтерләмәве аркасында гына түгел, ә әнисенең ул хакта заманында сөйләргә куркуы сәбәпле. Тик инде, әтисе кулга алынгач, аларны туган йортларыннан куып чыгаруларын, бер кешенең мунчасында яшәргә мәҗбүр булганлыкларын һ. б. төрле авыр газаплар чиккәнлекләрен әнисе әллә нигә бер кызына елап-елап сөйли торган булган.



Балтачның Мортаза бай йорты. Сулдан икенче, кулына калын «дело» тотканы — Мортаза бай. 1917 елга кадәр төшерелгән фото

саклау органнары тиз арада җыйнап алалар. Ул алтыннар арасында, һичшиксез, теге чуен эчендәге «сары»лар да булгандыр...

Мин әтидән Мортаза байның ниндирәк кеше булуы хакында сораша идем. Аның сөйләвенчә, бай бик тә тырыш һәм гадел, бер тиенен дә әрәм итмәгән һәм башкалардан да шуны таләп иткән, кирәк чакта кырыс та кеше булган. Әҗәтне вакытында китермәсәң, ачулана, әмма килешкән вакытка барып: «Мортаза абзый, әлегә эшләрем бик үк шәптән түгел, бераз көтеп тор»,— дисәң: «Ярар, булгач китерерсең»,— дип әйтә иде, ди. Ярлы кеше булса, еш кына алып та тормый: «Әйдә, ярар, савабы булсын, гает көнне дога кылырсың»,— дип кенә куя иде, ди. Үзе бик гади, еш кына башына «мескен» бүрек, аягына чабата киеп, алдына ак алъяпкыч бәйләп йөргән.

Мортаза бай хакында соңгы елларда мин Балтачның күп кенә кешеләре белән очрашып сөйләштем. Аларның берсе дә байны начар итеп телгә алмады, киресенчә, аның гадилеге, кешелеклелеге, әмма таләпчәнлеге һәм гаҗәеп эшчәнлеге турында сөйләделәр. Алар бу хакта әти-әниләреннән, гомумән, авылдашларыннан ишетеп беләләр, хәтта аның үзен күреп белүчеләр дә бар әле. Шуларның берсе — Балтачның бүгенге иң олы ир кешесе, 88 яшьлек Рәхим абзый. Аларның өе элек Мортаза байлар урамында булган, шуңа күрә ул аны бик яхшы хәтерли һәм байның тормыш-көнкүрешеннән дә шактый мәгълүматы бар.

Аның сөйләвенчә, Мортаза агай өзлексез эш артыннан чапкан, хәтта иртәнге караңгыда ук үзе ике ат җигеп көлтәгә китә торган булган. Кайчан гына йоклый икән соң бу, дип аптырый идек без, ди Рәхим абзый. Ураза җиткәч, тарантасына яхшы чәй тутырып, авыл буйлап өләшеп йөрер, ә Корбан гаетендә зур мал суеп таратыр иде, ди. Икенче бер авылдашым Габдулла агайның сөйләвенчә, итек фабригында эшләүчеләрне бай, хезмәт хакы түләүдән тыш, көненә ике тапкыр – көндез һәм кичен ашата торган булган: кеше башына берәр кадактан (400 г.) итле аш пешерткән, күмәчен, маен, чәен куйдырткан.

Дөрес, Мортаза бай турында кире фикер әйтүчеләр дә булды. Хәер, андыйларның мин икесен генә очраттым. Шуларның берсе – бүгенге номенклатура вәкиле, миннән бераз яшьрәк кеше, элеккеге большевистик, коммунистик идеологиядән әле дә котыла алмый яшәүче. Шуңа күрә дә ул, байны, гәрчә аның турында рәтле әйбер белмәсә дә, эксплуататор, ягъни мәсәлән, изүче дип атады. Ә менә икенчесе белән эш катлаулырак һәм шактый гыйбрәтле дә. Ул бүген Балтачта тормый инде, читтә яши, бернечә ел элек туксан яшен тутырган. Агай, лаеклы ялга чыкканчы, хакимият органнарында эшләде, ә тагын да элегрәк, 20 нче еллар башында, ГПУ җитәкчесе, ә менә Мортаза байны кулга алганда волисполком, ягъни волостьның, бүгенгечә әйтсәк, районның башкарма комитеты рәисе булган, байга «Всесоюзный розыск» игълан ителгәч, аны властьларга тотып биргән. (Мортаза бай ул вакыттагы эзәрлекләүләрдән качып бераз читтә яши һәм, заманалар тынычланды дип уйлап, кире Балтачка кайта да, үзенең фабригына каравылга кергән була.)

Мин бу кеше белән каты итеп сөйләшә алмадым, һәм аның кирәге дә булды микән? Безнең татар әйтмешли, ашын ашаган, яшен яшәгән инде ул. Гомере буе сәвиткә, партиягә, тоталитар идеологиягә тырышып хезмәт иткән һәм бүген дә шуңа табынып яши. Гомеренең соңында гына мин аның дөньяга карашын үзгәртә дә алмыйм һәм аның кирәге дә юктыр. Киресенчә, үзенә рәхмәт тә әйттем әле, чөнки ул, тере тарих буларак, шул замандагы бик кызыклы һәм гыйбрәтле әйберләр сөйләде.

Мортаза бай хакында әле беренче тапкыр зурлап язарга тотынганмын икән, мөхтәрәм укучыларның игътибарын тагын бер әйбергә юнәлтми булдыра алмыйм. Әлбәттә, мин аны кеше буларак идеаллаштырырга, аның шәхесен һәм бөтен эшчәнлеген күпертеп күрсәтергә теләмим. Кем әйтмешли, эшләмәгән кеше генә ялгышмый. Мортаза байның тормышында да төрле хәлләр булгандыр. Кешеләрнең

сөйләвенчә, аның итек фабригында берәү, мәсәлән, йон тетү машинасына кысылып үлгән, ул вакыйга турында Балтачта хәтта бәет тә чыгарганнар. Әмма сөйләүләренә караганда, әлеге бәеттә бай хакында начар сүз әйтелмәгән. Шул бер вакыйга өчен генә Мортаза агайны эксплуататор дип атарга яратучы бер-ике кешегә шуны әйтәсем килә: сәвитнең үзенең завод-фабрикаларында, хезмәт куркынычсызлыгы кагыйдәләрен сакламау нәтиҗәсендә, күпме кеше һәлак булды икән? Кем санаган аларны?! Миллионнардыр!

Ә 1918 елда бая телгә алынган комиссарны үтерү вакыйгасында Мортаза байның турыдан-туры катнашуы яки күрсәтмәсе булганлыгы хакында төгәл мәгълүматлар кайда? Әгәр дә булган булса, нәрсә? Нәкъ менә шул 1918 елда әлеге комиссарлар тәшкил иткән большевизм режимы канлы, кызыл террор башлый. Аның нәтиҗәләре коточкыч: ул террор 20—30 елларда дәвам иттерелә һәм 15 миллионнан артык корбаннар бирә. Бик тә мәгълүматлы бер тарихчы миңа болай дигән иде: сугыштан соңгы Советлар Союзы геройлары һәм аңа кадәр большевизм, Сталин репрессияләре нәтиҗәсендә һәлак булганнар арасында, халык санына күчереп исәпләсәң, татарлар беренче урында тора. Хөрмәтле укучылар, кадерле милләттәшләр шуннан үзләре нәтиҗә ясасыннар иде... Намус дигән нәрсә бар бит әле!

Сүз Мортаза байны идеаллаштыру турында түгел, ә моңарчы каһәрләнгән, нахак бәла тагылган, Себер лагерьларында һәм төрмәләрдә башлары юк ителгән, иң әүвәл милләт мәнфәгате өчен кайгыртып йөргән йөзләрчә, меңнәрчә татар байларының һәм муллаларының исемнәрен ихтирам белән, рәхмәт әйтеп искә алу турында бара! Бүгенге кешеләрнең байтагына моны аңлавы кыендыр. Заманалар үтәр, коммунизм-большевизм идеологиясе белән миңгерәйтелгән безнең буынны икенчеләре алыштырыр — аңларлар...

Элекке татар байлары хакында сүз алып барганда, шуңа басым ясап үтәсем килә. Алар, хәзерге заманның күпчелек мафиозник бизнесменнарыннан үзгә буларак, бер тиенне ике тиенгә алыштыру, шуннан байлык туплау өчен төннәрен йокламыйча дигәндәй, йөзләрчә чакрымга чаба (үзе чаба һәм приказчикларын чаптыра), шуннан тупланган байлыкның күп өлешен милләт файдасына бирә: мәчет төзи, мәдрәсә ача, тегермән тота, юлларны карый, гарипгорабаны, ярлы-ябаганы туйдыра, вәкыф кыла, ягъни килеренең бер өлешен җәмәгать файдасына калдыра, фидияйолым бирә. И-и, саный китсәң... Авылны байлар тотты, байлар туйдырды, дип әйтә иде минем әти.

Мортаза бай 1929 елда Себергә сөрелде, дип әйттем. Ә бит массакүләм «раскулачивание» шуннан ике елдан — ВКП(б) Үзәк Комитетының 1930 ел, 14 март карарыннан соң гына башлана. Татар байларына карата булган репрессиягә аңа кадәр үк тотынулары, минемчә, очраклы хәл түгел, киресенчә, аның тирән мәгънәсе бар — ул, Рәсәй империясенең урыс булмаган халыкларга, иң беренче чиратта жене сөймәгән татарга, каршы алып барылган шовинистик, карагруһчыл сәясәте. 1552 елдан ук башланган бу сәясәт 1910 елда «атаклы демократ-реформатор» Столыпин җитәкчелегендә үткәрелгән «Особое совещание»дә бөтен зәһәрлеге белән калкып чыга, татарны панисламизмда, пантюркизмда гаепләп, бөтен Россияне татарлардан килә торган «хәвеф»кә каршы көрәшкә чакырып һәм төрле административ чаралар белән куркытып, шул чараларны тормышка ашыру буенча хәтәр карарлар кабул ителә. Бу сәясәттән 1917 елда хакимияткә килгән большевиклар да читтә калмый. Алай гына да түгел, Сталинның, большевизмның татарга һөҗүме ВКП(б) ҮКның 1923 елда Мирсәет Солтангалиев эше буенча булган махсус карарыннан соң аерата көчәя. 20 нче еллар ахырында «солтангалиевче»ләргә, татарның интеллигенциясенә каршы көрәш кискенләшә, нәкъ менә шул елларда Сөембикә манарасының аен бәреп төшерәләр, татар мәчетләрен ябу һәм аларның манараларын кисү, татар интеллигенциясенә һөҗүм башлана.

Әмма Хан мәчетеннән ай төшереп, мәчет манараларын кисеп, интеллигенцияне сөргенгә сөреп кенә милләтне бетереп булмый әле. Аның өчен Рәсәй базарына нык үтеп кереп, урыс экономик сәясәтенә җитди конкурент булып үсеп алган татар капиталын, бу милләтнең икътисади нигезен тамырдан какшатырга кирәк, ә ул капитал, ул нигез — байлар кулында. Менә шуңа күрә дә, татарны милләт итеп саклауга ифрат зур көч куйган аның алдынгы байларына, шушы борынгы, заманында зур дәүләтләр тоткан милләтнең игътисади куәтенә каршы аяусыз көрәш башлана. Шул явыз көрәшнең беренче корбаннарыннан булып, Балтачның, Казан артының, гомумән, татарның ул замандагы мәгълүм һәм зур бае булган Мортаза байны үзенең тырыш, гадел хезмәте белән гомере буе җыйган һәм күбесен милләт мәнфәгатенә тоткан мал-мөлкәтеннән вә мирасыннан, гаиләсеннән, туган авылыннан, сөйгән халкыннан мәңгегә аерып, Себергә сөрәләр, шунда башын бетерәләр[1]. Канлы большевизмның һәм ул төзегән каһәр

---

[1] Кайбер мәгълүматлар буенча, Мортаза бай Самара төрмәсендә үлә. Хәер, Себер лагерьмы, төрмәме — аның әлләни аермасы юк.

төшкән системаның урысның үзенә дә һәм иң беренче чиратта татарга, аның интеллектуаль көчләренә, экономик рычаглары булган реформатор байларына, шул исәптән Балтачның Мортаза байга китергән фаҗигасе шунда!

Мортаза һәм башка байларның истәлеге — халыкның укымышлы муллаларга һәм гадел, ярдәмчел байларга ихтирамы ул, милли горурлыгы сүнеп бетмәгән игелекле татарның күңелендәге җылы хисләр алар. Сөйгән халкы белән бергә тормышның бөтен ачысын-төчесен татып, җиргә ябышып үскән татар байларының истәлеге — бүгенге үзгәрешләрне аңлап, кабат милли уянуга аяк атлаган татарның азатлыкка булган өмет вә хыяллары алар. Бу истәлек — элекке байларның традицияләрен яңарту юлында мең төрле авырлыклар үтеп байлык туплаган, шуның иң зур өлешен мәчетләр салуга, йөз меңнәрчә данәләрдә китаплар басып, аларны халыкка бушлай таратуга, милли-азатлык хәрәкәтенә зур матди ярдәм рәвешендә биргән бертуган Кашаповларда, аларның ярдәмчеләрендә һәм көрәштәшләрендә (әлегә башкаларның исемнәрен атамаганмын икән, андыйлар мине гаеп итмәсеннәр, мин үзем яхшы белгәннәрне, үзем инанганны хуплап язам).

Мортаза бай истәлеген яңарту, аның исемен мәңгеләштерү максатында Балтач халкына, район хакимиятенә минем берничә конкрет тәкъдимем бар, кабул итү — аларның эше. Авылда байдан калган икешәр катлы ике таза, таш бина саклана. Шуларның берсендә — асты кибет, өсте — банк булганында, Балтач музеен оештырырга: өске катта — авыл, район тарихы буенча документлар, фотолар, татарның элекке тормышын күз алдына китерүче киемсалым, савыт-саба, эш һәм музыка кораллары, йорт җиһазлары, ювелир әйберләр, шулай ук мәчетләр, мәдрәсәләр, мәгърифәт, финанс-кредит һәм сәүдә тарихыннан мәгълүматлар; элек байның кибете булган аскы катта — мөмкин булганча әүвәлге кыяфәтенә китереп торгызылган шул кибет һәм Мортаза агайның конторасын реставрацияләп куйган бер интерьер-почмак. Байдан калган икенче зур гына бинада (элегрәк анда саклык кассасы урнашкан иде) җәмгыяте хәйрия (благотворительность) үзәге төзергә: өске катта — һәртөрле бизнесменнар, спонсорлар, яңа заман меценатлары, дини оешмалар белән эш итү конторасы, шул хәйрия файдасына төрле чаралар (концертлар, кичәләр һ. б.) үткәрүне оештыру бүлеге; аста — җыйналган акчага ачылган һәм гарип-горабаны, тәрбиясез калган карт-карчыкларны, хәзерге заманда күбәеп киткән ярлы-ябагайны, мөмкинлектән чыгып, көнгә бер-ике тапкыр бушлай ашата торган ашханә һәм шунда ук алар өчен

бушлай дарулар бирә, табиб ярдәме күрсәтә торган медпункт-аптека. Бу үзәктә тормышның ачысын-төчесен татып үскән, ходайдан, ата-анасыннан алган иманын үзендә саклаган, безнең татарга хас миһербанлы, намуслы, инсафлы кешеләр эшләргә тиеш. Эшчән һәм тәрбияле Балтачта андыйларга кытлык юк, минемчә.

Әллә ниткән, юк-бар «эшләр»гә миллионнар тотканчы, авыр сугыш елларында фронтта һәм тылда мәңгегә сәламәтлеген югалтканнарга, бүген ипи белән сөт алырга акчаны ничек җиткерим икән, дип тилмереп яшәүче фәкыйрь пенсионерларга, каһәр төшкән авыр һәм газаплы дөньяның «җимешләре» булган һәртөрле дивана вә гарипләргә, тормыш төбенә төшкән башка бичараларга ярдәм кулы сузу — мең тапкыр яхшырак һәм саваплырак эш булыр иде.

Минем бу беркатлылыгымнан көлүчеләр дә, «кычытмаган җиреңне кашып йөрисең», дип әйтүчеләр дә булыр. Ә менә Балтачның Мортаза, Кәләми, Мөхәммәтҗан, Сасның Гомәр, Карилэнең Шәйхи һәм башка бик-бик күп байлар көлмәсләр дә, әйтмәсләр дә иде, чөнки алар шундый саваплы эшләрне башкаруга гомерләрен багышлаган изге затлар булганнар. Гасырларга калырлык зур бер мәчет салып куюкебек изге эш эшләгән балтачларның тагын бер изге эшен — халык музееп һәм җәмгыяте хәйрияне оештырырга көчләре җитәр, дип уйларга хакым бар төсле.

Мортаза байның йорт-җире урнашкан урам бүген «Космонавтлар урамы» дип атала. Әлегә Балтачтан ярты космонавт та чыкканы булмады, киләчәктә чыкса инде... Әмма иксез-чиксез галәм киңлекләрен йөзеп йөргән Рәсәй һәм Америка армияләренең полковник-майорлары булган күп санлы космонавт-астронавтларына безнең татарның, тау астында, үзәнлектә яшеллеккә күмелеп утырган, аның моңсу вә матур авылларының һич катнашы юк. Татар авылларындагы «Космонавтлар», «Звездная», «Юбилейная» һ. б. шуның ише исемнәр — безнең дистә елларга сузылган коллык психологиябезнең, томаналыгыбызның җимешләре генә. Алыштырыгыз сез, кадерле якташлар, шул урам исемен Мортаза бай исеменә. Урам башланган җирдәге һәм бая телгә алынган ике катлы таш йортның стенасына беркетегез бер мәрмәр такта, язып куегыз шунда Мортаза агайның кем булганлыгын. Куансыннар картлар, гыйбрәт алсыннар яшьләр.

Мортаза байдан калган ике зур бина һәм яңа салынган мәчет Балтачның буеннан-буена сузылган үзәк урамында урнашканнар. Гомер-гомергә, без белгәннән бирле ул урам Тукай исемен йөртте. Әмма берзаман ул Ленин исеменә

алыштырылып, «Тукай» кечерәк бер урамга күчте, һәм менә яңа мәчет тә Ленин бабай урамында пәйда булды.

Бүген Ленининар, Свердловлар, Дзержинскийлар, Урицкийлар, Менжинскийлар һәм башка яманаты чыккан большевиклар заманы үтеп бара. Аларның исемнәре белән бәйле булган урамнар Рәсәйнең үзендә дә, безнең Татарстанда да (Чаллы, Түбән Камада) алыштырыла башлады. Дан булсын әле Балтачка, мөхтәрәм авылдашлар, кайтсын әле Тукай кире үз урамына, җитмәсә, ул күпмедер безнең районныкы да бит: шушы җирдә аның бераз балалык вакыты үткән, монда аның әнисенең кабере калган...

Бер кызып киткәч, мин әле туган як тегермәннәре (хәер, ул хакта моннан 17 ел элек язып чыккан идем инде, ләкин алар, кызганычка каршы, бүген җимерелеп баралар), Балтач һәм Чепья базарлары («Хәлләр бар Чепья базарында!») хакында да язармын дигән идем, әмма, боерган булса, икенче тапкыр инде. Хәзергә шуңа аерым басым ясап үтим: югарыда кыскача язып үтелгән һәм шул уңайдан ясалган кайбер тәкъдимнәр бер Балтачка гына түгел, ә бөтен татар җиренә кагыла. Һәр авылның, һәр төбәкнең үзенең Габдерәүф хәзрәтләре вә Мортаза байлары, үзенең су һәм җил тегермәннәре, базарлары булган. Һәр якның, һәр авылның үзенең кабатланмас тарихы булган, ул тарих үз музеен көтеп ята. Бу фани дөньяның һәр почмагындагы һәр кимсетелгән адәм баласы миһербан-шәфкатькә мохтаҗ. Ниһаять, һәр авылда, һәр районда, һәр шәһәрдә мәгънәсез вә искергән исемнәр йөртүче урамнар, мәйданнар бихисап. Күпчелеге урысча исемнәрдән торган ул урамнар безнең үз җиребездә, үз Ватаныбызда милли атамаларга, халкыбыз азатлыгы өчен газиз җаннарын биргән каһарманнарның, татарның милләт булып яшәешен нығытуда, интеллектуаль көчен үстерүдә һәм данын арттыруда чиксез зур хезмәт куйган асыл затларыбызның мөкатдәс исемнәрен көтеп яталар (бу мәсьәләдә без — бер төркем галимнәр — Казанда империячел көчләр, элеккеге тоталитар идеология тарафдарлары һәм куркак җаннар белән көрәш алып барабыз, тик әлегә уңышсыз)...

...Балтачта мәчет ачылуның икенче көнендә иртән торып, тагын шул тарафка киттем. Очраклы хәлдерме, юктырмы, әмма яңа мәчет бая мин әйтеп үткән түбән оч, ягъни безнең оч, мәчете урынына каршы, аннан бераз гына читтәрәк салынган. Ә ана каршы, аз гына кыйгачлап, урамның икенче ягында Габдерәүф мулланың йорты тора. Йа Алла! Балтачта да, башка бик күп җирдә дә соңгы бер-ике дистә ел эчендә иске йортлар бетә язды, алар урынына яңалары салынды, ә менә мулла йорты калган!

Аны күпләр онытканнар инде, ә мин хәтерлим — ак сакаллы, ак йөзле, Хозыр Ильястай мулла абзыйның итәгендә утырып торган көннән бирле хәтерлим. Урам якка караган, кайчандыр хәзрәт үзенең гаиләсе белән куылып чыгарылган агач өй исән, аның артындагы, электә җир идәнле таш өй исән, өйнең рәхмәт төшкерс яңа бср хуҗасы аның стеналарын һәм тәрәзәләрен биегәйтеп, кыйшайган түбәсен яңадан ябып куйган. Җир идән дә инде мулла абзый эзләре белән тарихта гына калган. Илле елдан соң туган яңа хисләр, яңарган хатирәләр, тамак төбенә утырган яңа төсрләр...

Тукайның «Кичке азан»ы белән башлаган язмамны кабат шул илаһи шигырьдән өзек китерү илә тәмамлыйм:

Хөлүсән мөс —
тәмигъ азан.
Фи бәдьиһи
Вә бәгъдә азан[1].

Искәрмә: Россия Федерациясенең «Сәяси репрессияләр корбаннарын реабилитацияләү турында»гы 1991 ел, 10 октябрь Законы нигезендә Мортаза Мөлеков (Мортаза бай) акланды.

ТУГАН ЯК ТЕГЕРМӘННӘРЕ[2]

Тегермән куәте су белән.

Татар халык мәкале.

Узган ел «Комсомольская правда» газетасында (1976 ел, 1 сентябрь) журналист В. Песков Брянск өлкәсендә сакланып калган су тегермәне турында язып чыкты. Мәкалә күпләрдә кызыксыну уяткан, һәм автор килгән хатларга күзәтү рәвешендә бу хакта янәдән бер очерк бастырды. Укучылар әлеге тегермәнне торгызган колхоз председателенә рәхмәтләрен әйтәләр, бүгенге техника заманында эшләүче мондый борынгы агрегатларны әллә кайчан үлеп беткән мамонтка тиңлиләр. Мамонт! И, дип уйлыйм, андый икс «мамонт» туган ягымда — Балтач районында да бар ләбаса. Җитмәсә, ул тегермәннәр турында материал да җыя башлаган идем.

«Башлаган идем» дип әйтү азрак та булыр. Бала чакта әтигә ияреп тегермән тартырга барулар, аның буасына балык чирттерүгә йөрүләр (ул гадәтем озак елларга калды,

---

[1] Мәгънәсе: ихлас белән тыңланган, башлангычында һәм дәвамындагы азан.

[2] Мәкалә шактый кыскартылып «Социалистик Татарстан» газетасында басылды — 1977, 21 июль.

җәйләрен авылга кайткан саен шунда бара идем), археологик экспедицияләр уздырганда тегермәннәр тарихы белән кызыксынулар... Тарих һәм культура истәлекләрен саклау җәмгыятенең археология секциясендә Балтач тегермәннәрен архитектура һәм этнография истәлекләре итеп калдыру турында карар чыгарып, шуны раслауны һәм тиешле чаралар күрүне сорап, җәмгыятьнең республика советына да мөрәҗәгать иттек. Ул арада бөтен илебездә тарих һәм культура истәлекләрен саклау турында закон проекты игълан ителде, тарихи истәлекләрне киләчәк буын өчен саклап калу эше гомумдәүләт эшенә әверелде кебек.

Иң элек тегермәннәр тарихы турында берничә сүз. Ул, кеше иген игә башлаган заманнан, моннан биш-алты мең ел электән үк килә. Дөрес, әле ул вакытта чын тегермәннәр булмый, аларның бик гади башлангычлары — орлык угычлар гына кулланылган. Эшләү тәртибе гади аның — ике таш арасына ашлык салып, шул ташларны бер-берсенә ышкып уганнар. Соңга табарак, колбиләүчелек чорында, көньякта цивилизация башланган илләрдә беренче су тегермәннәре дә күренә башлый. Аларны күбрәк тиз агучы тау елгаларына корганнар. Греция һәм Рим дәүләтләрендә ташларын хайваннар, хәтта кешеләр (коллар) көче белән әйләндерә торган тегермәннәр барлыкка килгән. Әмма күп җирдә, шул исәптән безнең якларның беренче феодаль дәүләтләре Рус һәм Болгар илләрендә дә ташлары зур булмаган (уртача диаметры 50 сантиметр) кул тегермәннәре киң таралган. Шул ук вакытта, X йөздән башлап, җил тегермәннәре кулланыла башлаган. Безгә аларның үрнәкләре Көнчыгыш һәм Якын Көнчыгыш илләреннән үтеп кергән. Баштарак, җил үзгәрешенә карап, тегермәннәрнең бөтен корпусы әйләнгән, ә XVIII йөздән «шатерлы» тегермәннәр, ягъни канатлары урнаштырылган түбә генә әйләнерлек итеп эшләнгәннәре төзелгән. Шуны да әйтеп үтик, 1917 елда Россиянең Европа өлешендә 170 мең җил тегермәне булуы мәгълүм. Миңа 60 нчы елларда, бигрәк тә Кама аръягы дигән җирдә, андый канатлы тегермәннәрне күргәләргә туры килде; кайберләренә әле он тартырга да йөриләр иде.

Кул һәм җил тегермәннәре белән беррәттән Рус һәм Болгар (соңрак Казан ханлыгы) дәүләтләрендә су тегермәннәре дә кулланыла башлый. Алар Болгар дәүләте оешкан заманда ук киң таралыш алганнармы — анысын әйтүе кыен. Бу мәсьәлә археологик яктан тикшерелмәгән әле. Һәрхәлдә, монголлар килгәнче үзәк болгар җирләрендә корылган су тегермәннәре калдыкларын туры китергәнебез юк. Безнең уебызча, безнең якларда мондый төр тегермән-

нәр XIII—XIV йөзләрдә, ягъни халык урманлы һәм мул сулы елга буйларына күчеп утырган чакларда киң кулланыла башлагандыр. 1969 елда Казан суы буенда тикшеренүләр үткәргәндә безгә бик иске бер тегермән буасының калдыкларын күрергә туры килде. Авыл картлары аның кайчан төзелгәнен хәтерләми. Сакланып калган ташы күләме ягыннан болгар кул тегермәннәре ташыннан зуррак, бүгенге көн тегермән ташларыннан кечерәк, ягъни — ике арада. Шул ук җирдә Казан ханлыгы чорына караган авыл урыны һәм каберлек тә табылды. Боларның барысын искә алып, без тегермәнне дә әлеге чорга керттек.

Су тегермәннәре соңга таба тагын да киңрәк таралган һәм аларның, әлбәттә, җил тегермәннәреннән өстенлеге үзенекен итә: җил тегермәннәре, мәгълүм ки, җил искәндә генә эшли; алар бер генә ташлы булса, суныкының берничә ташлы булуын әйтергә кирәк. Тегермән халык тормышында иң әһәмиятле экономик чыганакларның берсенә әйләнә. Тегермән тоту хокукы элек төрле катлау кешеләре арасында каршылыклар да китереп чыгарган. Гомумән, тегермән тоту, он тарту мәсьәләсе гражданлык хокукының, кешелек җәмгыятенең мөһим проблемаларыннан саналган. Бу тема, шуңа күрәдер инде, халык авыз иҗатында да киң чагылыш таба. Халык тегермән тартуга зур әһәмият биргән, аны башка төрле авыр эшләрдән дә мәшәкатьлерәк эш итеп санаган. Нәкый Исәнбәт җыентыгында шундый бер мәкаль бар:

> Урак урмак — уйнамак,
> Печән чапмак — биемәк,
> Ашлык сукмак — кул чапмак.
> Тегермән тартмак — ут йотмак.

Шуңа күрә халыкның тегермәнгә, тегермәнчеләргә таләбе дә зур булган. Нәкый ага мондый бер сөйләм дә китерә. Бер егетнең анасы яңа оннан ипи пешергән. Аны кайнар килеш табынга китереп, урталай сындырып җибәрсә, ни күзе белән күрсен, эченнән чабата килеп чыккан. Моңа егет тә гаҗәпкә калган, әһә, белдем, онны иләмичә изгәнсең икән, дигән.

Юк, юк, иләгән идем, дигән анасы. Егет чабатаны әйләндергәләп караган да, булмас, шушы хәтле чабата ничек итеп иләктән үтәр икән, дип әйткән. Моңа каршы әнисе болай дигән:

— Син, улым, чабатаның иләктән үтүенә исең китмәсен, иләктән үтәр ул, менә син аны ничек тегермәннән үткән диген, шунысын әйт: тегермәнче нәрсә караган?..

Тагын да соңга табарак, капиталистик мөнәсәбәтләр хөкем сөргән чорда, тегермәннәрне эшләтүдә пар көче киң

кулланыла башлый, зур-зур тегермәннәр барлыкка килә. Бөек Октябрь революциясе җиңгәч, яшь совет илен икмәк белән тәэмин итү иң мөһим мәсьәләләрнең берсенә әверелә. В. И. Ленин шул вакытта Петроградтагы тегермәннәр белән махсус кызыксына һәм аларны саклау мәсьәләсенә җитди әһәмият бирә. Он тарту промышленносте кискен сыйнфый көрәш мәйданына әйләнә. Озакламый тегермәннәрне дәүләт милкенә әверелдерү башлана. 1920 елда гына да 67100 тегермән национализацияләнә, механикалаштырылган эре тегермән предприятиеләре төзелә башлый.

Шулай да, әле 30—50 елларда, бөтен Европада киң таралган һәм буш энергиягә корылган су тегермәннәре безнең илебездә, шул исәптән Татарстанда, бигрәк тә аның төньяк районнарында күп иде. Шунда туып үскәнлектән, Балтач ягындагы тегермәннәрнең күбесе әле безнең буын хәтерендә. Тора-бара аларның кайберләренең буаларын су алып китте, икенче берләренең биналары тузды, сүтелеп ташланды. Әмма ике тегермән — Яңгул һәм Салавыч авылларында урнашканнары исән калды. Сүз уңаенда әйтеп үтим, миңа 15 ел буена Татарстанны тоташтан археологик тикшереп йөргәндә берничә дистә елганы аркылысын-буен дигәндәй үтәргә туры килде, тик бер генә җирдә дә сакланып калган су тегермәнен очрата алмадым. Шуңа күрә туган як тегермәннәре, ничектер, күңелгә аеруча якын.

«Җидегән чишмә» исемле романын язганда елгалар, чишмәләр турында өстәмә материал туплау нияте белән язучы Г. Бәширов Балтач якларына килеп чыкты һәм без аны, КПССның Балтач райкомы секретаре Р. Зарипов белән, әлеге икс тегермәнне карарга алып бардык. Бик коры, урманнар янган, үләннәр көйгән 1972 ел иде. Табигатьне саклау мәсьәләсе белән якыннан кызыксынучы Гомәр ага тегермәннәр зонасына кергән болыннардагы кукуруз һәм печәннәрнең яшеллегенә, муллыгына гаҗәпләнде. Гаҗәпләнерлек тә шул, башка җирдә кукуруз дым әсәре күрми тилмереп утыра, ә биредә ул кеше күмелерлек озынлыкта. Тегермән буаларының, шуннан таралган дымның көче иде бу.

Хәзерге заманда авыл хуҗалыгында культуралы көтүлекләрне киңәйтүгә гаять зур игътибар бирелә. Соңгы елларда коры көннәрнең ешаюын, елгаларның саега баруын исәпкә алсак, элекке тегермән буаларын саклау һәм ныгыту, яңаларын булдыру, шулай итеп, сусаклагычлар тотуның кирәклеге бермә-бер арта.

Яңгул тегермәне Шушма елгасының матур җирендә. Юлдан үткән һәр юлчы аңа кызыксынып карап уза. Бик

Балтач районының Янгул авылы тегермәне. З. Бәширов фотосы, 1972

биек, өч катлы итеп, оста куллар тарафыннан эшләнгән ул. Агач архитектураның менә дигән үрнәге. Тегермәннең өч ташы эшли. Икесе су көче, берсе электр белән хәрәкәткә китерелә. Колхоз экономисты М. Хәбибуллин биргән белешмәдә бик куанычлы сүзләр бар. Тегермән буасы Шушма елгасының суын 4 метрга күтәрә икән һәм, шулай итеп, күрше Салавыч тегермәне белән бергәләп, өч зур колхозның культуралы көтүлекләрен туендыру өчен менә дигән сусаклагыч булып та хезмәт итә икән. «Яңа тормыш» колхозында быел сафка басачак 150 га культуралы көтүлек һәм алардан алына торган продукция терлек азыгы балансында зур урын тота. Колхоз идарәсе тегермәннең тарихи истәлек һәм аның буасының яхшы сусаклагыч булуын искә алып, узган ел аңа ремонт үткәргән, шуның өчен 9400 сум акча тоткан. Шул ук елны, мәсәлән, монда 19 мең центнер он тартылган. Мондый хуҗаларча кайгыртуда колхоз председателе Р. Җамалиевның тырышлыгы зур. Бу аның чын мәгънәсендә файдалы һәм мактаулы эше.

Күрше «Социалистик Татарстан» газетасы исемендәге колхоз җитәкчеләре дә Салавыч тегермәнен саклауга әһәмият бирәләр. Электр көченә корылса да, он шул тегермәндә тартыла (моңысын тагын да борынгырак, XIX йөз ахырында төзелгән, диләр), буасына ремонт уздырганнар...



Янгул тегермәненең эче. З. Бәширов фотосы, 1972

Тегермән тартканыгыз яки тегермәннең ничек эшләгәнен күргәнегез бармы? Менә буадан улаклар буйлап тегермән чарыгына (аны «куласа» да диләр) су ага, шуннан чарык әйләнеп торып, аның «кырык чөй»ләре махсус «орчык» аркылы тегермәннең ташларын әйләндерәләр (елганың зурлыгына, ягъни суның көченә карап, ташлар бердән алып 4—5 кә кадәр була). Өске ташның уртадагы тишеге аша өстән, козаудан, ашлык төшә һәм ике таш арасында ышкылып ватыла да, он була. Шунда тегермәнче ташларны карап, көйләп тора: он эрерәк чыкса, өске ташны баса төшә, артык вакка китсә, бераз күтәрә. Тартылган он улактан әрҗәгә агып төшә, аны агач соскычлар белән капчыкларга тутырып алалар.

Бу бер-ике сүз белән әйткәндә генә бик гади тоела, ә буасы белән тегермән үзе, аның бөтен төзелеше, эшләү тәртибе — тулы бер катлаулы механизм. Тагын бер әйбергә игътибар итик: зур һәм авыр, өслекләре кытыршы ике таш арасында он тартыла, ә бит ташлар һич кенә дә бер-берсенә ышкылырга тиеш түгел, югыйсә, он вакланган таш комы белән тулачак. Ә онның ниндиен телисең, шун-

дыен чыгарырга була: бер каттан да ярый дисәң, эрерәк, көрпәлерәк була; күмәч яки ак оннан токмач ашыйсын килә икән, ике каттан җибәрәсең.

Урта гасырлардан безнең заманга кадәр килеп житкән шушы тотрыклы системаны уйлап чыгаручылар һәм үзгәртмичә диярлек саклап килүчеләр алдында мин тарихчы буларак башымны иям. Ел дәвамында өзлексез эшләп торган — язгы ташуда, бозлар киткәндә генә буаны ачып алалар — мондый хикмәтле җайланманы карап, төзәткәләп һәм саклап тору өчен күпме түземлелек һәм осталык кирәк! Аның каравы, буш энергиягә корылган (елга бит өзлексез агып тора, акча сорамый) менә дигән, арзанлы һәм бик тә файдалы вә кирәкле агрегат-җайланма.

Тегермәннәрнең буш энергиягә корылган он тарту җайланмасы, бик яхшы сусаклагыч һәм тарихи истәлек булулары өстенә, тагын бер файдалы яклары бар әле. Бусы да шул ук табигатьне саклау белән аерылгысыз бәйле, шуның кирәкле бер өлеше: тегермән буалары һәм буа артындагы тирән сулы чокырлар балык үрчү өчен зур мөмкинлекләр бирә. Елгалар саега барган хәзерге заманда моның әһәмияте шулай ук зур. Елгаларны балыклы итеп тоту, эштән арып кайтканнан соң яки ял вакытларында шунда төшеп балык каптыру, бүгенге хәрәкәт, техника һәм информациянең көчәйгән чорында какшаган нервларыңны тынычландыру, узган көннең мәшәкатьләреннән, ыгы-зыгысыннан бераз бушанып, табигатьтән ямь табып, хозурланып утыру, җитмәсә тәмле елга балыгы ашау начармыни? Әлбәттә, һәртөрле браконьерлыкка юл куймаска кирәк. Моны халык үзе дә, җирле власть органнары һәм җәмәгать оешмалары да истә тотарга тиешләр.

...Яңгул тегермәненә чираттагы төшүемдә дә, гадәттәгечә, кармаклар алган идем. Тегермән турында очерк язарга тотынганмын икән, аны бөтен ягы белән дә күзаллыйсым килде — шунда төн кунарга уйладым... Мин төн кармакларын салып бетергәндә караңгы да төште, ерак түгел чиак ябалак кычкыра башлады. Яшенле яңгыр якынлашып килә иде, тегермән өенә кереп яттым. Төне буе диярлек яшен яшьнәде, күк күкрәде, яңгыр койды. Тегермәндә бер үзең төн үткәрим дисәң, гөнаһ шомлыгына каршы, аның шул яклары да килеп чыга икән. Ул арада тегермән хакында төрле табышмаклар, әкиятләр, имешмимешләр, ышанулар хәтергә төшә: «Су буенда бүре улый», ул нәрсә? — тегермән. «Утыра әби буада, аякларын салып елгага», ул нәрсә? — тегермән чарыгы. Тегермән буасында яшәгән су аналары, су кызлары, аларнын башлыгы су иясе турында сөйләмнәр... Тегермән тартып бетереп,

кешеләр таралгач, җеннәрнең җыелышып шунда кәрт сугулары... Әүвәл заманнарда, тегермән буасын астан су ашый башлап, буа уларга тотынса, тегермәнне су алып китмәсен өчен, кеше үтереп сала торган булганнар, дигән юк-бар сүзләр дә йөри. Болар һәммәсе шомлы да, шактый кызык, мавыктыргыч та.

Шулай вәсвәсәләнеп ята торгач, йокыга да киткәнмен. Мин уянганда яңгыр туктаган, таң атып килә иде. Салкынча суда битне-кулны юып алып, балык тота башладым...

Искәрмә: Бу язма кыскартылып дөнья күргәннән соң 18 ел вакыт үтеп китте, күп нәрсәләр үзгәрде. Салавыч тегермәне тартмаса да, буасын саклап, елганы тутырып торган суны басуларга сиптереп торалар торуын, ә менә Яңгулныкы исә җимерелү, тәмам бетү хәлендә: буасы киткән һәм бүтән бөялми, тегермән бөтенләй эшләми генә түгел, бинасы да сүгелеп бара. Әйе, аны каратып тоткан Р. Җамалиев колхоз рәислегеннән киткәч, тегермәнгә дә рәт бетте, Шушма елгасы буенда (ә бәлки, бөтен Татарстандадыр) дөбердәп эшләп торган шушы уникаль корылма яшәүдән туктады. Кызганыч! Ә бит табигатьнең, архитектураның һәм традицион этнографиянең менә дигән истәлеге иде, ничә дистә еллар тирә-юньгә ямь биреп, кешеләргә файда китереп торды. Киләчәк өчен, районның менә дигән тарихи горурлыгы итеп сакларга була иде. Теләгәндә...

«ҮПКӘНЕҢНӘН БИРЛЕ, ӘНКӘЙ...»

Сасна Пүчинкәсе авылына Габдулла Тукай туган көнне — 26 апрельдә чыгып киттем. Шагыйрь һәйкәле янында уздырыла торган традицион шигырь бәйрәмен бик карыйсым килсә дә, Казанда калмадым. Тукай туган көннәрдә, ул яшәп киткән, аның әнисе үлеп калган авылда буласым килде, шул көннәрдә максатыма тизрәк ирешермен төсле тоелды. Шулай булды да! Максатым исә — Г. Тукай әнисе Мәмдүдәнең каберен табу иде. Бу эшне миңа Татарстан Язучылар союзы идарәсе һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тапшырган иде.

Сасна Пүчинкәсе авылы Г. Тукай биографиясенә соңгы елларда килеп керде. «Исемдә калганнар» дигән мәгълүм автобиографик әсәрендә шагыйрь, әтисе Мөхәммәтгариф үлгәч, әнисе Мәмдүдәнең, аны үз авыллары Кушлавычта вакытлыча калдырып торып, Сасна имамына кияүгә чыкканлыгын, бераздан бәләкәй Тукайны үз янына алдыруын,



Балтач районының Сасна Пүчинкәсе авылы. Автор фотосы, 1982

әмма бер елдан үлеп китүен, ә үги әтисенең аны бабасы (әнисе Мәмдүдәнең атасы) Зиннәтуллага кире кайтаруын язган иде.

Г. Тукай турында басылган күп кенә хезмәтләрдә «Сасна нам каръя»не (Сасна исемле авылны) хәзерге Балтач районының Сасна авылы (Зур Сасна) дип язып килделәр. Соңгы елларда журналист Риф Якупов бу мәсьәләгә шактый әһәмиятле төгәллек кертте: республика Үзәк архивында һәм Балтач районы загс бүлегендә сакланган элекке документлар нигезендә, Тукайның әнисе Мәмдүдәнең Сасна Пүчинкәсе дигән авылның Мөхәммәтшакир атлы мулласына 1888 елның 22 декабрендә кияүгә чыкканлыгын һәм шул авылда 1890 елның 18 гыйнварында (яңа стиль белән 30 гыйнварьда) 26 яшендә үлгәнлеген ачыклады. Кечкенә Габдулла исә Сасна Пүчинкәсенә 1889 елның март-апрель айларында килеп, 1890 елның февраль-март ахырларына кадәр, ягъни бер елга якын яшәгән. Әнисеннән Габдулла өч яшь тә тугыз айлык булып ятим калган. Бу хакта Р. Якупов башта Балтач һәм Арча районнары газеталарында, соңра «Казан утлары» (1976, 3 сан) журналында язып чыкты. Шуннан соң бу әһәмиятле биографик вакыйгалар Г. Тукайның 4 томлы «Әсәрләр»енең 1975—1977 еллардагы яңа басмасында беркадәр чагылыш тапты.

Сасна Пүчинкәсе (русча Починок Сосна — рәсми документларда шулай атала) үткән йөзнең урталарында Зур

Сасна авылыннан күченеп утырган кечкенә генә авыл; баштарак Күчкән Сасна, Кече Сасна дип тә йөртелгән. Инеш буенда, яшеллеккә күмелеп утыручы, таза-таза йортлы, бүгенге көндә 27 хуҗалыктан торучы, бер генә урамлы бу бик матур авыл Балтач районының Г. Тукай исемле колхозына керә. Колхозга исә бу исем 1976 елда, шагыйрьнең 90 еллык юбилее уңае белән, авыл халкының, колхозчыларның теләген искә алып бирелә. Сасна Пүчинкәсе Казан артында Тукай тормышы белән бәйле булган, ул яшәгән дүртенче авыл (вакыт ягыннан икенче: Кушлавыч — Сасна Пүчинкәсе — Өчиле — Кырлай).

Шагыйрь әнисенең каберен эзләү һәм табу эшендә район, колхоз һәм авыл советы җитәкчеләре, авыл халкы зур ярдәм күрсәттеләр. Авыл картлары М. Нурмөхәммәтов, М. Хәкимов, Ә. Гыйльманов Тукайның үги атасы Мөхәммәтшакирның гаилә каберен, шул исәптән Мәмдүдәнең дә күмелгән җирен күрсәттеләр. Аларның сүзләре элегрәк яшәгән, тагын да олырак булган картлардан язып алынган мәгълүматларга да туры килә. Бу хакта, шулай ук Мәмдүдәнең кабере өстенә таш кую кирәклеге турында матбугатта язып чыгылды инде (Р. Фәхретдинов. «Бар күңелләрдән җылы...» — «Социалистик Татарстан», 1981, 16 июнь). Сүз уңаеннан шуны әйтеп үтик: Г. Тукайның әнисенә мемориал проекты Махсус фәнни-реставрация мастерскоеның реставрация советында, Татарстан Язучылар союзы җитәкчеләре катнашында тикшерелде һәм бертавыштан кабул ителде (мемориалның авторы — мастерскойның фәнни советы җитәкчесе, архитектор Р. Билалов). Г. Тукайның 100 еллык юбилеен уздыру программасына кертелгән шушы мемориал кую эше якын елларда башкарылачак дип уйларга кирәк[1].

Сасна Пүчинкәсендә заманында бәләкәй Тукай һәм аның әнисе яшәгән йортның язмышы хакында да югарыда телгә алынган мәкаләдә язылды: бу йорт 1916 елда үлгән Мөхәммәтшакирның кече улы Шамил (Мәмдүдәдән соңгы Фатыйма исемле хатыннан туган) тарафыннан Зур Сасна авылына күчерелә һәм шунда бары тик 1964 елда гына сүтелә. Йортның фотосы сакланмаган микән дип, Саснада да, Балтачта да, читтә дә шактый эзләнүләр алып барырга туры килде, әмма көтелгән нәтиҗә булмады. Биредә хөрмәтле әдәбиятчыларыбызның, Тукайның тормышын өйрәнүче галимнәрнең дә игътибарсызлыгын әйтеп үтәсе килә. Кызганычка каршы, тукайчылар ике Саснаның берсендә

[1] Бу эш тормышка ашты — Тукай әнисенең кабере өстенә зур таш куелды.

Сасна Пүчинкәсе авылы зиратында Г. Тукайның әнисе Мәмдүдә абыстайның каберен күрсәткән авыл картлары: М. Нурмөхәммәтов, М. Хәкимов, Ә. Гыйльманов. Автор фотосы, 1981, 27 апрель

дә эзләнүләр алып бармаганнар. Вакытында нәни Тукай, аның әнисе хакында да никадәр истәлек язып алып булган булыр иде.

Соң булса да, уң булсын дигәндәй, андый истәлекләрнең сакланганнарын җыярга тырыштык. Дөрес, алар Тукайны һәм аның әнисен күреп белүчеләрдән алынмады, чөнки андыйлар инде дөнья куйганнар. Әмма шуларны белүчеләрдән ишетү буенча җыйналган кайбер истәлекләр дә кызыклы һәм, әлбәттә, Г. Тукай тормышы өчен әһәмияткә ия. Бу истәлекләр укучы өчен дә кызыклы булыр. 1966 елда Сасна Пүчинкәсе карты Галимов Гайнаннан Субаш мәктәбе директоры С. Федоров язып алган истәлектә түбәндәгеләр әйтелә:

«Мин Габдулла Тукайдан өч яшькә кече, шунлыктан олылардан ишеткән кайбер нәрсәләрне генә әйтә алам:

Беренчесе. Минем ишетүем буенча, Шакир мулла Мәмдүдә абыстайны җәберләп торган, хәтта аның үлүенә дә шул сәбәпче булган, дип язалар. Бу турыда минем Мәмдүдә абыстайда укыган, үзебезнең авылда туып үскән Вильдан кызы Гыйльмивафадан сораганым бар. Ул әлеге фикерне кире какты. «Абыстай ишегалдына чыкканда да, перчатка киярга куша иде, кулың ярылмасын, дип әйтә

Г. Тукайның әнисе Мәмдүдә. Шагыйрьнең бертуган апасы Газизә Зәбирова истәлекләре буенча аның кызы Ә. Зәбирова ясаган рәсем

иде. Мулла абзый аны бик ярата иде һәм тату яшиләр иде»,— диде. Гыйльмивафа Казанда яшәде. Ул хәзер исән түгел инде.

Икенчесе. Минем әтиемнең энесе Мөхәммәтша Ибраһим улы, балалары булмау сәбәпле, хатыны белән сөйләшеп, Шакир хәзрәттән ятим калган Габдулланы үзенә балалыкка бирүне сораган. Ләкин мулла абзый: «Габдулланың бабасы да, әтисе дә муллалар булган, мин аны бабасына тапшырырга тиешмен»,— дигән».

Шул ук Гайнан бабай һәм башка олы кешеләрдән колхозның элекке председателе Х. Борһанов ишетүе буенча, Мәмдүдә бик чибәр булган, аны «матур абыстай» дип йөрткәннәр. Тукай үзе моңлы бала булып хәтердә калган, әнисе үлгәч тә, авылдан китәргә теләмәгән. Бу хакта безгә дә авыл халкыннан кайбер нәрсәләр ишетергә туры килде. Хәдичә апа Мөхәрләмованың сөйләве буенча, аның бабасы Нури Тукайны яхшы хәтерләгән, алай гына да түгел, Тукай шул авылда яшәгән елның җәен алар бергә уйнап уздырганнар. Нури олырак булса да, Габдулла аңа нык иярләшеп киткән, ә инде әнисе үлгәч: «Нури абый, мин сездә генә калыйм инде, әтиеңә әйт әле, зур үскәч, мин аның эшләрен дә эшләр идем»,— дигән. Кушлавычның Шәрифә карчыкта кагылып-сугылып яшәвен онытмаган шушы үксез баланың каядыр кеше кулына барып керәсе килмәгәндер, күрәсең. Өчиледәге үги әбисенең «алты күгәрченнәре» арасына «бер чәүкә» булып кайтып керәсен сизгән диярсең...

«Туктале, Бәдәр апа Тукай турында сөйли иде, ул миннән олы, күбрәк хәтерли»,— дип, Хәдичә апа мине күршеләренә алып керде. Бәдәр апа Гобәйдуллинаның кунаклары бар, мәшәкатьле чагы, бераз какшабрак та тора.

Әмма минем Тукай турында кызыксынып йөрүемне белгәч, дәртләнеп китте, кайбер хатирәләрен искә төшерде. Аның әти-әнисе кечкенә Тукайны күреп белгәннәр, аның турында еш кына сөйли дә торган булганнар. Өйләренең урам як тәрәзә төбендә, тезләрен чәнчеп, еш кына көйләп-такмаклап утыруын яхшы хәтерләгәннәр. Нәни Габдулла 3—4 яшендә генә булуга карамастан, ниндидер мәгънәле сүзләр көйләгәндер, ахры, чөнки ул сүзләргә игътибар иткәннәр. Бәдәр апаның әтисе ул сүзләрне исендә калдырган, аларны еш кына кабатлый торган булган. «Аларны мин дә белә идем, хәтердән чыгып киткән, искә төшкәч язып куярмын, икенче бер әйләнсәң, кереп чык»,—диде Бәдәр апа. Мин кабат Сасна Пүчинкәсенә килгәндә, ул дөнья куйган иде инде...

Шушы кечкенә генә хатирә Тукайның рухи халәтенә хас үзенчәлекләрнең бик кечкенәдән үк аерылып торуын күрсәтә сыман. Ул үзенчәлекләр Тукайның бөтен гомере буена баргандыр. Аның апасы (ата бер, ана башка) Газизә Зәбирова Тукайның Уральскидагы тормышыннан мондый бер истәлек бирә:

«Габдулла күп вакытларын, түбән өй тәрәзәсеннән карап, уйланып утыра торган иде. Күргән кешеләрнең күбесе: «Бу бала туган илен сагына торгандыр»,—ди торганнар иде. Шулай тәрәзә төбенә утырып, китап уку гадәте дә бар иде»[1]. Сабакташларының истәлеге буенча, Тукай, Уральскида мәдрәсәдә, үзе кебек үк шәкертләрне җыеп, халык әкиятләре сөйләгәндә яки кичәләрдә җырлаганда, һәрвакыт ике тезен кочаклап утырган килеш сөйли-җырлый торган булган[2]. Тукайның якын дусты Каюм Мостакаевның шагыйрьнең Казандагы тормышын тасвирлаган истәлегендә мондый юллар бар: «Тукай, кичләрен ятар алдыннан яки иртә белән уянгач, караваты өстенә тезләрен кочаклап утырып моңланырга, үзе яраткан шагыйрьләрнең кайбер шигырьләрен, өзекләрен, бала тибрәткәндәге кебек, йомшак-нәфис тавыш белән көйләп утыруны ярата торган иде»[3]. Тукайның Клячкин больницасында үләренә бер тәүлек кала алынган мәгълүм фоторәсемен искә төшерик. Караватында тезләрен кочаклап тәрәзәгә карап утырган, дөньядан китеп баручы шушы бөек шәхеснең күзләрендә никадәр моң, никадәр сагыш! Дүрт яшен дә тутырмыйча ятим калып, газиз әнкәсенең назын күрми, кулдан-кулга, өйдән-өйгә йөреп үскән үзенең кыска гына михнәтле тор-

[1] Тукай турында замандашлары. Казан, 1960, 43 бит.
[2] Шунда ук, 52—53 битләр.
[3] Шунда ук, 126 бит.

мышын, газиз әнкәсен исенә төшермәгәндер дисеңме аны? Әлбәттә, төшергән.

Тукайның әнисе белән аерылышу көннәрен болайрак күз алдына китерергә мөмкин булыр иде.

Каты авырып, Мәмдүдә урын өстендә, хәл эчендә ята, көннәр үткән саен хәле начарлана гына бара. Соңгы көннәре килеп җитүен сизенеп, әледән-әле Габдулланы янына чакыртып ала. Баласының башыннан сыйпап, көчсезләнгән куллары белән күкрәгенә кыса, күзләреннән үбә. Бала күңеле сизмәсен, дип күнме генә тырышса да, яшерә алмый, күзләреннән мөлдерәп яшь ага... Булмады, бердәнбер баласын үзе үстерә алмады, нинди ятлар кулына гына калыр бу нарасый, сабый бала...

Мәмдүдәнең хәле кинәт авыраеп, өйдә ыгы-зыгы куба. Хәлнең ышанычсызлыгын күреп, Габдулланы әнисе янына китерәләр. Соңгы күз яшьләре, соңгы үбү. Иреннәр соңгы тапкыр пышылдый: «Хуш, балам, бәхил бул, рәнҗемә». Габдулла үксеп, әнисенең күкрәгенә каплана...

Шушы үзәк өзгеч авыр вакыйганы Тукайның үз сүзләре белән тәмам итәсе килә: «...әнкәмнең җиназасын күтәреп алып киткәннәрен сизгәч, яланаяк, яланбаш хәлемдә, капка астыннан, үкереп елый-елый, йөгереп чыгып: «Әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез! — дип шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганымны хәзер дә тәхаттыр иткәнемне (хәтерләвемне) язамын»[1].

Кыска булды шул әнисенең гомере, 26 яшьтә китеп барды. Ә үзенеке? Менә 27 не дә тутырмыйча... Тукай шуннан өч ел гына элек, 1910 елда язган «Өзелгән өмид» дигән шигырен искә төшерә:

И мөкатдәс моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?
Син сынасың, мин сүнәмен, айрылабыз ахрысы!..

Дөнья читлегеннән тарсынып очып китүче күңел кошы... Их, аз сайрады шул ул! Мәхәббәте тагын, кабынды да...

Булмадың алтын ярым, салкын ярым, син дә минем
Бер тәбәссем[2] берлә дә тормыш юлым яктырткычы!

Тагын әнисе, аның күз яшьләре, соңгы тапкыр үбүе искә төшә:

Күз яшең дә кипмичә еглап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!
Үпкәнеңнән бирле, әнкәй, иң ахыргы кәррә[3] син,

---

[1] Тукай. Әсәрләр, IV том. Казан, 1956, 13 бит.
[2] Тәбәссем — елмаю.
[3] Кәррә — тапкыр, кат.

Һәр иштектән сөрде углынны мәхәббәт сакчысы,
Бар күңелләрдән жылы, йомшак синең кабрең ташы,
Шунда тамсын күз яшемнең иң ачы һәм татлысы!

Соңгы юлларын әнисенә багышлап, аның якты истәлегенә дан җырлап язган үлемсез әсәр бу. Кара реакция чорында, бик күпләрнең җан газабына дучар булган авыр заманда иҗат ителгән бу атаклы шигырь, әнисенең соңгы тапкыр үпкәненнән бирле иркәләүгә, мәхәббәткә гаҗиз булып, ана каберен бар нәрсәдән дә якын күреп, өзелеп әйткән гыйбрәтле бу сүзләр тирән бер моң булып, мәрхәмәтле баланың үз әнисенә белдергән чиксез мәхәббәте буларак кабул ителәләр.

«Азат хатын»,
1982, 11 сан.

ХАЛЫК КӨЙЛӘРЕ ҺӘМ ИЛҺАМ ШАКИРОВ

Ишеттем мин кичә: берәү җырлый
Чын безнеңчә матур, милли көй;
Башка килә уйлар төрле-төрле, –
Әллә нинди зарлы, моңлы көй.

Халкыбызның борынгы җыры «Әллүки»не ишетеп язган Габдулла Тукайның әлеге сүзләре Илһам Шакиров җырлавына да бик туры килә. Аның башкаруында бу илаһи моң күңел түренә үтеп керә, гаять хисләндерә.

Халкыбызның иң моңлы көйләреннән шактые Тукай сүзләренә җырлануда зур бер мәгънә, символика бар. Халык күңеле сизгәнне өзелеп-өзелеп әйтеп бирә алган бөек Тукай сүзләреннән башка без борынгы көйләребезне, аларның бөтен гүзәллеген аңлап бетерә алмас идек шикелле. Бу җырларда гасырлар буена изелеп килеп тә, үз йөзен, үз моңын югалтмаган халыкның рухи батырлыгы яңгырый. Әйе, һәрберсеннән нечкә сагыш, тирән моң бәреп торган, халкыбызның үзе кебек үк озын гомерле «Әллүки»ләребез, «Зиләйлүк»ләребез, «Тәфтиләү»ләребез, «Туган тел»ләребез бар безнең.

Ә халкыбызның үз сүзләренә җырлана торган, буыннан-буынга тапшырылып килгән борынгы җырларыбыз күпме! «Кара урман», «Гөлҗамал», «Кәләү Гайшә», «Зөбәрҗәт», «Тәзкирә», «Салкын чишмә», «Бөдрә тал», «Сакмар», «Уел» һәм башка гүзәл җырлар. Тукай сүзләре белән әйткәндә, «бабаларыбыз тарафыннан калдырылган иң кадерле вә иң бәһале бер мирастыр», «халкыбыз күңеленең һич тә тутыкмас вә күгәрмәс саф вә раушан көзгеседер. Бу — бертөрле сихерле көзгедер. Чөнки халыкның

бер генә җыруын тотып нечкәләсәң, шөбһәсез, аның халәте рухиясен, нәрсә уйлаганын вә ни хакында нинди фикердә икәнен белеп буладыр».

Хак әйтелгән, бөек сүзләр. Нәкъ менә борынгы көйләр халкыбыз тормышының катлаулы үсеш баскычларын, аның социаль-политик аңы һәм психологиясенең формалашуын, иҗтимагый көрәшен чагылдыралар. Борынгы җырлар — бай һәм катлаулы тарихы булган халкыбызның, аның рухи культурасының кадерле ядкарьләре, энҗе-җәүһәрләре генә түгел, ә шул культураның тирән тамырларын ачыклауда, халыкның этник һәм психологик үзенчәлеген билгеләүдә зур роль уйнаучы кыйммәтле чыганаклар да.

Бер генә җырга мөрәҗәгать итеп карыйк. Ул да булса — халкыбызның иң гүзәл җырларыннан саналган «Кара урман» («Иске кара урман»).

Кара да гына урман, караңгы төн,
Яхшы атлар кирәк лә үтәргә.
Кара урманны чыккан чакта,
Кисеп алдым куш каен,
Ай, аерылмаек, дускаем.

Җырның ачынулы сүзләренә һәм тирән моңына карaганда, ул шактый борынгы булырга охшый, һәм ул халык өчен иң авыр заманда, тарихның иң дәһшәтле, иң әрнүле чорында тугандыр, дигән фикер уята. Кара урман төшенчәсе тирән философик, социологик төшенчә итеп, халыкның авыр көннәрдәге шомлы, караңгы тормышын чагылдыру символы булып кабул ителә.

Заманалар авыр, еллар ябык,
Дус-иш кирәк гомер итәргә,—

дигән сүзләрне нәкъ менә шундый фаҗигале заманда барлыкка килгән дип кенә аңлап була. «Төн караңгысы басып яткан кара урман эченнән нинди үзәк өзгеч авыр моң, нинди дәһшәтле ялгызлык бәреп чыга», — дип язган иде бу җыр хакында өлкән язучыбыз Гомәр ага Бәширов. Әйе, ялгызлык күңелдә авыр яра булып калган. Тик бу халыкның киләчәккә өметләре зур әле:

Кара да гына урман, караңгы төн.
Нинди юллар белән лә үтәрбез.
Дус-иш белән бергә эш иткәндә
Теләкләргә тизрәк җитәрбез.

«Кара урман» көе күпме генә җырчы һәм музыкантны, башкаручы коллективны илһамландырмаган! Зөләйха Әхмәтова җитәкчелегендәге Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең хор группасы шушы җырны башкаруның бик

матур үрнәген биргән иде. Ансамбльнең «Кара урман»ын тыңлаганда, халыкның үткәндәге шомлы көннәре дә, аның киләчәккә булган якты хыяллары да күз алдына килә. СССРның халык артисты, композитор Нәҗип Җиһановның «Татар халык көйләренә сюита»сының икенче кисәге дә «Кара урман» көенә нигезләнгән. Симфоник оркестр башкаруында бу көй кара урманның кырыс табигате фонында халыкның үткән тарихына бер күз салу һәм якты тормыш символы булып яңгырый. Илһам Шакиров соңгы елларда бу җырны берниндн аккомпанементсыз, ялгызы гына җырлап, аңа икенче бер төсмер һәм яңгыраш бирде. Илһам тавышы караңгы төндә калын һәм кара урман аша атка утырып барган ялгыз егетнең моңлы авазы булып ишетелә, халык әйтергә теләгән уйларны, аның изге хисләрен ачып бирә.

Илһам Шакиров турында китап басылып чыгу уңае белән олы шагыйребез Сибгат ага Хәким мондый сүзләр әйткән иде: «Шигырь тирәсендә күпме бәхәс ишетмәдем мин. Шигырьдә фикерме, имеш, хисме? Шундый чакта минем кешеләрне бәхәстән бүлеп, Илһам Шакировтан «Кара урман»ны җырлатасым килә. Тыңла, онытыл. Бәхәсләр мәгънәсез булып кала... Бар да үз урынына кайта, ачыклана».

Хор җырлыймы, симфоник оркестр яки ялгыз җырчы башкарамы — «Кара урман»нар гади тыңлаучыда да, профессиональ музыканың нечкәлекләрен аңлаган сәнгать кешеләрендә дә тирән эстетик тойгы уяталар. Ә халыкның мондый үлемсез әсәрләрен башкаручылар олы ихтирамга лаек булып кына калмыйлар, бәлки искиткеч тирән эчтәлекле һәм катлаулы музыкаль алымнарга бай булган мондый җырларны башкарып, үзләренең осталыкларын тагын да үстерәләр.

Татар халык көйләрен, бигрәк тә борынгы җырларны башкаруда Илһам Шакиров аерым бер урын алып тора. Үзенә генә хас моңлы һәм көчле тавыш, туган халкыбызның рухи дөньясын бөтен йөрәге белән аңлау һәм шуны җыр аша ачып бирә белү, ниһаять, көйне башкару осталыгы — менә бу сирәк очрый торган сыйфатлар Илһамга татар көйләренең бөтен тирәнлеген һәм эмоциональ матурлыгын җиткерә алырга мөмкинлек бирделәр. Илһам Шакиров иҗатын татар халык җырларын башкаруда, шөбһәсез, аерым бер чор итеп карарга була. Гомумән, Илһам халык җырларының фәлсәфи тирәнлеген, эстетик югарылыгын, кайнар хисен һәм моң-сагышын ачып бирүдә моңарчы берәү дә ирешмәгән, гаҗәеп зур уңышларга иреште.



Илһам Шакиров

Татар халык көйләре һәм Илһам Шакиров иҗаты турында сүз алып барганда, тагын бер мәсьәләгә тукталып үтәсе килә. Халык иҗатыннан көч һәм илһам алып, борынгы җыр-көйләребезне туплау, һәм кире халыкка кайтаруда заманында Габдулла Тукай, Заһидулла Яруллин, Фәттах Латыйпов, Фәйзулла Туишев, Исмәгыйль Мусин, соңрак Александр Ключарев, Җәүдәт Фәйзи, Гөлсем Сөләйманова, Фәйзи Биккинин, Заһид Хәбибуллин, Рокыя Ибраһимова һәм башка шагыйрьләр, композиторлар, музыкантлар, җырчылар ифрат мактаулы, изге эш эшләделәр. Бу күркәм традицияне Илһам Шакиров дәвам иттерде. Моңлы тавыш белән җырлау һәм киң популярлык, халыкның сөйгән җырчысы булу Илһамга борынгы җырларыбызны яңадан халыкка җиткерүдә гаять зур мөмкинлекләр тудырды. «Син сазыңны уйнадың», «Туган ил», «Кораб», «Каръят батыр», «Җиһанша», «Бик еракта идек без», «Әнкәм кабере янында», «Маһирә», «Озын су өсте» кебек бүгенге тыңлаучы өчен яңа булган, әмма заманында халык арасында киң таралган, тик ниндидер сәбәпләр аркасында онытылып торган җырларны Илһам үзе яки башка җыр сөючеләр ярдәмендә эзләп тапты, беренче булып башкарды һәм халык тарафыннан җылы кабул ителгән бу матур көйләребезгә икенче тормыш, яшәеш бирде. Моның белән ул җыр-музыка ятучыларны гына шатландырып калмады, ә профессиональ музыкантлар, композиторлар иҗаты өчен, гомумән, сәнгатебез һәм рухи культурабыз өчен иҗтимагый әһәмияткә ия булган зур, мактаулы эш эшләде.

Илһам Шакиров иҗаты турында сөйләгәндә, бер хатирәгә урын бирәсе килә... Җылы август киче иде. Без, Кама

елгасы буенда борынгы истәлекләрне өйрәнеп йөрүче бер төркем археологлар, көне буе эшләгәннән соң, лагерьга кайтып киләбез. Лагерь дигәнебез, өсте ябулы бер машина да, аның янында ялгыз палатка. Ерактан күренгән учак төтене безнең арыган аякларыбызга хәл кертеп җибәргәндәй итте. Килеп җиткәндә, шоферыбыз мәж килеп, кичке аш пешерү эшләрен хәстәрләп йөри иде. Тиз генә елга суында юынып алдык та аш белән ботка да пешереп ташладык. Без ашап бетергәнче караңгы төшеп өлгерде. Әмма аңа карамыйча, учак яктысында гына чәй эчәргә тотындык. Билгеле, чәйне аны эчмәгән кеше юк, ләкин менә елга үзәнендә, учак янында кырын ятып, калай кружкалардан авызны пешерә-пешерә эчкән чәйдән дә тәмлерәге булыр микән? Җитмәсә, бөтен тирә-юньне ниндидер бер моң чолгап алган. Тукта, нәрсәсе моңлы соң әле бу кичнең — тау өстендәге зиратның карт каеннарымы, бормаланып аккан елгамы, әллә күтәрелеп килүче тулган аймы? Әйтерсең, ул бөтен нурын безнең өскә генә яудыра...

Ул арада Казаннан кичке концерт башланды. Татар халык көйләре. Менә сиңа мә — моң өстенә моң! Килсә дә килеп тора бит...

Фортепьянода ярсулы кереш. Аңа җырчының көчле тавышы кушыла:

Шаулый диңгез...
Җил өрәдер...
Җилкәнен киргән кораб!
Төн вә көндез
Ул йөзәдер:
Юл бара, ят ил карап...

«Кораб» җырының үзәгендә күп газапларга дучар булган татар язмышы... Аны икенчесе алмаштыра. Бусын инде баяннар башлап җибәрә, аларны шул ук җырчының ягымлы, моңлы тавышы күтәреп ала:

Китми күңелемнән һич
Шул сөекле илкәем;
Анда минем сөйгән халкым,
Анда сөйгән әнкәем...

«Туган ил». Туган җиреңне өзелеп сөю, ярсып сагыну хисе. Бу көйләрне чит илләрдә каңгырып йөреп тә, бәхет таба алмыйча, үз илләрен сагынып кайткан татар егетләре алып кайтканнар. Туган якларын, җирен сагынып газапланган кешеләр мондый көйләрне чыгарганда юкка гына Дәрдмәнд һәм Исәнбәтнең гыйбрәтле сүзләрен сайлап алмаганнардыр. Илһам башкаруында шушы ике җыр бербөтен булып кабул ителде, алар туган ил, туган туфрак төшенчәсен бөтен тулылыгы белән ачып биргәндәр сыман

тоелды. Күзгә йокы кермәде. Әле лагерь йокыга яткач та, елга буйлап озак кына йөрдем.

Ай тагын да югарыга менде, үзәнне сыек томан каплап алды. Бөтен тирә-юнь ниндидер сихри тынлыкка чумды. Ерактарак, тау итәгенә урнашкан Укмас авылында да утлар сүнде.

Укмас — шагыйрь Укмасыйның туган авылы. Ничек дигән әле ул:

...Җырлар идемме җырымны,
Ил өчен җан янмагач?!

Ил өчен җан янмагач! Гаҗәеп мәгънәле сүзләр! Алар, әйтерсең, бөтен йөрәге белән илен һәм халкын сөюче Илһам җырларына карата язылганнар. Әйе, ул җырлаганда, туган ил бөтен гүзәллеге белән күз алдына килеп баса. Туган ил ул — иң әүвәл туган туфрак, газиз ата-ана, син дөньяга килгән авыл, аның гөрләп үскән иген басулары, шау чәчәкле болыннары, серле кара урманнары, тау астында челтерәп аккан чишмәләре, суларында колач салып йөзгән елга-күлләре, моңсу таллар әйләндереп алган тегермән буалары, айлы төндә ат саклаганда сөйләгән тылсымлы әкиятләре, кояш нуры белән тулы зәңгәр күге, күңелләргә дәрт өстәүче иртәнге тугайлары, моңсызларга моң бирүче кечкенә сандугачлары, чиләкләп койган җылы җәйге яңгырлары, колак яфракларын өшетерлек кышкы салкыннары, күз ачкысыз бураннары. Ул — авылның күпне күргән әби-бабайлары, дөнья җимертеп эшләп йөрүче агайлары, апалары, яшь егетләре һәм кызлары, ул аның нарасый балалары. Ул — тирә-якны шау китергән җәйге сабан туйлары. Ул — тальян гармуннарның үзәк өзгеч моңнары...

Илһам Шакиров иҗаты турында сүз барганда, аның башкаруында кабатланмас яңгыраш тапкан авыл көйләрен дә искә алмый мөмкин түгел. Әйе, безнең күңелләргә балачактан кереп урнашкан, һәрвакыт туган-үскән җирләребезне искә төшереп һәм шунда чакырып торучы җанга якын, газиз авыл көйләре... Борын-борыннан җыен һәм сабан туйларында, аулак өй һәм мәҗлесләрдә, бәхет эзләп чит җирләргә һәм солдатка чыгып киткәндә, туган илләргә кайтып кергәндә җырланган моңлы да, дәртле дә авыл көйләре. Шул авыл көйләренә җырлап печәнгә төшкәннәр, тула сукканнар, каз өмәләре үткәргәннәр, кыз биргәннәр, өйгә килен төшергәннәр. Кайчан гына, кайда гына җырланмаган да һәм хәзер дә кайда гына җырланмый ул авыл көйләре! Менә кичке айлы төндә авылның бер башында кемдер авыл көенә тальянын сызып җибәрә, аңа кушылып җыр башлыйлар, урамны иңләп узалар. Йоклый алмый

яткан һәм йокыларыннан уянган әби-бабайлар, апа-жингиләр яшьлекләрен искә төшереп, бер моңаеп алалар, күз читләрен сөртеп куялар. Сөйгән ярлар исә, булачак кавышу хыялына чумып, әкрен генә тагын йокыга талалар. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай. Миңа калса, безнең агай-энедә җыр-музыкага мәхәббәт әлеге шул тальян моңнарыннан, җанга якын авыл көйләреннән башланган. Нинди генә авыл көйләре булмаган һәм юк бездә, санап очына чыга алмассың! Әле теге яки бу авылга, аның тирә-юненә генә таралган көйләрдән башка, бөтен халыкка мәгълүм җырлар булып киткән «Сарман»нар, «Минзәлә»ләр, «Шөгер»ләр, «Арча»лар, «Әтнә»ләр, «Наласа»лар... Аннан килеп «Күн авылы», «Өнсә», «Безнең авыл» көйләре. Болары инде — чын мәгънәсендә «Илһам җырлары», ул күтәреп алып җырлый башлаган һәм башкаларны авыл көенә җырларга кабат дәртләндергән җырлар. Әйе, әйе, Илһамнан отып алып, шушы җырлар җырланмаган авыл һәм шәһәр сәхнәләре, сабан туйлары, кунак ашлары, туй мәҗлесләре юктыр хәзер. Гомумән, авыл җырларын зур театр һәм концерт залларында, телевизор экраннарында яңгыраткан, радио дулкыннарында тибрәткән Илһамга туган-үскән җиренә мәхәббәт саклаучы һәр изге җанның рәхмәте чиксез зур.

Халык көйләрен башкаручыларны һәм иң беренче чиратта Илһам Шакировны тыңлаганда, ирексездән, Габдулла Тукайның «Халык әдәбияты» дигән мәгълүм лекциясендә сөйләгән сүзләре искә төшә: «Безнең халыкның җырлау вә көйләвендә, минемчә, үзенә бертөрле хосусият бар кеби.

Башка милләтләрдә булдыгы кеби, бездә калын тавыш илә вә мөмкин кадәр көчләнеп вә авызны бик зур итеп ачып җырлау бер дә мәкъбүл түгел. Бездә җырланган чакта тавышның йомшак булуы вә бераз уен коралы авазына охшашрак булуы вә иреннәрнең дә мөмкин кадәр аз ачылуы мәкъбүл вә мөхтәхсән (кабул ителгән һәм күркәм) күрелә. Мәсәлән, мин дөм чукрак булып та, җырлап утыручы бер татарның авызына карасам, мин аны җырлый дип белмәс, бәлки бернәрсәне кызу-кызу сөйли икән дип хөкем итәр идем.

Минем исемдә калган: мәдрәсәдә чакта һәр шәкертнең хәсне тәвәҗҗеһен җәлеп иткән (яхшы карашын казанган) бер җырлаучы, үзенең иренен каты кәгазь сыярлык итеп кенә ачып, озын вә кыска көйләрне җырлап җибәрә иде. Аның шулай мыек астыннан гына җырлавы безнең хушыбызга бигрәк китә иде.

Безнең бер көйне руслар арасында бик яхшы тавышлы саналган бер кешедән җырлатсаң, әллә ничек шуның без-

нең күңелгә ошарына күңел ышанмый. Көебезнең алтынын кояр шикелле тоела»[1].

Бөек шагыйрь булуы һәм халык иҗатын тирәнтен белүе өстенә, Тукай үзе дә кече яшьтән җырчы булган, моңлы итеп җырлаган; аның җырлавын ярата, кат-кат җырлата торган булганнар. Шуңа күрә дә халык көйләрен башкаручыларга карата аның таләбе зур булган. Ул моңлы, матур итеп җырлаучыларга зур бәя биргән, ә инде «бер тыңласаң, мәче тавышы, бер тыңласаң, майланмаган арба тәгәрмәче тавышы» китереп җырлаучыларны каты тәнкыйтьләгән. Шулай дип фараз кыласы килә: әгәр дә Тукай исән булса, көйләребезнең «алтынын коймыйча» җырлаучы Илһамны тыңлап, чиксез шатланыр иде, аның башыннан сыйпап, олы рәхмәтен әйтер иде.

Татар халык көйләре һәм аларны башкару осталыгы турында сүз алып бару, иң беренче чиратта, Илһам Шакиров иҗаты турында сөйләү булыр иде. Һәм киресенчә: Илһам Шакиров турында сөйләү — халкыбыз җырлары һәм аларны башкару осталыгы турында сүз алып бару булыр иде. Әлбәттә, татар халык көйләре һәм аларны башкаруга кагылышлы мәсьәләләр күп һәм барысы да хәл ителгән дип уйларга һич тә ярамый. Әйтик, безнең татар җырларына хас булган моң проблемасы. «Моң» төшенчәсенә әле берәүнең дә төгәл генә аңлатма бирә алганы юк. Бу төшенчәгә бер-ике сүз белән генә билгеләмә бирү, гомумән, мөмкин булмаган нәрсә. Моң ул — халыкның рухи халәтенең бер хосусияте, үзенчәлегедер. Алай гына да түгел, бу моң шул халыкның бөтен яшәеше, рухи байлыгы белән билгеләнәдер. Тукай да бит үзенең кыска гына гомерен мөкатдәс бер моңлы саз дип атаган. Фашист палачлары алдында тез чүкмәгән, корыч ихтыярлы батыр Муса Җәлил: «Гомерем минем моңлы бер җыр иде», — дип язган. Әгәр дә җыр язмышы ил язмышы белән бәйләнә икән, әгәр дә шул җыр ил язмышында булган әрнүле һәм шатлыклы вакыйгаларны дөрес чагылдыра һәм халык күңеленә кереп урнашкан хисләрне бөтен тулылыгы белән әйтеп бирә ала икән, ул җыр зур бер моң булып кабул ителә. «Көй — күңелнең моңы», — дип юкка гына әйтмәгән безнең халык. Хәлбуки, ул моңны бөтен тулылыгы белән бирә алу өчен җырчы тавышының моңлы булуы да бик зарури. Ни өчен Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов, Зифа Басыйрова, Фәридә Кудашева, Илһам Шакиров, Әлфия Афзалова, Габдулла Рәхимкулов, Таһир Якупов, Зөһрә Сәхәбиева, Флера Сөләйманова, Рафаэль Ильясов җыр-

[1] Г. Тукай. Әсәрләр, 2 том, Казан, 1955, 271—272 битләр.

лары халык күңеленә аеруча үтеп керәләр? Чөнки аларда моң бар, чөнки алар халык күңеленең көзгесе булган халык көйләренең рухын, шул рухны тоеп язган Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Александр Ключарев, Заһид Хәбибуллин, Сара Садыйкова, Рөстәм Яхин һәм башка композиторларыбыз әсәрләрендәге моңны бирә алалар.

Тыңласаң жыр, тыңла моңлылардан,
Моңлы җырлар кала ла йөрәктә,—

дип дөрес әйткән безнең халык.

Гомумән, моң ул — ата-бабаларыбызның күңеленнән, үзебезнең туган җир һәм туган туфрагыбыздан шытып чыккан, гасырлар буена сөйгән халкыбыз тарафыннан кадерләп үстерелгән олы хис. Моң — кешенең күңелендә булган шул олы хисне әйтеп бирә белү. Ә җырчы тавышы өчен — шул көйне «алтынын коймыйча» башкара алу.

Шушы зур булмаган язмабызның ахырына якынлашканда, тагын бер-ике мәсьәләгә игътибарны юнәлтик. Илһам Шакиров халкыбызның күп кенә җырларын бик яхшы башкарды, аларның язмалары алынды. Әмма Илһам җырламаган, аның тавышын көтеп ятучы җырлар шактый әле. Әйтик, «Гөлҗамал», «Сибелә чәчәк», «Зөбәрҗәт», «Ишкәкче карт җыры», «Шахта», «Су буйлап» («Идел бит ул») һәм башка шуның кебек гүзәл җырларны аның башкаруында ишетәсе килә. Инде булган язмалар өстенә яңалары өстәлеп, халкыбыз җырларын классик башкаруның зур бер җыелмасы эшләнер иде һәм ул язмалар, һич шик юк, Татарстан радиосы һәм телевидениесенең алтын фондын тәшкил итәрләр иде. Бу киләчәк буын тыңлаучылары өчен дә, сәнгать белгечләре һәм фольклорчылар өчен дә халык җырларын нәкъ менә классик башкару үрнәкләре булып калыр иде.

Бик яхшы хәтерлибез: 1968 елның язында, Тукайны искә алган көннәрдә, радио аша Илһам Шакировның бөек шагыйрь сүзләре белән исемләнгән «Халык җырлары — халык күңеленең көзгесе» дигән концерт-әңгәмәсе яңгырады. Үзе язган, үзе алып барды, үзе җырлады. Бая телгә алынган «Кораб»лар, «Туган ил»ләр, «Маһирә»ләр кебек уннан артык җыр яңгырады, һәрбер җырның табылу тарихы яки үзенчәлеге турында кызыклы мәгълүматлар бирелде. Халык моңнарына искиткеч зур мәхәббәт белән үткәрелгән ул әңгәмәдән соң радиокомитетка, Илһамның үзенә мең төрле рәхмәтләр әйтеп, дистәләрчә хатлар килде. Бер ел да узмады, 1969 елның январь аенда Казанның театр һәм культура сарайларында Илһам Шакировның «Татар халык

җырлары» исемле концертлары булып узды. Гаҗәеп салкын көннәр булуга карамастан, концертларга халык агылып торды, артык билет табып булмады. «Бис»кә чакырып җырлатуларны да санасак, концерт саен 30 лап җыр җырланды. Исең китмәле: бер тын алу белән дип әйтерлек җырланган 30лап җыр! Борынгылары да, яңалары да. Һәрбер башкарылган җырдан әйтеп бирә алмаслык тирән моң бәреп торган шушы онытылмаслык концертлардан халык тыныч кына тарала алмый иде. Ул вакытта Илһам Шакиров иҗаты турында яза башлаган бер кеше буларак, мин кызыксынып, халыкның мөнәсәбәтен, фикерен белергә теләп, концерт барышында әкрен генә тирә-ягыма каранып ала идем — бөтен зал «тын да алмый» тыңлап утыра, күпләрнең күзләрендә соклану билгесе, шатлык яшьләре; концерт тәмам булып, халык таралышканда, шунда буталган булып, сүзләренә колак салам — җырчы адресына чын күңелдән, йөрәк түреннән чыккан рәхмәт сүзләре, җырларыбыз белән горурлану хисләре. Татар җыр сәнгате тарихында беренче тапкыр эшләнгән, бик озакка истә калырлык тапшыру һәм концертлар булды алар.

Ул көннәрдән соң 13—14 ел вакыт үтеп китте. Хәзер инде халкыбыз яңадан андый җырларга сусап өлгерде. Ул темага әйләнеп кайтырга, халык җырларына багышланган концертларны яңартырга да вакыт җитте сыман. «Ул заманда Илһамга 32—33 яшь иде, хәзер 45 не узып китте, аның өчен зур концертлар бирү авыр инде»,— дип шикшөбһә белдерүчеләр дә булырга мөмкин. Әмма алар фикере белән килешү кыен. Илһамның потенциаль мөмкинлекләре әле бик зур, һәм ул халык җырларына багышланган махсус концертлар биреп, меңләгән тамашачыларны, җырга гашыйкларны кабат шатландырыр, әлбәттә.

Әйтеп үтелгән тапшыру һәм концертлардан соң бераз ара калдырып, радиодан Илһам Шакировның тагын бер концерт-әңгәмәсе яңгырады. Дөресрәге, бу Илһамның үз концерты түгел, ә танылган җырчы Фәридә Кудашева турында ул әзерләгән тапшыру булды. Халыкның мәхәббәтен казанган җырчы турында бик матур, җылы хисләр белән язылган, аның күп кенә язмаларын керткән әйбәт концерт-очерк булды ул. Иң әһәмиятлесе шунда — халык җырчысы турында халык җырларын башкаруның бөтен нечкәлекләрен үзләштергән оста сөйләде. Мондый тапшыру тыңлаучыга, әлбәттә, бик көчле тәэсир итә.

Ниһаять, соңгысы. Шул ук 60 нчы елларда Илһам Шакиров республикабызның газета-журнал битләрендә җыр-музыка, башкаручы коллективлар һәм аерым җыр-

чылар турында очерк-мәкаләләр белән бик еш чыгыш ясады. «Халык моңнары», «Дусларга бер-ике сүз», «Эзләнү — иң яхшы юлдаш» исемле һәм башка язмаларында татар һәм башкорт көйләрен пропагандалау, аларны башкару үзенчәлегенә бәйле мәсьәләләрне күтәреп чыкты. Ул язмалардан Илһамның халык җырларын өйрәнү өлкәсендә киң эрудицияле, оста каләмле белгеч икәне дә күренде. Еллар үткән саен, тәҗрибә туплана, фикер камилләшә, каләм шомара. Шуңа күрә, ул мәсьәләләргә кабат әйләнеп кайтып, күләмлерәк әйберләр эшләргә вакыт җитте кебек. Әйтик, классик көйләр булып киткән әсәрләр, бигрәк тә борынгы җырлар, аларның туу һәм халыкка таралу тарихы, татар халык җырларының үзенчәлеге һәм аларны башкару осталыгы мәсьәләләрен күтәреп язган китап тумас микән?

Халык көйләрен башкару үзенчәлекләре хакында сөйләгән һәм югарыда китерелгән сүзләрен тәмамлап, Г. Тукай мондый фикер әйтә: әгәр дә бу турыда күп сөйләшүгә кителсә, музыка һәм аны аңлау мәсьәләләрен күтәрергә туры килер иде, ди. Ул әлегә бу өлкәдә үзенең тиешенчә хәзерлеге юклыгын әйтә һәм фикерен болай тәмамлый: «Юк аның тоткан нәрсәсен куптарырлык кулы. Юк аның уйлаган вә сизгән нәрсәсен дәлилләр белән сөйләрлек теле. Юк аның караган нәрсәсен аркылы тишәрлек күзе»[1]. Тирән юмор белән әйтелгән бу сүзләрдә, әлбәттә, шагыйрьнең зур тыйнаклыгы сизелә. Коеп куйган шагыйрь булу өстенә, Г. Тукайның бөек гыйлем иясе дә булуы бәрәүдә дә шик тудырмый. Аның «Халык әдәбияты» исемле әсәре генә дә халык иҗатын, халык җырларын өйрәнүчеләрнең ничәмәничә дистә еллар инде юл башы булып тора һәм озакка шулай булып калыр да. Тукай әлеге әсәре белән генә дә канәгатьләнмәгән, шул эшен дәвам иттереп, халык җырларының тарихын ачыклауга багышланган зуррак хезмәт язуны күздә тоткан: «Җырларыбыз вә көйләребезнең тарихын вә мәнбәгъләрен (чыганакларын) тикшерергә бер заман махсус хезмәт куярмын да, шаять шул турыда әсаслырак (төплерәк) мәгълүмат бирермен дигән өметем бар әле»[2]. Шуннан бер ел узгач, С. Сүнчәләйгә язган хатында Г. Тукай шул яңа хезмәте өчен бик яхшы материаллар тапканын, шуны җыйнап бирергә нияте булганлыгын әйтә. Әмма икс елдан соң, 27 яшен тутырганда дөнья куйган шагыйрь бу хезмәтен төгәлли алмый калган, һәм ул эшнең язмышы да хәзергә билгеле түгел.

---

[1] Г. Тукай. Әсәрләр, 2 том, Казан, 1955, 272 бит.
[2] Шунда ук, 256 бит.

Әлбәттә, Тукай үзенең махсус музыка белеме булмаганлыгын яхшы аңлаган. Бу өлкәдә хәзер кытлык юк инде. Профессиональ һәм халык музыкасының нечкәлекләрен аңлаган белгечләребез, талант ияләребез күп. Шулар арасында музыка буенча югары белемле, халык җырларының, халык көйләренең үзенчәлекләрен яхшы белгән, гаҗәеп моңлы тавышка ия булган халык җырчысы Илһам Шакиров та бар.

Әйе, халыкның рухи идеалларын бөтен җаны-тәне белән тоя белгән һәм шуларны йөрәгенең иң нечкә хисләре аша ачып бирә алган, халыкның чын мәхәббәтен казанган якты шәхес һәм кабатланмас талант иясе, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык артисты, Габдулла Тукай исемендәге Татарстан Дәүләт премиясе лауреаты Илһам Шакиров сөйгән халкын яңа, зур уңышлары белән тагын да шатландырыр.

«Казан утлары»,
1982, 10 сан.

БЕР РӘСЕМНЕҢ ТАРИХЫ[1]

«Социалистик Татарстан»ның кушымтасы «Әллүки»нең чыга башлавына чын күңелдән куанып, аңа озын гомер, халкыбызның тарихын һәм культура тормышын матур-матур сәхифәләр белән яктыртуда зур уңышлар теләп, бер фоторәсем тәкъдим итәм. Бу рәсем минем кулга Илһам Шакиров турында китап язганда килеп кергән иде. Китап кечкенә күләмле һәм аз фотолар белән чыгарылганлыктан («Җырчы», Казан, 1973), әлеге рәсем анда керә алмый калды. Инде менә «Әллүки» чыга башлагач, рәсемне газета укучыларга тәкъдим итәсем килде. Минемчә, бу коллектив фото Тукай моңнары белән тулган «Әллүки» исеменә бик тә муафыйк килеп тора, анда — бөек шагыйребезнең замандашлары, хәтта якын дусты, аның мәдхиясенә лаек булган беренче татар артисткасы атаклы Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, төрле елларда татар сәхнәсендә уйнаган талантлы артистлар һәм артисткалар, мәшһүр җырчылар һәм музыкантлар, музыка белгечләре, театр эшлеклеләре.

Ә рәсемнең кыскача тарихы менә болай. 1960 елның 12 гыйнварында Казан җәмәгатьчелеге халкыбызның беренче

---

[1] Бу язма «Социалистик Татарстан»да «Әллүкинең фотоархивы» исеме белән басылды. 1989, 9 июль.

профессиональ җырчысы Фәттах Латыйповның 75 еллыгын билгеләп үтә. Башка шәһәрләрдән дә сәхнә ветераннары җыйнала, Ижевскидан С. Гыйззәтуллина-Волжская килә. Ул чакта Ташкентта яшәгән юбиляр, каты авыру сәбәпле, үзе килә алмый.

Кичә Бөтенсоюз театр җәмгыяте Казан бүлегенең ул вакытта Кави Нәҗми урамында урнашкан бинасында үткәрелә. Юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турында музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина сөйли. Концертта танылган артистлар катнаша, алар арасында Казан дәүләт консерваториясенең соңгы курс студенты, әмма үзенең бик тә моңлы тавышы белән инде халыкның мәхәббәтен яулап өлгергән Илһам Шакиров та була. Шунда Илһам, заманында Фәттах Латыйпов яратып җырлаган «Җирән кашка», «Сәгать чылбыры», ул иҗат иткән «Мәхәббәтем» җырларын башкара. Соңыннан аның янына Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская килеп: «Улым, тавышың бик моңлы икән. Сәхнәдә үзеңне тотышыңда да бер сабыйлык, нарасыйлык бар, шуны гомерең буе онытма, яме»,— дип, аркасыннан сөеп китә.

Кичә тәмамлангач, анда катнашкан артистлар һәм культура эшлеклеләре фотога төшәләр. Шул заманнан бирле 30 ел диярлек вакыт узган. Рәсемдәгеләрнең кайберләре, шул исәптән Гыйззәтуллина-Волжская да, инде дөнья куйганнар, калганнары шактый олыгайган, лаеклы ялда, тик И. Шакиров кына элекке моңлы тавышы белән сөйгән халкына әле дә җыр бүләк итеп яши.

Рәсемдә уңнан сулга: беренче рәттә — ТАССРның атказанган артисты Каюм Бариев, артистка Мөкәррәмә Әсфәндиярова, театр активистлары Насыйбулла Чекин һәм Фатыйма Чекина; икенче рәттә — ТАССРның халык артисткасы Галия Кайбицкая, артистка Маһирә Мирвәлиева (танылган артист Шакир Шамильскийның хатыны), Сәхипҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, РСФСРның атказанган артисткасы Гөлсем Болгарская, ТАССРның атказанган артисткасы Мәрьям Сульва, ТАССРның халык артисткасы Рәйсә Билалова, ТАССРның халык артисты Фәйзи Биккинин; арткы рәттә басканнар — танылган мандолиначы Исмәгыйль Һилалов, ТАССРның атказанган артисты Әзәл Яһудин, артистка Мәстүрә Әбкәнәева, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Илһам Шакиров, ТАССРның атказанган артисткасы Алия Фәйзуллина, ТАССРның халык артисты Һидаят Солтанов, РСФСРның һәм ТАССРның халык артисты Фәхри Насретдинов, артистка Маһинур Шәрипова, ТАССРның атказанган артисты Зариф Закиров, музыка белгече Зәйнәп Хәйруллина, артист Габдулла Максудов, артист Хан Исмәгыйлов[1].

МАТУРЛЫККА ЙӨЗ БЕЛӘН

Мин белемем буенча архитектор түгел һәм, әлбәттә, проектлаштыру-төзелеш оешмаларында эшләмим. Әмма халкыбызның, республикабызның борынгы һәм урта гасырлар тарихын өйрәнүче тарихчы-археолог буларак, мине шул тарихны тикшерүдә зур әһәмияткә ия булган сәнгать-архитектура мәсьәләләре дә нык кызыксындыра. Менә шуңа күрә архитектурага, аның үткәненә, бүгенгесе һәм киләчәгенә дә кагылышлы кайбер фикерләр белән урталашу теләге туды. Мондый теләкнең тууы соңгы вакытта архитектурага булган мөнәсәбәт, төрле карашлар, аның турында бәхәсләрнең күбәеп китүе белән дә аңлатыладыр. Ә бу исә безнең бүгенге тормышыбызда башланган чын мәгънәсендәге революцион үзгәрешләргә бәйле. Мәгълүм булган торгынлыктан тизләнешкә һәм үзгәртеп коруга күчү архитектурага да яңа сулыш өрде. СССР архитекторларының күптән түгел булып үткән VIII съезды материаллары белән кызыксынып барган һәркем моны сизгәндер.

---

[1] Фоторәсемдәге шактый гына шәхесләрнең исемнәрен ачыклауда ярдәм иткәне өчен мөхтәрәм Әзәл ага Яһудинга һәм Зәйнәп ханым Хәйруллинага зур рәхмәтемне белдерәм.

Архитектура үзенең тумышы белән сәнгать*ул, алай гына да түгел, аны «сәнгатьнең анасы» дип атыйлар, чөнки борынгы антик культураны, мәшһүр Грек һәм Рим культурасын һәм сәнгатен, беренче булып дөньяга таныткан өлкә — мәһабәт, монументаль архитектура. Аннан соң барлыкка килгән, шул ук антик культурага нигезләнеп, үзенчәлекле юллар белән алга атлаган мәшһүр Шәрык сәнгатьархитектурасы, урта гасырларның Яңарыш (Ренесссанс) чорына, «барокко» стиле белән үзенчәлекле яңа заман дәверенә һәм XIX йөзгә кагылышлы Көнбатыш Европаның классик архитектурасы, Русьның кырыс та, серле дә булган храм-соборлары, шәһре Болгарның күпләрне таңга калдырган пулат-сарайлары, мәчет-манаралары... Менә шул матурлыкны йөз, мең еллардан соң күреп исе киткән шагыйрьләр һәм философлар архитектураны «торараташка әверелгән музыка» дип бәяләгәннәр. Әйе, үткән гасырларның авыр да, серле дә, гыйбрәтле дә, данлы да булган тормыш-вакыйгалары шул таш-мәрмәрләрдән кайтаваз булып, гүзәл бер музыка булып ишетелә...

Менә шул гүзәллек, сәнгати нәфислек соңгы вакытта архитектурада югала башлады. Аны артык гадиләштерү, примитивлаштыру, төзүчеләрнең заказларын үтәү белән генә чикләнү шулкадәр киң колач җәйде ки, хәтта аерым даирәләрдә архитектураның бүгенге көндә кирәксезлеге турында сүзләр сөйләнә башлады. Зур итеп әйткәндә, архитекторлар өстеннән төзүчеләр диктаты, власте урнашкач, архитектурада иҗат, художество эше артык дәрәҗәдә чикләнде. Архитекторларның эшләренә традицион конкурслар оештыру гафу ителмәслек кимеде. Соңгы 20—30 ел эчендә архитекторларның күпчелеге нигездә әзер проектларны теге яки бу урыннарга урнаштыру мәсьәләләре белән генә шөгыльләнергә мәҗбүр булдылар. Архитектура тартма йортлар («коробкалар») һәм бетон панельләрдән өйгән башка корылмалар арасында югалып калды. Ә ул бер типтагы йортлар исә бернинди климатик, милли үзенчәлекләрне искә алмыйча, иксез-чиксез илебезнең бөтен җиренә — Бресттан Владивостокка, Мурманскидан Ашхабадка кадәр «сибелде». Панель йортларның бертөрлелеге шул дәрәҗәгә җитте ки, кайсы шәһәргә килеп эләккәнеңне чамалау да авырайды — шәһәрләрнең үз төсләре, үзенчәлекләре югала башлады.

Дөрес, соңгы елларда нык үсеп киткән шушы микрорайоннар, андагы «типовой» йортлар илебездә торак мәсьәләсен шактый җиңеләйтте, күпләр иске, уңайсыз йортлардан бөтен уңайлыклары булган квартираларга күчте. Бу — социаль, шул исәптән торак проблемасын хәл итүдә зур,

мөһим адым булды. Әмма сүз ул турыда бармый. Сүз бердәм архитектура-төзелеш комплексы булдыру, проектлаштыру һәм төзелеш эшенең аһәнле, гармонияле үсеше хакында, панельләрдән эшләнгән биналарга да матурлык өстәү, шул планда яңа формалар эзләү турында бара.

Материаль байлыклар җитештерүдә генә түгел, ә җәмгыятьнең эстетик һәм мораль-әхлакый идеалларын формалаштыруда зур роль уйнаучы архитектураның, совет архитектурасының гуманизмы, кешелеклелеге, олы җанлылыгы игътибар үзәгендә булырга тиеш. Бүгенге архитектура — сәнгатьнең, фәннең һәм техниканың органик берләшмәсе, архитекторларның, галимнәрнең, төзүчеләрнең, төзү материаллары җитештерүчеләрнең уртак иҗади хезмәте. Ләкин монда төп, җитәкче көч, әйдәп баручы — ул, әлбәттә, архитектор. Күптөрле музыка коралларын берләштергән зур оркестр белән оста җитәкчелек иткән талантлы дирижер кебек, архитекторлар да бүгенге проектлаштыру-төзелеш эшләрендә җитәкче көч булырга тиеш. Архитектураның элекке матур традицияләрен яңартып, аның сыйфат дәрәҗәсен үстерү, идея-художество эчтәлеген баету, кешегә әхлак тәрбиясе бирүдәге ролен күтәрү, гомумән, архитекторларның социаль җаваплылыгын арттыру — бүген мәсьәлә шулай куела.

Архитекторларны, гомумән, киң җәмәгатьчелекне борчый торган мөһим мәсьәләләрнең тагын берсе — борынгы шәһәрләрнең тарихи йөзен саклап калу мәсьәләсе. Шәһәребезнең тарихи үзәкләренә карата булган кайбер тискәре карашлар, чын мәгънәсендә тарих һәм культура истәлекләренә әверелгән әүвәлге йортларны сүтеп, алар урынына шул җирнең архитектур-композицион үзенчәлегенә һич кенә дә туры килми торган стереотип биналар салып кую белән хәзерге архитектура фәне һич тә килешә алмый. Яшь буында, гомумән, халкыбызда патриотик хисләр тәрбияләүдә шәһәрләрнең тарихи мохитенең ролен, кызганычка каршы, шактый гына идарә органнары аңлап бетермиләр.

Менә шушы кыскача гына санап үтелгән мәсьәләләр күзлегеннән караганда, республикабызның башкаласы, илебезнең зур индустрия һәм культура үзәге булган Казанның — борынгы Казанның архитектур йөзе хакында да берничә сүз әйтеп китү урынлы булыр иде. Башка бер генә шәһәрнеке белән дә алыштыргысыз тарихи йөзен, бүгенге культурасын ачык күрсәтеп торучы, һәрберебезнең чын горурлыгы булган менә дигән архитектур ансамбльләребез, аерым биналарыбыз бар безнең. Сөембикә манарасы



Казанның Апанай мәчете. Э. Турнереллиның 1830 еллар азагында ясаган рәсеме. К. Насыйри урамы, 29 нчы йорт. Хәзер анда мәчет яңадан эшли башлады

һәм башка борынгы корылмалар белән данлыклы чал һәм матур Кремль, ап-ак мәһабәт университет, Ирек мәйданына һәм бөтен тирә-юньгә зур ямь өстәүче Опера һәм балет театры, Сынлы сәнгать, Тукай музейлары бинаклары, Мәрҗани, Апанай, Әҗем мәчетләре... Саный китсәң, бик күп алар. Үз гомерләрендә илебезнең һәм чит илләрнең бик матур шәһәрләрен күргән атаклы фән һәм культура эшлеклеләре, Казанга килгәч, иң элек менә шундый борынгы йортларның күплегенә, аларның кабатланмас булуына игътибар итәләр, аларны саклап калу кирәклеген искәртәләр. Әйе, аларны мөмкин булган кадәр саклау, реставрацияләү, мемориаль такталар кую — менә болар архитектор-реставраторларның, совет органнарының, иҗат, коммуналь хуҗалык оешмаларының, киң җәмәгатьчелекнең тиз арада кайгырта торган эшләре. Мәсәлән, ни өчен халкыбызның Ф. Әмирхан, Г. Камал, С. Сәйдәшев һәм башка олы шәхесләре, якты талантлары исеме белән бәйле булган элекке «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе урнашкан бинада (Тукай урамы, 34 нче йорт) мемориаль такта юк? Саный китсәң, татар һәм рус культура эшлеклеләренә бәйле бул-

ган күпме йорт-бина шул кечкенә генә мәрмәр тактага нәүмиз булып моңаеп басып тора.

Әйтелгәннәргә шуны да өстик: бүгенге архитектура истәлекләрс турында уйланган чакны, соңгы еллар төзелеш архитектурасының бик тә үзенчәлекле вәкиле булып цирк бинасы күз алдына килеп баса. Тик, ни өчендер, аңа өстәп Татар дәүләт академия театрының яңа бинасын әйтәсе килми. Күңелне ниндидер канәгатьсезлек борчый. Дөрес, театрның яңа бинага күчүе татар культурасы өчен зур шатлык, бәйрәм булды. Тик аның тышкы кыяфәте сәнгать йорты турында түгел, ә гадәти промышленность архитектурасы турында сөйли кебек. Стенасына индереп эшләнгән һәм төсле мозаика белән чуарланган берничә тоташ тәрәзә-ниша гына аңа милли үзенчәлек бирә алмый. Киләчәктә менә шундый, шәһәребезнең архитектура йөзе турында сөйләрлек, культура учаклары булып яшәрлек зур-зур корылмаларны төзү алдыннан аларның проектлары белән халыкны, киң җәмәгатьчелекне дә таныштыру гамәлгә керсен иде, чөнки болар һәммәсе халык өчен эшләнә бит.

Соңгы вакытта ландшафт архитектурасына шактый игътибар итә башладылар. Бу архитектура — кирпеч-бетонга төрелгән шәһәрне беркадәр табигатькә якынайту сәнгате, яшеллек белән таш мәрмәрләрнең гармониясе. Японнар үрнәгендә, алар булышлыгы белән Мәскәүдә үзенчәлекле парк төзелгән. Урынына һәм мөмкинлеккә карап, зәвык белән эшләнгән төрле зурлыктагы шундый паркларны, бакча-скверларны булдыру — һәрбер шәһәр өчен ифрат кирәкле эш. Алар, беренчедән, шәһәрләребезнең һавасын чистартучы мөһим органнар булса, икенчедән, бүгенге интенсив тормышта яшәүче кала кешесен беркадәр табигатькә якынайту булыр иде.

Шәһәрләребезне төзекләндерү, матурайту эшендә архитекторлар белән дизайнерларның бергәләп, иҗади эшләве дә зур файда бирә. Дизайн — халыклар теленә үтеп кергән яңа сүз, ул производство, промышленность сәнгатен аңлата, дизайнерлар — шул өлкәдә эшләүче инженерлар, художниклар, гомумән, шул сәнгатькә хезмәт итүчеләр. Дизайнның үсеше илебездә әлегә күбрәк чит ил үрнәгендә бара. Бу сәнгатьне һәр җирле халыкның декоратив сәнгать элементлары белән баету бик тә мөһим.

Кыскасы, бүгенге заманның фән һәм техника казанышларын оста, иҗади кулланып, сәнгатьнең бай төре булган архитектураны камилләштерү, аның әүвәлге матур традицияләрен дәвам итеп, яңа, яшәешле формалар табу — халкыбызның социаль һәм культура тормышын баетудагы,

шәһәр-авылларыбызның төзеклеген булдырудагы, матурлыгын арттырудагы мөһим чаралар.

«Социалистик Татарстан», 1987, 25 июль.

ХӘТЕР

(Фуат Вәлиевнең тууына 70 ел тулу уңаеннан)

Борынгы архитектура һәм гамәли сәнгать буенча искиткеч бай гыйльми нигезгә корылган фәнни монографияләр авторы, исеме җәмәгатьчелек арасында киң таралган, халык сәнгате буенча татарлардан әлегә бердәнбер фән докторы булган, тик үзенең туган йорты Казанда һәм аның фәнни-тикшеренү институтында даими хезмәт урыны таба алмыйча, бу фани дөньяның каһәр суккан каршылыкларын җиңә алмаудан гаҗиз булып, үзенә карата көнчелектән һәм хөсетлектән тәмам туеп, тормыштан вакытсыз китеп барды Фуат Вәлиев. Фәнгә, сөйгән халкына хезмәт итүдән башканы белмәгән, киң күңелле, әмма шактый авыр холыклы, зур интеллектуаль акылга ия, ләкин күпләргә аңлашылып бетмәгән үзенчәлекле шәхес иде ул. Мөгаен, олы талантларның күбесенә хас сыйфатлардыр инде болар...

Хатирәмне шул фидаи затның авыр язмышы өчен газаплану сүзләре белән башласам да, Фуат абый минем күңелемдә татар халкының искиткеч бай мәдәни тарихын армый-талмый тикшерүче һәм аны ялкынланып пропагандалаучы фәнни баһадир булып калачак. Үземне аның рәсми булмаган, әмма чын укучысы дип игълан итәргә дә җөрьәт кылам, моңа минем хакым бар. Фуат Вәлиев турындагы хатирәләрем яңарган саен, иң әүвәл моннан 30 ел элек, ягъни 1960 елда, элекке Касыйм ханлыгының башкаласы Касыйм шәһәренә кылган сәяхәтебез искә төшә. Борынгы шәһәрнең татарлар яши торган өлеше, шундагы татар зираты, Хан мәчете, XV йөздән калган биек таш манара, халкыбыз тарихында кара эз калдырган Шаһгали мавзолее, аның эчендәге җисеменә бик ук туры килеп бетмәгән, зур һәм матур кабер ташлары, шунда Сөембикә каберен эзләп йөрүләребез... Фуат абыйга 39, миңа 23 яшь. Ул миңа тарих — татар тарихын сөйли, мин йотлыгып тыңлыйм. Инде бүген, үземнең дә шул тарихны ярыйсы гына белүем күзлегеннән караганда, мин Ф. Вәлиевнең шул вакыттагы фәнни эрудициясен, киң белемлелеген искә төшереп, хәйран калам. Бер уйласаң, махсус тарихи белеме

Сәнгать белгече һәм архитектура тарихчысы Фуат Вәлиев

дә юк төсле. Киевтә төзүче-инженерлар институтын тәмамлаган, аннан соң ун ел Гипротатнефть трестында архитектура-төзелеш бүлеге җитәкчесе, ике ел Казан реставрация остаханәсендә баш архитектор. Хәер, бу елларда инде ул атаклы этнограф Н. Воробьевның аспиранты, бер үк вакытта Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының кече гыйльми хезмәткәре. Институтта 10 ел эшләү дәверендә бу «дәрәҗәле» исем аның артыннан даими ияреп йөрде. Әйе, 50 яшен тутыручы танылган галим, «Казан татарлары орнаменты» исемле бәһа биреп бетермәслек зур монография, дистәләгән фәнни хезмәтләр авторы һәм... кече гыйльми хезмәткәр. Дөресен әйтим, Фуат абыйны бу исем кимсетте. Үзенең югарырак исемгә, «өлкән хезмәткәр» дәрәҗәсенә лаеклы булуын исләренә төшерсә дә, игътибар итмәделәр, һәм ул институттан китте. Мин аны аңлыйм. Бигрәк тә соңрак, бүген дә шушы институтта биш-алты чиле-пешле мәкалә чыгарып, фәләнчә еллык «образованиеләрен селкетеп» йөргән кайбер өлкән гыйльми хезмәткәрләр барлыгыннан чыгып карасаң, Ф. Вәлиевнең ул чактагы принципиаль адымы гаҗәп тоелмый. Ләкин ул бөтен булган үпкәсен онытып, берничә елдан институтка кайтырга теләде, конкурста катнашты, тик гыйльми совет аны үткәрмәде. Сәнгать буенча фәнни

хезмәткәр булып бер ханым узды, шуннан берничә ел үткәч, институт буенча кыскартылуга эләгеп, аннан китәргә мәҗбүр булды. Баксаң, әлеге мөхтәрәм ханымның фәндә ун елдан артык эшләү дәверендә... бер генә фәнни хезмәте дә булмаган икән. Ә конкурстан уза алмаган, ул вакытта Мари политехник институтында доцент булып эшләгән Фуат Вәлиев Йошкар-Ола шәһәрендә татар халкының сәнгать һәм архитектура тарихы буенча ике монография бастырып чыгарды, Казанга кайтып, Татарстанның халык декоратив сәнгатенә багышлап тагын бер китап чыгарды һәм докторлык диссертациясен яклады. Әйе, инде әйткәнемчә, татар сәнгатенең тарихы, ягъни матди культура белән бәйле булган бик тә мөһим өлкә буенча һәм, әлбәттә, татарлар арасында әлегә берләнбер фәннәр докторы булды. 60 яшь тулганда күпьеллык гыйльми хезмәтенең җимешен — диссертациясен СССР Художество академиясендә яклап, шуннан сабый балалар кебек шатланып кайтып, тагын үзенең туган институтына эшкә алуларын, һич югында консультант итеп билгеләүләрен сорап бара һәм тагын «отказ» ала. Бу юлы сәбәбе дә бар — пенсионер! Ә ул вакытта анда хәтта 80 не тутырган кайбер тарихчылар консультант санала иде...

Мин бу сүзләремне әлеге институтта, ягъни үзем дә инде 28 ел өзлексез эшләүче фәнни оешмада ошатмаячакларын белеп язам. Фуат Вәлиевнең татар тарихын, аның гаҗәеп бай архитектура һәм сәнгать тарихын тырышыптырышып өйрәнүдә, шуны дөньяга чыгаруда искиткеч зур хезмәт куюын, ләкин үзе исән чакта шул зур хезмәтне, аның талантын әлеге институтта танымауларын, дөресрәге, танырга теләмәүләрен, югары классны белгеч буларак читкә кагылуын үзе үк белә торып, күп газапланулар, артык гасабиланулар нәтиҗәсендә («быстротечный рак») вакытсыз дөньядан китеп баруы өчен йөрәгем әрнеп, җаным сыкрап язам. Берничә монографиясенең фәнни редакторы һәм рецензенты, фикердәше һәм якын дусты буларак, аны институтка алуларын сорап ул вакыттагы институт житәкчелегенә, СССР Фәннәр Академиясенең Казан филиалы президиумына, КПСС өлкә комитетына берничә тапкыр мөрәҗәгать итеп тә, сүземне үткәрә алмаганлыгыма гарьләнеп язам. Кемнәр каһәрләгәннәр, кемнәр рәнҗеткәннәр, кемнәр аны читкә какканнар — шуларның намусларында калсын.

Даһи Тукайның үлемсез сүзләре, әйтерсең, туган халкын, аның бөек матди һәм рухи дөньясын сөеп иҗат иткән, әмма һәртөрле түбәнлекләр, мыскыллаулар тоеп яшәгән Фуат Вәлигә дә багышлап язылганнар:

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын,
Без үләрбез, билгеле, тик үкенечкә калмасын.
Киң күңелле бул эчеңнән, мыскыл ишетсәң, «вак» диген,
Таптасыннар, хурласыннар, тик җаның хурланмасын.

Әмма Фуат абыйның җаны да хурланды. Дөрес, ул көчле кеше иде, үзенең күпләрдән бер башка югары булуын сизеп яшәде, кемнәр алдындадыр баш имәде, ялагайлыкны җене сөймәде. Дөрес, хурланды, әмма сынмады, рухи гарипләнмәде.

Мин Фуат Вәлиевне идеаллаштырырга җыенмыйм. Күпләрнеке кебек, аның да җитешмәгән яклары бар иде, әйткәнемчә, холкы да бик җиңел түгел иде. Миңа моны үземә дә татырга туры килгәләде. Сөйләшеп утыра торгач, төрле гыйльми мәсьәләләр турында бәхәсләшеп китеп, сүзгә килешә, үпкәләшеп аерылыша торган идек. Әмма аннан яшь кеше буларак, аның олы галим булуын тоеп, шуны кабул итеп, үзем башлап, Щапов урамына, аның өенә тагын барам, әнисе Нәгыймә апа (безнең әниләрнең исемнәре дә бер иде) пешергән бик тә тәмле йомшак кабартмаларны ашап озаклап чәй эчәбез, тагын төрле фәнни мәсьәләләр турында фикерләшәбез. Әлбәттә, еш кына уртак тел табабыз. Һич кенә дә үпкә саклаучан, үч тотучан кеше түгел иде мәрхүм.

Мин Ф. Вәлиевне белгәннән бирле аның талантына, эшкә ифрат сәләтле булуына сокланып яшәдем. Киң эрудицияле тарихчы, этнограф, сәнгать белгече, архитектор һәм рәссам. Мин аның ике кулы белән дә бер үк дәрәҗәдә, бер үк тизлектә сызым сызу яки рәсем ясау сәләтенә сокланып бетә алмый идем. «Ничек алай эшли аласыз?» дигән сөалемә каршы елмаеп кына куя иде. Дөресен әйтим, аның бу табигый сәләтенә Бакый Урманче да зур бәя бирде. Без икәү Бакый ага янында булгалап, сәнгать һәм, гомумән, халык тарихы турында озаклап сөйләшеп утыра торган идек. Кайбер гадәтләре өчен аны җиңелчә шелтәләп, «Юк, Фуатҗан, бу юлы син хаклы түгел», дигәләсә дә, олы рәссам аны бик ихтирам итә, ярата иде, ә Фуат абый Бакый Урманчены гомере буе үзенең остазы итеп санады. Мин моның шаһиты.

Әлбәттә, мин аның бөтен басылган китапларына да фәнни анализ ясарга җыенмыйм, кечкенә генә язмада моны башкарып та булмый; җитмәсә, минем хатирәмнең максаты да ул түгел. Аның күпьеллык фәнни хезмәтенә бәя биреп, берничә сүз белән генә болай дип әйтеп булыр иде: Фуат Вәлиев милли сурәтләү өлкәсендә татар халык сәнгатен өйрәнү фәненә чын мәгънәсендә нигез салды, халкыбызның декоратив-гамәли сәнгате аның фәнни тик-

шеренүләрендә беренче тапкыр гыйльми-теоретик нигезгә корылды. Бу аның биш фәнни монографиясендә, Мәскәүдә басылган берничә зур коллектив хезмәттә (шулар арасында «Урта Идел һәм Урал буе татарлары» дигән һәйбәт китап, дөнья халыклары сәнгате буенча энциклопедик басма) чагылыш тапты, раслану алды, тиешле фәнни калыпка салынып бирелде.



Яка чылбыры — Казан татарларының алтын, көмеш һәм асылташлардан төерчекле нәкыш алымы белән эшләнгән зәркән (ювелир) сәнгате ядкаре

Беркадәр баналь, кабатланган сүзләр кушып әйткәндә, Ф. Вәлиев башка бернәрсә дә язмыйча, инде телгә алынган «Татар халык орнаменты» дигән капиталь монографиясен генә иҗат иткән булса да, аның исеме татар халкының күп гасырлык сәнгать тарихын өйрәнү эшендә алтын хәрефләр белән язылып куелыр иде. Исеменә караганда, бу китап сәнгатьтәге техник алымнарның бер төренә — орнамент-бизәккә генә багышланган кебек тоелса да, монда халыкның искиткеч бай рухи дөньясының матди чагылышы булган декоратив-гамәли сәнгатькә, аның төрледән-төрле төркемнәренә, шуларны эшләү алымнарына, аларның килеп чыгышына һәм тарихи язмышына гаҗәеп төпле, нигезле, профессиональ анализ бирелгән.

Мин бу китапны кулыма алган саен — ә мин аңа бик еш мөрәҗәгать итәм — тыныч кына укый алмыйм. Никадәр зур байлык, никадәр гүзәллек вә сылулык, никадәр тирән сәнгати фәлсәфә! Әйе, бу сәнгать — чын мәгънәсендә халкыбызның бөек акылы, аның гасырлар буена тир һәм канлы яшь түгеп җыйган рухи вә матди байлыгы. Ә югалганнары, 1551—1552 елларда һәм шуннан соң да таланганнары күпме булгандыр...



Татарның каюлы читекләре. XIX—XX йөз башы

Алтын-көмештән, кыйммәтле ташлардан эшләнгән атаклы ювелир, ягъни зиннәтле бизәнү әйберләре: чулпылар, хәситәләр, яка чылбырлары, беләзекләр, йөзекләр, алкалар, бөтиләр, кечкенә һәм нәфис Коръән тартма, тагын әллә ниләр, аларны бизәкләүнең бай алымнары, әйтик, кою, нәкыш, бөртекләү, каралту, кырлау, басма һәм башка югары сәнгати ысуллар — болар һәммәсе байлык, осталык вә илаһи нәфислек. Ә менә энҗе, якут, зөбәрҗәт, ахак, фирүзә кебек асылташлар куеп, яссы нәкыш, бигрәк тә төерчекле нәкыш алымы белән эшләнгән бизәнү әйберләре, Ф. Вәлиев раславынча, бары тик татарларга гына хас һәм алар дөнья зәркән (ювелир) сәнгатенең иң гүзәл үрнәкләреннән саналырга хаклы.

Бу әле халык сәнгатенең бер төрен генә искә алу булды. Ә бит һәрберебезгә балачактан бик таныш булган, һәр татар өен, хәтта ярлы-ябаганың да җыештырып куйган куышын үзенчә бизәп торган, әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез, абый-апаларыбыз, ниһаять, үзебез киеп йөргән, чигеп эшләнгән җиһаз һәм киемнәр. Кызыл башлы сөлгеләр, япмалар, келәмнәр, ашъяулыклар, башъяулыклар, түбәтәйләр, калфаклар, башмаклар, читек-кәвешләр, аларны чигүнең күп төрле алымнары, мәсәлән, элмәле чигү, тоташ чигү, каеп чигү, сәйлән чигү, чуклы чигү. Аларны бизәкләүнең бер генә төрен, чәчәк орнаментын гына ал син — мәңге яшәр табигатьтән никадәр олы байлык, гүзәллек кабул ителгән: йөзем агачы, дәлия, лалә, канәфер, кашкарый, мәк, миләүшә, гөлчәчәк, чалма чәчәк, кыңгырау чәчәк, ак чәчәк, алтын чәчәк... Сөйли-яза китсәң, туктый алмассың. Боларның һәммәсе Фуат Вәлиевнең әлеге кита-

бында, аның башка хезмәтләрендә гыйльми вә сәнгати яңарыш алып, сөйгән халкына кире кайтарылды.

Сөйгән халкы... Бу сөю берьяклы гына түгелме соң? Юк, мин һич тә бөтен халык тарафыннан сөелү турында сүз алып барырга җыенмыйм. Фән кешесе ул җырчы да, композитор да, шагыйрь дә түгел, галимнәрне, гадәттә, азрак беләләр, аларның булган популярлыгы күбрәк шул годәмә, интеллигенция арасында. Ләкин болары да бит шул ук халыкның уллары, җитмәсә, теге яки бу галимгә халык исеменнән бәя бирергә яратучы партия-совет эшлеклеләре, һәртөрле чиновниклар, функционерлар бар. Аларның «сөюе» ни дәрәҗәдә? Үзе исән чакта кагу, мыскыллау, эшенә төрлечә аяк чалу, үлгәч күкләргә чөеп мактаумы? Дәрдмәндчә әйтсәк:

Бетеп гомерең, итеп күмгәч үзеңне,
Итәрләр хирзе җан[1] күмгән сүзеңне.

Шул ук Фуат абыйның институтка кире кайтуына комачаулау өчен бөтен көчләрен куючыларның кайберләре бүген аның татар сәнгате тарихын өйрәнүгә керткән «зур өлеше» турында сөйлиләр, кайберләре аның 70 еллык юбилее уңае белән үткәрелгән фәнни конференциянең оештыру комитеты әгъзалары... Йа хода, кайдан соң бу бездәге рухи гариплек, бу җаһилият? Кайдан бездәге бу кеше көенечечә сөенеп, кеше сөенеченә көенеп яшәүләр? Нигә татарның әле күптән түгел генә без белгән галимнәре — менә дигән тарихчы, эпиграфист, этнографлары Хәйри Гимади, Һарун Йосыпов, Әхәт Заһидуллин үз-үзләренә кул салдылар? Нигә? Кем моңа җавап бирә ала? Нигә халкыбызның гасырлардан килә торган тарихын, газиз исемен — «татар» исемен — сүгеп, аны икенчегә әйләндерү максатында китаплар һәм мәкаләләр бастырып, 1552 елда Казанның «Рус дәүләтенә кушылуы прогрессив күренеш булган» дип язып, шушы институтта кадер-хөрмәт казаналар? Кайда намус, кайда пакълек, кайда вөҗдан? Җавап таба алмагач, ирексездән тагын Тукайга мөрәҗәгать итәм:

Керләнә өст, өстенә — рух, һич хозур вөҗданга юк;
Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә — мунча, җанга — юк?!

Әмма андый вакытта мин Фуат Вәлиев кебек фән каһарманнарының намуслы исемнәрен искә төшерәм, аларның якты хатирәсе алдында үземнең чаларган башымны иям, киләчәккә өмет белән карыйм. Аллага шөкер, Фуат

[1] Хирзе җан — бөти, талисман.

абыйның татар халык*әсәрләрен җыйнау, гыйльми классификацияләү, аны бөтен итеп халыкка кире кайтару, гомумән, халкыбызның чын тарихын һәм мәдәнияте тарихын язу эше бүген ышанычлы кулларда — аның сәләтле кызы, тирән белемле сәнгатькәр Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова, Фуат абыйның фикердәшләре, якын дуслары кулында.

«Казан утлары»,
1991, 6 сан.

КҮҢЕЛЕМДӘ — ҖЫЛЫ ХИСЛӘР

(Сәяхәтләрдән кайткач)

Кайларда гына булмый, ниләр күрми,
Дөнья гизә адәм баласы...

Татар халык җырыннан

...Язгы айларда АКШның Мадисон шәһәрендәге Висконсин университеты профессоры Кемал Карпат әфәндедән Казан университеты һәм Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының берничә галименә Үзәк Азия буенча IV Халыкара фәнни конференциядә катнашырга чакырып, хатлар килеп төшә. Чакыру миңа да була, әмма ул кемнеңдер кулына эләгеп... югала. Шул турыда Американың кайбер татар даирәләренә билгеле була, һәм алар миннән өй адресымны сорап язалар. Ике якка хатлар йөргәнче шактый вакыт уза, һәм мин кабат чакыру алам. Конференциягә аз вакыт калган, әмма мин бәхетемне сынап карарга булам. Тиз арада кирәкле документ-кәгазьләрне тутырып (аларны әзерләүдә миңа институт җитәкчеләре ярдәм итте, рәхмәт аларга), Мәскәүгә, СССР Фәннәр академиясенең президиумына илтеп бирәм.

Гаҗәп хәл, бер атна эчендә кәгазьләр, тиешле инстанцияләрне берниндм тоткарлыксыз үтеп, кабул ителәләр, миңа Америкага очу өчен самолетка билет алырга кирәкле документларны бирәләр. Әмма шуннан газап чигү башлана, чөнки самолетка билет юк икән! (Соңыннан үзәк газеталарның берсендә язылганча, Нью-Йоркка оча торган совет самолетында урыннарның өчтән бер өлеше диярлек буш булса да билет алып булмый, аларны «күләгәле экономика» вәкилләре, ягъни мафия үз кулында тота икән. Тагын шуны ишеттем: билетка ике бәя түләгәндә алып

була, диделәр.) Йа, Ходаǃ Бер билет сорап кайларга гына мөрәҗәгать итмәдем мин. Ул бихисап оешмаларны санап чыгу һәм Казан — Мәскәү юлларын кат-кат үтүләрне сөйләп тору хөрмәтле укучыларга кызыклы булмас, дип уйлыйм.

Шунысын гына әйтеп үтим: андый вакытта кешегә очраклылык ярдәмгә килә торган була. Менә миңа да соңгы сәгатьтә «күк капусы ачылып» китте — конференциягә барырга тиешле бер Мәскәү галиме авырып киткән икән (тизрәк терелә күрсен, рәхмәт төшкере), шуның урынын миңа бирделәр. Анда да әле бюрократиянең берничә баскычын үтәргә туры килде. Язмышым шундыйдыр инде минем, күп нәрсәләр озак интегү-газаплардан соң гына хәл ителәләр... Хәер, без барыбыз да бу фани дөньяда якты киләчәк көтеп яшәргә өйрәнеп беткән инде.

Ирландия һәм Канадада тукталыш ясап, ярты тәүлек эчендә Нью-Йоркка килеп җиттек. Монда да мине аердылар. Чакыруны әүвәл алган һәм алдан билет алып, үзләренең килүләре турында алдан хәбәр иткән галимнәр Мадисонга бөтен совет делегациясе составында Чикаго аша очтылар. Ә мине Ходайның игелекле бер бәндәсе, үз машинасында шәһәрнең икенче аэропортына алып барып, шул ук Мадисонга икенче рейс белән очыртып җибәрде. Әле юлда туктап, «пересадка» ясарга да туры килде. Боларның барысына да совет мәктәбе һәм вузында белем алганда колакка эленеп калган ярым инглизчә, ярым немецча, «сәнк-йү», «о'кэй», «битте» кебек хикмәтле сүзләр ярдәм итте. Инде картаеп бара торган йөзеңә бераз елмаю билгесе чыгарасың да шул тылсымлы сүзләрне әйтәсең. «Мең дә бер кичә»дәге Гали бабаның «Сим-Сим»еннән бер дә ким түгел, бөтен ишекләр ачылып китә, әле җитмәсә, бик матур елмаеп җавап бирәләр. Шуңа игътибар иттем: бездә, гадәттә, самолет килеп төшкәч, иң башлап бик эре кыяфәт белән генә, ямьшәйгән портфельләрен тотып, пилотлар чыгып китәләр, аннан соң гына халык чыга. Ә боларда киресенчә: самолет хуҗалары тезелешеп һәрбер пассажирны озатып калалар, өстәвенә һәрберсенә рәхмәт әйтәләр.

Мадисонда конференциянең башлыгы профессор Карпат үзе каршы алды. Үзебезчә «әссәламе галәйкем»не әйтеп, ике кулын сузып күрешкәч, күңелләр тулып китте. Кемал Карпат — румын татарларыннан, төрекчәне дә, казан татарлары телен дә белә. Хәл-әхвәл сорашып торган арада, Чикагодан да самолет килеп төште һәм безне, ягъни бөтен делегацияне, җиңел машиналарга утыртып, отельгә алып киттеләр.

Күл буена урнашкан бик матур шәһәр ул Мадисон. Аның өчтән бер өлешен университет шәһәрчеге алып тора, анда 45 мең студент укый (чагыштыру өчен: безнең Казан университетында 11 мең). Монда Шәрык һәм шул исәптән татар тарихын өйрәнүгә игътибар шактый зур. Безнең конференция житәкчеләре — университетның татар профессорлары. Алар — исеме дөньяга танылган Кемал әфәнде Карпат (ул Үзәк Азия тарихы буенча зур белгеч, 60 яшьләрдәге, бик мөлаем, зыялы бер кеше); «Идел буе татарлары» исемендәге күпләргә мәгълүм китап авторы, быел Казанда булып киткән Гайшә ханым Рорлих (Гайшә ханым Калифорния университеты профессоры); шулай ук Казанда булып, гыйльми җәмәгатьчелек алдында чыгыш ясаган яшь профессор, бик тә мөлаем һәм ифрат ярдәмчел Юлай әфәнде Шамил — ул Алтын Урда тарихын яза. Шуңа күрәдер дә, безгә, татарларга, карата булган аерым игътибар да сизелде.

Профессор Карпатның кереш сүзеннән соң беренче докладны Миркасыйм Госманов ясады. Ул Россиядәге төрки телләр һәм XV—XVIII йөзләрдәге тарихи чыганакларны өйрәнүнең барышы турында сөйләде. Казан галиме докладын татар телендә ясады. Әмма шундый бер хәл булып алды. Ул сөйли генә башлаган иде, Союздан килгән берничә «бөек халык» вәкиле һәм яһүд демонстратив рәвештә залдан чыгып киттеләр. Икенче доклад — минеке. Темасы: «Татар халкы һәм аның исеменең килеп чыгышы». Мин дә аны татарча башладым (Юлай әфәнде янәшә басып, икебезне дә инглизчәгә тәрҗемә итеп барды). Ачык ишектән күреп торам: теге чыгып киткәннәр шунда гына, коридорда йөриләр. Тукта, мин әйтәм, русчага күчерсәм, кермәсләр микән? Докладның соңгы өлешен русча сөйләдем, әмма кермәделәр (минем доклад беткәч, тәнәфес булды, шуннан соң кереп утырдылар).

Программа буенча, конференциянең өченче көнендә (ул дүрт көн дәвам итте) Казаннан тагын ике иптәшебез чыгыш ясады. М. Зәкиев VIII—X йөзләрнең Скандинавия риваятьләрендә телгә алынган, чынында ерак төньякта, Котып диңгезе буенда урнашкан ниндидер Биармия дигән җир һәм аның Болгар дәүләте белән тәңгәллеге (?) турында сөйләде. Ф. Әхмәтованың докладьы татар халкының авыз иҗатына багышланган иде. Әйтергә кирәк, конференциядә татар тарихы һәм мәдәнияте темасы шактый сизелеп торды. Безнең докладлардан башка, Себер, Кырым, керәшен татарларының тарихы вә теле, Алтын Урда хакында кызыклы чыгышлар булды. Аларны Америка һәм Франция галимнәре ясады. Азәрбайҗан, казах, кыргыз,

үзбәк, шулай ук Россиядәге ислам хәрәкәте темалары да шактый урын алды. Азәрбайҗан темасы аерылып торды, моңа конференциядә Кавказ арты мөселманнарының шәйхелисламы, СССР халык депутаты мөфти Аллагашөкер Пашазадәнең катнашуы һәм доклад сөйләве дә сәбәпче булды.

Гомумән, конференция бездә, шул исәптән миндә дә, онытылмаслык тәэсир калдырды. Доклад темаларының төрлелегеннән башка, күп кенә илләрдән килгән галимнәрнең катнашуы, алар белән аралашу ифрат истәлекле, әһәмиятле булды (докладчыларның күп өлеше АКШ, СССР һәм Төркиядән булып, Франция, Англия, Германия, Израиль, Иерусалим һәм Кытай вәкилләре дә бар иде). Рәсми утырышлардан башка, һәртөрле очрашулар, банкетлар үткәрелде. Кемал, Юлай әфәнделәр, ирле-хатынлы ике америка французы безне аерым кунак иттеләр. Флора ханым, бүлмәсенә берничә кеше җыеп һәм шәйхелисламны чакырып, Бакый Урманче рухына Коръән укытты (Бакый аганың вафатына 51 көн тулган иде).

Мадисоннан зур бер канәгатьләнү хисе белән, ифрат тәэссоратлы хәлдә, рухи яктан ньк баеп юлга чыктык. Нью-Йоркта тукталыш ясадык, анда безне татар гаиләләре үзләренә бүлешеп алдылар (аңа кадәр М. Зәкиев белән М. Госманов, Техас штатына сәяхәт ясап, андагы университет белән танышып кайттылар). Мин Уфа галиме-этнограф Р. Кузеев белән Агишлар гаиләсендә тордым.

Нәркиз һәм Илдар Агишлар — ифрат та кече күңелле вә нәзакәтле, бик тә кунакчыл, 38—40 яшьләрдәге кешеләр. Илдар Нью-Йорк шәһәренең транспорт идарәсендә директор-администратор булып, Нәркиз «Пан-Америкаи аэролиния»сендә пассажирларга хәлиткеч ярдәм итү бүлегендә эшли. Ике кызлары һәм бер уллары бар, алар һәммәсе безнең Казандагы татар балаларын көнләштерерлек итеп саф татарча сөйләшәләр. Балалары ана телләрен онытмасын өчен, аларны мәктәпкә кадәр балалар бакчасына бирмиләр, гаиләдә тәрбиялиләр. Бу эштә аларга ике яктан да әти-әниләре булыша. Алар чыгышлары белән безнең яклардан, гражданнар сугышы вакытында язмыш үзләрен Кытайга илтеп ташлаган. Шуннан Төркиягә китеп, тора-бара Америка җиренә килеп эләккәннәр.

Шушы уңайдан хөрмәтле укучыларның игътибарын бер әйбергә юнәлтәсе килә. Бер даирә халык, бигрәк тә бездә Сталин төзегән казарма һәм лозунглар социализмына мөкиббән китеп, шуңа фанатикларча табынып яшәүче функционерлар һәм кайбер ветераннар Америкадагы, башка илләрдәге милләттәшләребезгә, «илләренә хыянәт итүче-

ләр», дип карарга яраталар. Еллар вә дистә еллар дәвамында башка сугып сеңдерелгән хыянәтчел идеология бу. Читкә китеп яшәргә мәҗбүр булган татарларның (һәм, әлбәттә, бүтән милләт вәкилләренең дә) һәрберсенең диярлек ачы язмышы бар.

Мин Нью-Йоркка килеп эләкән безнең як татары Мәҗит ага белән дә дуслаштым. Ул өендә дә, машинасында йөргәндә дә миңа үзенең гыйбрәтле үткәнен ачынып сөйләде. Сталинград сугышында, яраланып, әсирлеккә эләгә, шуннан соң — концлагерь тормышы. Аннан ике тапкыр кача, икесендә дә тоталар. Тагын лагерь, оккупация зонасы, союзниклар, Көнбатыш Германия, Америка. Бу — шул авыр заманнарда күпләр кичергән уртак язмыш. Ә олыраклар, әйткәнемчә, 20 нче еллар башында Кытайга барып эләгәләр. Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы меңнәрне түгел, миллионнарны төрле җирләргә сибә, төрле язмыш, төрле юллар үтәргә мәҗбүр итә. Татарларның күбесе башта руслар белән бергә Харбинда һәм Хайларда яшиләр (беренчесендә 100, икенчесендә 200 гә якын татар гаиләсе була), дус яшиләр, кытайлар аларга яхшы карыйлар. Тик 50 нче еллар башында Кытайга Мао режимын яклап совет гаскәрләре килеп кергәч кенә, элек Россиядән килгәннәргә көн бетә. Алар төрлесе төрле якларга китәргә мәҗбүр булалар. Татарларның күбесе Төркиягә килә. Мөселман һәм төркиләр дәүләте булганлыктан, анда татарларга яхшы мөнәсәбәт урнаша. Аларга шактый мөмкинлекләр тудыралар: биш ел буена налог алмыйлар, балаларын бушлай укыталар. Соңгарак аерым гаиләләр Америкага күчеп киләләр, күбесе моны балаларын университетларда белем алдыру өчен эшли. Татарлар тырыш, эшчән халык булгач, Кытайда да, Төркия һәм Америкада да аларны яраталар, яхшы эшләргә урнаштыралар. Боларны миңа шул озын-озак елларны һәм юлларны үткән, ул авырлыкларны үз җилкәләрендә татыган олы агайлар һәм апалар бик тәфсилләп сөйләделәр. Аларда туган җирләренә, Татарстан, Башкортстан, Пенза якларына булган мәхәббәт чиксез зур.

Аерылышканда Маһинур апалар, Габдулла абыйлар, мине кочаклап, «илгә сәлам әйт», дип елап калдылар. И, туган иленнән, газиз халкыннан еракта, чит-ят җирләрдә яшәргә мәҗбүр булган татар картлары, татар карчыклары! Күп газаплар кичеп, соңыннан, мул тормышка ирешкән һәм җан тынычлыгы тапкан, әмма ата-баба җирләрен, туган-үскән илләрне сагынып яшәүче кадерле затлар! Калган гомерегездә башка мәшәкатьләр күрмичә, кайчан да булса гүр иясе булганда кереп ятасы тар каберләрегез кин,

өсләрегезгә өеләсе авыр туфракларыгыз җиңел булып, игелекле балаларыгыз һәм оныкларыгыз илдән алып килеп, баш очларыгызга берәр уч туган җир туфрагы салсыннар иде!

Америка халкы, гомумән милләтләргә аерылмыйча «америкалылар» дип аталса да, кайберләрендә, бигрәк тә безнең татарларда, милли аңның үсүе һәм берләшү, туган телне, мәдәниятне, гореф-гадәтләрне саклау хисе көчле. Бу хисләрне үстерүдә, татарларны берләштереп торуда Американың татар җәмгыятьләре зур, мактаулы эшчәнлек алып бара. Андый җәмгыятьләр илнең өч зур шәһәрендә: Нью-Йоркта, Сан-Францискода һәм Вашингтонда, шулай ук Канадада бар. Алар арасында тыгыз элемтә урнашкан.

Мин Нью-Йорктагы җәмгыять белән таныштым, шуна күрә аның турында берничә сүз әйтәм. Җәмгыять 1927 елда төзелә, ул вакытта ул «Ислам берлеге» дип атала. 1960 еллар башында «Америка ислам җәмгыяте» дип үзгәртелә, ә 1973 елдан соң «Америка татар җәмгыяте» дип атала башлый. Җәмгыятьнең төп максаты — дөньяның шушы атаклы шәһәрендәге һәм башка җәмгыятьләр белән бергә бөтен Америкадагы татарларны берләштереп, аларга үзләренең телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен һәм, әлбәттә, ислам динен саклауда ярдәм итү. Бу җәмгыять Финляндия, Төркия, Австралия һәм Татарстандагы татарлар белән элемтәдә яши. Нью-Йоркның үзәгендә махсус биналары бар. Алар, шунда җыелышып, төрле кичәләр уздыралар, татар һәм гомумән төрки дөньясындагы яңалыклар, Казанда һәм Төркиядә басылган яңа китаплар, газета-журналлар белән танышалар, фикер алышалар. Шунда ук ураза, корбан гаетләрен уздыралар, җомга намазы укыйлар (Нью-Йоркта мөселман мәчете булса да, татарлар үзләре генә җыелышуны хубрак күрәләр). Муллалары Ногман Юлдаш, СССРдан килгән, 97 яшьне тутырса да, әлегә шактый таза, көр тавышлы, ачык мәкамле бер карт икән (мин аның үзен күрмәдем, мина сөйләүләре буенча шулай дип әйтәм).

Җәмгыятьнең рәисе — инде безгә таныш булган Илдар Агиш. Ул, менә дигән гаилә башлыгы, ата-анасына игелекле вә ихтирамлы булудан тыш, бик яхшы оештыручы да. Җаваплы эшеннән һәм гаилә тормышыннан бушаган вакытын һич кызганмыйча җәмгыять алып бара торган мактаулы эшкә биргән. Америка татарларының үткәне һәм хәзерге тормышыннан хәбәре зур. Аның әйтүенчә, бөтен илдә җәмгысы 300 дән артык татар гаиләсе бар, шуларның йөзе — Нью-Йоркта. Бер-икесен генә санамаганда, барлык

гаиләләр дә саф, милли гаиләләр һәм шул сафлыкларын киләчәктә дә сакларга тырышалар.

Нью-Йоркка килеп төшүнең өченче көнендә җәмгыятьтә безнең белән очрашу кичәсе уздырдылар. Без аларга Татарстан, Казан, илдәге татар тормышы, андагы соңгы үзгәрешләр турында сөйләдек, халкыбыз тарихы, аның теле һәм мәдәнияте мәсьәләләре буенча күптөрле сорауларга җавап бирдек. Эш көне булуга карамастан, кичә төнге сәгать икегә кадәр дәвам итте. Консерваториядә белем алган Асия ханым пианинода матур итеп халык көйләрен, Рөстәм Яхин әсәрләрен башкарды. Үзе генә дә, улы белән бергәләп тә яңа җырларны җырлады. Габдулла әфәнде Вафа, олы яшьтә булуына карамастан, моңлы гына итеп берничә җыр башкарды. Мин дә җырлаган булдым. Соңыннан, гадәттәгечә, һәммәбез бергәләп, аягүрә басып, «Туган тел»не җырладык. Күпләрнең күзләрендә яшь иде.

Шулай килеп чыкты: Мадисондагы конференциядән соң безнең 4 көн вакытыбыз калды һәм илгә кайтып киткәнче Нью-Йорк белән таныштык. Әлбәттә, шул кыска гына вакыт эчендә бу зур шәһәрне хәтта машинага утырып та карап бетереп булмый. Әмма Нью-Йорк турындагы беренче тәэссоратны алдык. 107 катлы небоскребның түбәсенә менеп, бөтен шәһәрне тамаша кылу (анда экскурсантларны тиз йөрешле махсус лифт алып менә), аллы-гөлле утлар белән җемелдәп торган кичке Бродвейны узулар, Берләшкән Милләтләр Оешмасының күккә ашкан биналары алдында рәсемгә төшүләр яки кытай ашханәсенә кереп экзотик азыклардан авыз итүләр — болар һәммәсе булды. Әмма алар белән бүгенге технократик рациональ дөньяның укымышлы затын шаккатыра алмассың. Эш анда түгел. Эш — әлегә безгә бик аз таныш булган яңа дөньяның кешеләрендә, аларның бер-берсенә искиткеч җылы, дустанә мөнәсәбәтендә. Юк, бездәге очсыз-кырыйсыз чиратлардан, кибетләрдәге буш киштәләрдән, җимерек өйләрдән, пычрак урамнардан, баткаклы юллардан тәмам гарык булган кырыс йөзле һәм ачулы кешеләр белән чагыштырганда шат күңелле, тук кешеләр яши, дигән баналь, күп кабатланган сүзләрне әйтәсем килми минем. Әмма бу туклык, бу муллык, бу мөлаемлылык — кадерле вакытның бер минутын әрәм-шәрәм итмичә, адәм баласына бирелгән һәр көннең, һәр сәгатьнең бөтен бәһасен аңлап, армый-талмый, төпкә җигелеп, тырышып хезмәт итү нәтиҗәсе ул. Бездәге тоталитар режимның әле бүген дә сукыр колы булып яшәүчеләргә минем бу сүзләрем ошамас, алар мине, шөбһәсез, «череп таркалучы капитализм»ны мактауда гаепләрләр. Урамда өй эчендәге кебек

чиста, шуңа күрә өйдә аяк киемен салмыйча йөриләр яки азык-төлек вә башка кибетләрдә җанын ни тели шул бар, дисәм, ышанмаслар, тагын да шул, «Көнбатышны идеаллаштырасың» кебек сүзләр әйтерләр. Әйтсәләр әйтерләр, кем нәрсә әйткәнгә аптырап йөреп булмый инде. Ышанмаганнар барып карарлар тагын.

Әлбәттә, бездәге коммунистик идеология каһарманнарын да шатландыра алам. Соңгы вакытта Америкада, бигрәк тә Нью-Йоркта, җинаятьчелек артып бара. Америкалылар үзләре: «Америка Нью-Йорктан чыккач кына башлана»,— диләр. Нью-Йоркта нормаль, гадәти кешеләрдән башка, дөньяның шактый әтрәк-әләмнәре, русча әйтсәк, «сброды» җыелган. Андыйлар бигрәк тә испан телле көньяк кешеләре арасында күп икән. Кичке аулак урамда берничә доллар өчен адәм канын агызу алар өчен берни дә тормый. Шуңа күрә, соңгы елларда кешеләр өй ишекләренә өстәмә бикләр, хәтта тимер челтәрләр дә куя башлаганнар. Менә бу да — Америка. Әмма ни генә булмасын, миңа тарихчы-галим буларак та, болай гына, күп нәрсә белән кызыксынучы алла бәндәсенә дә яңа дөньяга барып, аны үз күзләрем белән күреп, андагы гыйльми конференциядә катнашып, татар тарихы буенча кызыклы вә кадерле китаплар туплап, милләттәшләрем белән аралашып кайту бик тә файдалы эш, киләчәктә сагынып сөйләрлек якты бер хатирә булды. Мин Илдар Агиш, Мәҗит Гали, Габдулла ага Вафа, Әнвәр һәм Гыйльфан әфәнде Табилар, Рөстәм әфәнде Борлуҗа кебек яңа дуслар табып, аларның матур гаиләләре белән танышып кайттым. Без бардык та кунак булдык, инде үзегез килегез, дип әйтәм.

«Социалистик Татарстан»,
1990, 28 октябрь.

II. ТАРИХ ҺӘМ ЗАМАН

БОРЫНГЫ САРАЙГА СӘЯХӘТ

Казан — Волгоград поезды, Идел күперен үтеп, озак вакыт таныш җирләр буйлап чаба. Таныш диюем шул — әле берничә көн генә элек шушы Тау ягының елга үзәннәрендә мин археологик истәлекләр эзләп йөргән идем. Бу экспедиция шактый уңышлы булды. Инде өйрәнелгән материаллар өстенә, янәдән дүрт болгар шәһәре һәм күп кенә авыл урыннары, шулай ук яңа истәлекләр табылды. Бүген мин икенче экспедициягә — борынгы Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрен казуда катнашырга һәм яңа материаллар белән танышырга барам.

...Инде яңа иртә җиткән. Күз алдына икенче дөнья ачылып киткәндәй булды. Саратовны да (Сары Тауны) үткәнбез. Ландшафт безнең якларга караганда үзгә. Кая карама — тигезлек. Авыллар сирәк урнашкан; алар тирәсендә киң дала, тузанлы юллар. Карамыш станциясен узгач, дала хуҗалары — әкрен генә үлән кимереп йөрүче дөяләр очрый башлый. Ара-тирә кавын бакчалары күренеп кала. XX гасыр тудырган тиз йөрешле поезд белән шушы киңлекләрне ерып бару кызык һәм мавыктыргыч.

Поезддан төшүгә, автобуска утырдым да, Волгоград ГЭСы аша Иделне кичеп, Волжск шәһәренә килеп җиттем. Сарай урынына кадәр әле тагын 50 чакрым барырга кирәк. Бәхеткә каршы, шул якларга кайтучы бер машина очрады. Пассажирлары исә Сарай тирәсеннән булып чыктылар. Казаннан икәнемне белгәч, алар миннән Казан турында төпченә башладылар. Караңгы төшкәндә мин, машинадан төшеп калып, зур кыенлык белән археологлар лагерен эзләп таптым.

Сарай тигез урынга урнашкан. Көньякка таба җир азрак түбәнәя. Яшелчә бакчалары, камышлыклар, шулай ук таллар белән капланган ерымнар җәелеп ята. Бер чакрым чамасы көньяктарак Иделнең тармагы — Актүбә ага. Шәһәр урыны вак чирәм һәм дөя ашый торган чәнечкеле үлән белән капланган. Җир өстендә чүлмәк ватыклары, бакыр акчалар, кирпечләр чәчелеп ята. Бөтен мәйданда диярлек төрле зурлыктагы калкулыклар — борынгы сарай,

мәчет, пулатларның җир белән капланган нигезләре тезелеп киткән. Шунда XIV йөзнең атаклы гарәп сәяхәтчесе Ибн-Баттута сүзләре искә килеп төшә. Ул, Сарай — дөньяның иң матур һәм зур шәһәрләреннән берсе, дип әйтә. Анда 13 зур мәчет һәм күп санда башка биналар булган икән. Хәзер аларның берсе дә юк, билгеле. Әмма әле XX йөз башларына кадәр кайбер бина калдыкларын күрүчеләр була. Шул тирә авылларның берсе булган Сарай авылы карты, 85 яшьлек Хәкимҗан бабай Кутуев миңа яшь чагында зур бер мәчетнең диварларын күргәнен сөйләдс. Әйтергә кирәк, Сарайны XIX йөзнең 40 нчы елларында ук өйрәнә башлыйлар. Ләкин әле бу өйрәнү чын фәнни өйрәнүдән ерак тора. Дүрт ел бернинди системасыз һәм плансыз алып барылган казыну эшләре нәтиҗәсендә полковник Терещенко шактый зур материал туплый. Ул вакытта әле археология фәне яңа туып кына килә, методика эшләнмәгән була. Әмма Терещенко туплаган материалның фән өчен кыйммәте — аның бик бай һәм зур күләмле булуында. Ул әйберләрнең шактые югалуга карамастан, хәтта исән калганы да йөз елдан соң, ягъни безнең гасырның 30 нчы елларында Ленинград Эрмитажы залларында зур күргәзмә ачарга мөмкинлек бирә. Шушы кыйммәтле һәм бик күп төрле хәзинә — Шәрык дөньясының урта гасырдагы иң зур һәм бай шәһәрләреннән берсе булган Сарайның материаль культурасын күз алдына китереп бастыра.

Сарай шәһәре бик зур мәйданны биләп торган. Шәрыкны яхшы белүче А. Якубовский фикеренчә, анда 100 мең халык яшәгән. Шәһәр берничә зур районга бүленгән булган: шәһәр уртасында хан сарае һәм аны әйләндереп алган аксөякләр, сарай әһелләре, эре сәүдәгәрләр йортлары. Аның белән янәшә — шахристан һәм рабад, яки чын мәгънәсендә промышленность, һөнәрчелек һәм сәүдә районы. Бу инде Сарайның иң зур өлеше булган. Аерым бер урында административ үзәк — чиновниклар аппараты урнашкан. Язма истәлекләрнең мәгълүматларына караганда, Сарайның төп халкы төрки халык — кыпчаклар булган; сәүдә һәм һөнәрчелек үзәге буларак, бу шәһәрдә чит ил кешеләре дә — Урта Азия, Кавказ халыклары, руслар, греклар һ. б. яшәгән. Мәдрәсә һәм мәктәпләрдә, дин сабагыннан башка, дөньяви белем дә бирелгән. Татар әдәбиятының борынгы гүзәл үрнәкләре шушында туган.

Шәһәр читендә дача һәм кәрван-сарайлар урнашкан, Актүбәгә таба яшелчә һәм җимеш бакчалары тезелеп киткән булган. Бакчаларга арыклар буенча зур бер сусаклагычтан су килгән. Профессор Ф. Баллод әле 20 нче ел-



Үзле балчыктан ясалган язулы савыт. Сарай-Бәркә шәһәре

ларда гына шушы сусаклагычның аерым өлешләрен күрүен яза: буе 280, иңе 32 һәм биеклеге 16 метрга җиткән буа һәм аның капкалары (шлюзлар) һ. б.

Әйтеп киткәнемчә, Сарай зур промышленность һәм һөнәрчелек үзәге булган. Иң беренче чиратта металл (чуен, тимер, бакыр) эшкәртү алга киткән. Предприятиеләр мануфактура тибында булган. Аерым цехлар сугыш һәм эш кораллары, төрле көнкүреш әйберләре, савыт-сабалар ясаганнар. Археологик мәгълүматлар шулай ук ювелир әйберләр, чүлмәк савытлар, күнчелек, туку, тегү һәм агач эшкәртү мастерскойларының киң таралган булуын ачыклыйлар. Сарайда шәһәр төзү техникасы һәм архитектура алга киткән. Безнең көннәргә кадәр зур архитектура ансамбльләре сакланмаса да, археологлар тапкан күп сандагы майолика һәм мозаика төрләре Сарай йорт төзү сәнгатенең Урта Азия йорт төзү сәнгатенә якынлыгы турында сөйлиләр. Сарайда эшләнгән ялтыравыклы керамика (балчык савытлар) үзенең зиннәтле булуы белән таңга калдыра.

Заманыбызның зур тарихчыларыннан академик Б. Греков һәм А. Якубовский әйтүенчә, Алтын Урда үзенең ике йөз елдан аз гына артык яшәү дәверендә гаять үзенчәлекле культура тудыра. Бу культураның үз осталары, рәссамнары һәм үзенә генә хас мәктәбе була.

Сарай заманында бөтен Көньяк-Көнчыгыш Европада иң зур сәүдә үзәге дә булган. Транзит сәүдәсен үз кулында тотудан башка, ул үзендә җитештерелгән товарларны да күп чыгарган. Шул заман сәүдә әйләнешендә булган кай-



Архитектур майолика — чынаяк кирпеч. Сарай-Бату шәһәре

бер әйберләрне санап үтү кызыклы булыр: ашлык (бодай, арпа, тары, ясмык, борчак, дөге), мамык, йоннан, ефәктән, киҗе-мамыктан эшләнгән тукымалар, күн әйберләре, мәгъдән (тимер, бакыр, көмеш һ. б.), сугыш кораллары, ялтыравыклы керамика, алтын һәм көмеш савытлар, зиннәтле җиһазлар, аш тәмләү әйберләре.

Сарайның материаль культурасы, аның тарихи топографиясе 20 нче елларда В. Баллод тарафыннан казулар нәтиҗәсендә тагын да тулыландырыла. Шуннан соң тукталып торган эш бары тик 1959 елда гына дәвам иттерелә. СССР Фәннәр академиясенең һәм Мәскәү университеты-

ның тарих фәннәре докторы Г. Федоров-Давыдов җитәкчелегендәге археологик экспедициясе бу шәһәр урынында яңадан зур казу эшләре башлап җибәрде. Экспедиция эшендә В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан университеты да зур активлык күрсәтә. Соңгы еллардагы тикшеренүләр нәтиҗәсендә шәһәрнең социаль топографиясе буенча кайбер мәсьәләләр ачыкланды, берничә тәрдәге йортлар, аерым мастерскойлар казылды, бай материал җыйналды. Сарайның сынлы һәм гамәли сәнгатен раслаучы дәлилләр табылды.

Быел археологлар бер торак йорт казыдылар. Йорт таш койма белән әйләндереп алынган, уртада өй. Ул берничә бүлмәдән тора, стеналары яндырылган кирпечтән өелгән. Шундый ук кирпечләрдән түшәлгән идәннәр берничә бүлмәне күз алдына китерәләр. Ике ак яки кунак бүлмәсеннән башка, өйне җылыту һәм ашарга пешерү бүлмәсе дә бар. Ашарга әзерләү миче кызыклы: учак авызы турыдан-туры чүлмәк сыман зур бер балчык савытка тоташа, аның төбе тулы көл. Монда, күрәсең, көлчә пешергәннәрдер. Хәзерге татарлар пешерә торган көлчәнең көл сүзеннән алынганын аңлавы кыен түгел; һәм бу табылдык шуның бер борынгы чагылышы булып тора. Әлеге аш бүлмәсенең идәненә зәңгәрсу чынаяк кирпеч түшәлгән.

Менә шушы югарыда кыскача сөйләп үтелгән шәһәр Сарай-Бәркә дип аталган. Билгеле булганча, Алтын Урдада ике Сарай булган. Аның берсе, Бату (Батый) хан тарафыннан төзелеп, Сарай-Бату дип аталган һәм XIII йөздә Урданың башкаласы булган. Инде XIV йөзнең I яртысында, ягъни Үзбәк хан заманында башкала икенче шәһәргә — Батыйның энесе Бәркә төзегән Сарай-Бәркәгә күчерелгән. Бу яңа Сарай Алтын Урда җимерелгәнче аның башкаласы булып торган, һәм Шәрык географларының мәгълүм язмалары да инде шушы Сарай турында. Әмма Сарай-Бату яшәүдән туктамаган, заманында «Иске йорт» дип аталса да, илнең икенче бер шәһәре — һөнәрчелек һәм сәүдә үзәге булып яши биргән. Соңгы ике елда археологлар бу шәһәр калдыгын да казый башладылар.

...Яңа таң атып килә. Салкын, җиләс. Машина, лагерьдан чыгып, Әстерхан ягына юл ала. Кузовта — Сарай экспедициясенең отряд җитәкчесе Әзһәр Мөхәммәдиев белән без икәү. Безгә бүген, яктыру белән, Иске Сарайга барып җитәргә кирәк. Ара 260 чакрым, ә юллар алай ук мактарлык түгел. Сентябрь булуга карамастан, көндезләрен эссе. Очсыз-кырыйсыз Әстерхан далалары көндезге рәшә астында чиксез булып күренә. Анда-санда рус, казах, нугай авыллары күзгә ташлана. Сасы Күл авылына килеп җи-

тәрәк — тәңкә яфраклы куаклык белән капланган ярымчүл башлана. Рельеф әкренләп биекләнә, калкулыклар күбәя. Озакламый менә шул калкулыклар арасына урнашкан Сарай-Бату урынына килеп керәбез. Калкулыклар арасында инде кибәргә өлгергән күл урыннары җәелеп ята. Кояшта яныл тыгызланган җир өстендә кушаяк, тузбаш һәм агулы еланнар, бөе (фаланга), чаян, чүл кәлтәләре хөкем сөрә. Аларны күрмәскә тырышкандай, көннәр буе дөяләр чәнечкеле үлән чемченә. Шушы чүл һәм дала хайваннары дөньясын борынгы тарихның телсез шаһитлары — җир өстен тутырып яткан гади һәм кыйммәтле балчык савыт ватыклары, акчалар, зиннәтле сарайларны һәм мәчет-дөрбәләрне бизәгән чынаяк кирпеч кисәкләре бизи. Ә гади кирпечнең хисабы юк. Археологлар монда берәр ай эшләсә, калган вакытта Селитряное авылы кешеләре хуҗа. Алар инде үз эшләрен беләләр: борынгы кирпечләрне өй нигезенә салсаң да әйбәт, келәт төзеп җибәрсәң дә тазага килә. Җитмәсә, бөтенләй буш материал, җирне бераз гына тырнасаң, килә дә чыга. Шушы кирпечләр белән 1578 нче елда хәзерге Әстерхан кремле салына, шушы кирпечләрне җирле халык менә инде 400 ел буена үз кирәк-ярагына тота. Ә алар һаман бетмиләр, Иске Сарайның мәйданы 36 квадрат километр ләбаса...

Сарай-Бәркә шәһәре урынында табылган чүлмәк; эчке ягында — арыслан баласы рәсеме

Әле соңгы елларда гына казыла башлаган шушы Сарай-Бату калдыклары Идел буе төрки халыклары, аерым алганда, татарлар тарихына, һичшиксез, яңа сәхифәләр кертер. Әлләни зур күләмдә булмаган беренче эшләр дә кызыклы мәгълүматлар бирде. Казылган мастерскойлар мәрҗәннәр һәм кыйммәтле керамиканың шушында эшкәртелүен исбатлый.

Алтын Урда дәүләте XIII йөзнең I яртысында булган монгол яулап алулары нәтиҗәсендә төзелсә дә, аның эко-

номикасы һәм культурасы җирле төрки халык яшәгән нигездә барлыкка килә. Ә бу халыкның меңәр ел буена сузылган тарихы, тир һәм кан түгеп җыйган байлыгы бар. Соңыннан Алтын Урда культурасы дип аталган бай һәм үзенчәлекле культура шушы җирле халык культурасы үсешенең яңа баскычы булып тора. X—XII йөздәге Идел буеның культура үзәге саналган Болгар иле, Алтын Урда составына кергәч, болгар культурасы Алтын Урда культурасының нигез ташларын салуга зур өлеш кертә. Мәгълүм булганча, болгар дәүләтендә шәһәрләр бик күп була һәм Болгар шәһәр культурасы Алтын Урда шәһәр культурасын булдыруда катнаша. Үзенең алга киткән авыл хуҗалыгы белән Болгар иле Алтын Урданың иң бай экономик районына әверелә. Урда шәһәрләрен казыганда археологлар бик күп болгар әйберләре табалар, шулар арасында алтын яки көмеш чыбыктан үреп ясалган зиннәтле әйберләр, кара көмеш йөгертелгән төрле савыт-саба, чәчәк бизәкле бронза көзгеләр, ат яки эт формасында эшләнгән кечкенә йозаклар һ. б. Ике Сарайда да табылган гади керамика белән танышырга туры килде миңа. Әйтергә кирәк, ул үзенең тышкы күренеше, бизәкләре һәм балчык составы буенча болгар керамикасына якын...

«Татарстан яшьләре»,
1968, 14 март.

БОЛГАР ШӘҺӘРЛӘРЕ БУЙЛАП

...Май урталары. Табигатьнең иң матур чагы шулдыр дисәк, һич тә ялгыш булмас. Болыннар, үзәнлекләр, яр буйлары яшел чирәмгә төренеп өлгергән, урман да инде үзенең соргылт-көрән төсеннән арынып, яшел юрганын ябынган. Шул саф яшеллекне тагын да яктырта төшеп, алма, шомырт һәм миләш агачлары шаулап чәчәк атып утыралар. Тирә-якны яңгыратып сандугачлар һәм тургайлар сайрый. Язгы ыгы-зыгыдан, мәшәкатьләрдән бушанган табигать, тәмам иркен сулыш алып, яшәрә, гүзәлләнә.

Эш беткәч, урман буенда лагерь корып җибәрдек. Кичке ашны ашап бетергәндә, караңгы да төште, әмма урман артыннан яктырып күтәрелгән тулы ай шул караңгылыкны таратып җибәргәндәй итте, бөтен тирә-юньне бертөрле илаһи моңга күмелде. Бүген 1970 елның 19 мае. Быелгы археологик эшләрнең уңышлы башлануына һәм язгы табигатьнең гүзәллегенә хозурланып учак янында утырганда, күз алдына бер борынгы тарихи вакыйга килеп басты.

...Моннан нәкъ 1048 ел элек, ягъни 922 елның 19 маенда Болгар бие Алмас Багдадтан килгән илчелекнең секретаре Ибн Фадланны үз янына чакыртып ала һәм аны, кем әйтмешли, утлы табага бастыра: кайда хәлифә тарафыннан җибәрелгән 4 мең динар? Югыйсә, илчелекнең төп максатларыннан берсе шул бит — дошманнардан саклану өчен Болгар илендә шәһәр корырга дип Багдад хөкүмәтеннән соралган акчаны Алмаска илтеп тапшыру. Ибн Фадлан акчаларның бер ел буе үтелгән озын юлда күптөрле авырлыкларга дучар булган илчелек өчен тотылуын әйтергә мәҗбүр була.

Икенче бер киңәшмәдә Ибн Фадлан дипломатик адым ясый: «Дәүләтең синең зур, байлыгың күп, керемең мул»,— ди ул Алмаска, янәсе, нәрсәгә сиңа акча. Ачуы басылган би шундый җавап кайтара: «Дөрес, шәһәр төзергә минем үз алтын-көмешләрем дә җитәрлек, тик миңа хәлифәнең үз кулы белән биргән акчасы, аның фатихасы, аның исеме кирәк иде»,— ди.

Әйе, болгарлар чыннан да читтән ярдәм көтеп тормыйлар, үз көчләре белән шәһәр төзиләр. Һәм берне генә дә түгел...

Менә без бүген яңа бер шәһәрлек таптык; ул Алексеевск районы, Ромодан авылыннан 2 чакрымда, Актай суының уңъяк кушылдыгы буенда урнашкан. Мәйданы зур түгел, 18000 кв. м гына. Гадәттә, мондый кечкенә шәһәрлекләр феодал замокларның калдыклары булып саналалар. Замокларны феодаллар (безнеңчә — бәкләр) чит дошманнардан һәм үзенә буйсынган крестьяннарның баш күтәрүләреннән саклану өчен төзегәннәр. Бу — бөтен урта гасырлар тарихына хас әйбер. Замокта феодал, аның якыннары, дружинасы, идарәсе торган, тирә-якта аның карамагындагы авыллар урнашкан булган. Тора-бара, житештерү көчләре үсешенең аерым бер чорында, төгәлрәк әйтсәк, һөнәрчелекнең авыл хуҗалыгыннан аерылып чыгуы нәтиҗәсендә, аерым феодал биләмәләр шәһәрләргә әйләнеп китәләр: замок (кирмән) шәһәрнең кремле, кальгасы ролен үти башлый, ә тирә-як авыллар бистәгә әйләнә. Элегрәк кирмән үзе генә валлар, урлар белән әйләндереп алынып, авыллар ачык, ныгытмасыз калдырылган булсалар, шәһәр барлыкка килгәч, ул инде бөтенләй шундый урлар белән ныгытылып алына. Ләкин мондый күренеш һәр чор өчен дә хас дип әйтеп булмый. XIII—XV йөзләрдә безнең якларда ачык шәһәрләр дә шактый күп булганнар, ул чагында инде шәһәрләрнең бары тик кальгасы гына ныгытылган булган. Мондый шәһәрләр рәтенә Иске Казан, Җүкәтау, Тубылгытау, Кирмәнчек, XIII йөздә Болгар керә (XIV—

XV йөзләрдә Болгар — ябык шәһәр). Ачык шәһәрләр булу нигездә Алтын Урда дәүләтенең политикасы белән аңлатыла: монгол ханнары, үзләре яулап алган халыкларны буйсындырып тоту өчен, аларга ныгытмалар төзергә рөхсәт итмәгәннәр. «Гаскәрләр керүгә комачауламас өчен, шәһәрләргә дивар һәм капкалар эшләргә рөхсәт итмиләр», — дип яза XIII йөзнең уртасында Кытайга сәяхәт кылган Марко Поло.

Аксубай районының Шәрбән авылында табылган хәзинәдәге бизәкле болгар чүлмәге

Бу күренешне Алтын Урда заманына хас дидек. Әмма X—XII йөзләргә караган Ромодан шәһәрлеге мисалында, ачык шәһәрләр элегрәк тә булмагае, дигән фикергә киләбез. Шәһәрлеккә, ягъни кальга урынына тоташып ук киткән бистә урыны бик зур, 975000 кв. м. Бу — һичшиксез, шәһәргә хас мәйдан һәм ул кальга белән бөтен бер ансамбль тәшкил итә. Бистә урында табылган аерым табылдыклар да бирелдә шәһәргә хас һөнәрчелек булганлыгын сөйлиләр. Мәсәлән, сфероконус дип аталучы кечкенә генә йомры савыт. Кечкенә, ләкин «эче төш кенә» — мондый савытларда металлургия өчен ифрат кирәкле терекөмеш саклый торган булганнар. Гомумән, безнең алда монголларга кадәрге чорның ачык шәһәре дип фараз кылырга нигез бар сыман. Ләкин бу чорда мондый шәһәрләрнең булуын нәрсә белән аңлатырга соң? Беренче чиратта, Болгар җирлегендә крепостнойлыкның киң җәелеш алмавы, Болгар феодализмының крепостнойлыкка түгел, ә икенче төр эксплуатациягә нигезләнгән булуындадыр? Феодал замокларының калдыклары дип санап йөртелгән шәһәрлекләрнең дә кайберләрен чын шәһәр урыннары дип әйтергә һәм шәһәрләр без уйлаганнан күбрәк булган дигән нәтиҗә ясарга нигез юк түгел.

Экспедиция вакытында мондый төрдәге шәһәр урыннары тагын да табылдылар. Берничә көннән без Аксубай

районының Байлар Енарускиносы исемле кечкенә генә рус авылы янында урнашкан тагын бер шәһәр урынын тикшердек. Бусының да мәйданы шактый зур — 665400 кв. м, шуның 30400 кв. метрын гына кальга биләп тора. Бу шәһәр, Ромодан авылы янындагысыннан үзгә буларак, Болгар тарихының ике чорына да, ягъни X—XIV йөзләргә карый. Соңгы чордан шәһәр мәйданында тарихыбызның иң кыйммәтле ядкәрләреннән саналучы эпиграфик истәлекләр — кабер ташлары — сакланып калган. Алар 1320—1330 елларда куелган.

Экспедиция өйрәнгән бөтен шәһәрлекләр турында да сөйләргә җыенмыйбыз һәм ул газета рамкаларында мөмкин дә түгел. Шулай да соңгы ике елда тупланган материал безне тагын берничә истәлеккә тукталырга мәҗбүр итә. Алар арасында урта гасырлар шәһәренең классик формасында, ягъни бөтен мәйданы урлар белән әйләндереп алынган шәһәр урыннары бар. Шундыйларның берсе Биләрдән ерак түгел Балынгуз тавында урнашкан. Зурлыгы ягыннан ул болгарларның иң зур шәһәрләре рәтенә керә. «Болгар шәһәрләре» исемле мәкаләдә («Казан утлары», 1970, № 2), кайбер язма истәлекләргә таянып, без аның турында бераз мәгълүмат биргән идек һәм аны, 1184 елда Владимир кенәзенең һөҗүме вакытында шәһри Бүләргә ярдәмгә килгән шәһәрләрнең берсе, төгәлрәк әйткәндә, Торцк (Төрек?) шәһәредер, дип әйткән идек. Безнең экспедиция шәһәрнең культуралы катламын өйрәнде һәм аның, һичшиксез, монголларга кадәрле дәвергә караганлыгын ачыклады.

Чистай районының Екатерина Бистәсе авылы янында урнашкан һәм әлләни зур булмаган шәһәр урыны (180000 кв. м.) үзенең төзелеше һәм ныгытмаларының ифрат та катлаулы булуы белән кызыклы. Шәһәр ике кат ныгытма белән әйләндереп алынган булган. Тышкы ныгытма бер рәт ур һәм ур чокырыннан, ә эчкесе өчәр рәт урлардан һәм чокырлардан гыйбарәт. Ике ныгытма арасында киң генә аралык бар. Тышкысын үтә алганда да, шул аралыкка килеп чыккан дошман эчке, төп линияне саклаучы гаскәрнең уты астында калырга тиеш булган. Әлеге эчке ныгытма чын мәгънәсендә лабиринт. Эченә керсәң, чыга алуыңны уйлама да. Капкалар эзләп азапланганда, һичшиксез, күкрәгеңә яки аркаңа ук алачаксың. Болардан тыш, шәһәр мәйданы ике-өч рәт өстәмә урлар белән ике өлешкә бүленгән. Һич сүз юк, ныгытмалар искитәрлек оста эшләнгән. Алар белән танышканнан соң, А. П. Смирновның «Идел болгарлары» исемле китабында әйткән: «Болгарларда хәрби-инженерлык эше тиешле юга-

рылыкта торган һәм аларның оборона системасы ул заманның хәрби техникасы таләпләренә җавап бирә алырлык дәрәҗәдә булган», дигән сүзләренең дөреслегенә тагын бер мәртәбә ышанасың.

Сүз юк, болгарлар ныгытмаларны төзи белгәннәр. Ләкин ничек итеп төзегәннәр? Бу сорау археологны гына түгел, әлеге ныгытмаларны күргән һәркемне кызыксындыра. Кай урыннарда биеклеге әле дә 10 метрга җиткән һәм формасын саклап калган шушы урлар алдында торганда, мондый сорауның тууы бик табигый. Болгарларның ничек итеп ныгытмалар, кальгалар салулары хакында язмалар булмаса да, башка күрше халыклар турында язылган истәлекләргә мөрәҗәгать итү мәсьәләгә бераз ачыклык кертә. Европага сәяхәт кылган географ Ибраһим ибн Якуб үзенең 965 елда язган китабында славяннарның крепость төзүләрен түбәндәгечә тасвирлый: «Крепостьларны славяннар күп вакытта болай төзиләр: алар сулы һәм камышлы болынга барып, үзләренә нинди крепость кирәк — түгәрәкме, дүртпочмаклымы, зурмы, кечкенәме — шундый урын билгеләп алалар. Һәм шул урын тирәли чокыр казып, аннан чыккан туфракны валларга өяләр; туфракны такталар һәм субайлар белән аралаштырып тыгызлыйлар, һәм шул рәвешле вал өелеп бетә. Шуннан соң кайда кирәк, шул яктан капка калдыралар һәм аның алдына агач күпер эшлиләр».

Славян крепостьларының болгар кальгаларына нык охшашлыгын искә алсак, болгарлар да шул рәвешле төзегәннәрдер дияргә кала. Кызганычка каршы, ул ныгытмаларның нинди эшче көчләр белән төзелүләре хакында хәбәрләр юк. Бу турыда заманында академик Б. Греков һәм профессор А. Смирнов арасында беркадәр фәнни бәхәс тә булып алган иде. Шәһәрләр, ныгытмалар төзү мәсьәләсе кечкенә мәсьәлә түгел, ул җәмгыятьнең социаль строен билгеләүгә ачыклык кертә. А. Смирновның, болгар кальгалары крепостной крестьяннар тарафыннан төзелгәннәр, дигән фикере белән килешмичә, Б. Греков ул ныгытмаларның коллар яки азат халык тарафыннан төзелүе мөмкинлеген куәтләп чыкты. Ныгытмалар нигездә дәүләт тарафыннан халык көче белән эшләнгәндер, дигән фикер чынбарлыкны күбрәк чагылдырадыр төсле. Дөрес, феодал замокларын төзүдә соңга табарак крепостнойларның да өлеше булмый калмаган. Әмма шәһәрләрнең, сәүдә һәм хәрби юлларны саклау өчен төзелгән кальгаларның ныгытмалары, һичшиксез, дәүләт тарафыннан эшләтелгән булырга тиеш. Безнең экспедиция бу фикерне расларлык яңа дәлилләр дә тапты. Чистай һәм Чирмешән районнарының

Яңа Чишмә, Елховка һәм Кармыш авыллары янында һәрберсенең озынлыгы 8—9 чакрымлы 3 вал бар. Болар — шәһәрлекләр түгел, ә нәкъ менә аерым мөстәкыйль урлар һәм алар Болгар дәүләтенең төп халкы урнашкан үзәк җирләрен көньяк-көнчыгыштан саклау өчен чик буе ныгытмалары ролен үтәгәннәр. Аларның төзелеше, планировкасы һәм топографиясе белән танышкач, әлбәттә, үзәкләштерелгән дәүләт тарафыннан эшләнгән булуларына шик калмый. Бу фикерне шулай ук дәүләт иминлеген саклау өчен төзелгән крепость-кальгалар да раслыйлар. Андыйлары Шушма (Шешма), Сөлчә һәм Олы Чирмешән буйларында табылды. Аларның кайберләре югарыда телгә алынган озын валларга кушып, шул валларның терәк пунктлары, стратегик базалары рәвешендә эшләнгән.

Әгәр дә бөтен болгар шәһәрләренең, кирмәннәрнең, хәрби кальгаларның ныгытмаларын һәм аерым валларны бер рәт итеп тезсәң, аның гомуми озынлыгы йөзләрчә чакрымга җитәр иде. Урларның хәзер дә әле, ягъни төзелүләренә 600—900 ел вакыт узгач та, биек булуларын, аларның бүрәнәләр һәм субайлар белән ныгытылып, аралаштырып өелүен һәм, ниһаять, шул урлар өстендә ике рәт бүрәнәләрдән салынган имән диварлар да булуын искә алсак, бу эшләрне башкаруга ифрат зур көч сарыф ителүенә хәйран каласың.

Аларны хәрби әсирләр төземәдеме икән, дигән сорау да туа. Б. Греков та коллар турында фараз кылганда, нәкъ менә шундый әсирләрне күз алдында тоткан булса кирәк, югыйсә, Болгар дәүләтендә колбиләүчеләрнең булмавы билгеле. Шуңа күрә, әсирләр төп эшче көчен тәшкил иткәннәрдер дип әйтергә урын юк. Мәгълүм ки, хәрби әсирләрнең чыганагы булып яулап алу сугышлары санала, ә болгар тарихына кагылышлы күп санлы рус елъязмалары һәм гарәп-фарсы географиясе белән танышкач, болгарларның андый сугышларны аз алып барулары ачыклана. Димәк, корылмалар төзүнең үзәкләштерелгән дәүләт тарафыннан халык көче белән эшләнүе бәхәссез. Мәгълүм ки, бу кадәр зур эшләр зур байлык таләп итә. Менә шунда инде тагын бер тапкыр Алмас белән Ибн Фадлан арасындагы сөйләшү искә килеп төшә, һәм аның буш сүз булмавына, дөреслекне чагылдыруына ышанасың.

Ибн Фадланның Болгар турындагы сүзләре, дипломатик калыпка салып бирелсәләр дә, дөреслектән ерак түгел. Ел саен болгар җирләре буйлап археологик разведка ясап йөргәндә, мин моның шулай икәнен үз күзләрем белән күрәм. Менә соңгы ике елда гына да Кама аръягы һәм

Ульяновск өлкәсендә 4 мең чакрым юл үттек. Исең китмәле: иксез-чиксез урман-дала буйлап машинада көненә берничә йөз чакрым чабабыз — һәм болар бары да Болгар иле, болгар җирләре. Әле берничә көн генә элек Самар тугае тирәләрендә идек, ә хәзер Шушма (Шешма) буйларында. Шушы озын юл шәһәрлекләр һәм авыл урыннары аша уза. Түбән Кама ярларымы, Сембер яки Самар якларымы — шундый ук археологик истәлекләр: зурысы да, кечесе дә.

Ульяновскидан ерак түгел, Иске Әләйке авылы янында зур гына бер болгар шәһәренең урыны бар. Мәйданы ягыннан мәшһүр шәһре Болгардан калышса да, икенче бер атаклы Суар шәһәреннән бермә-бер зур. Шәһәрнең кремле генә дә 25 гектар булган. Бөтен шәһәр ике-өч кат ныгытма белән әйләндереп алынган. Шәһәрдән өч чакрым читтәрәк, урман белән Зөя суы арасында өстәмә ныгытма — вал бар. Биеклеге әле дә 5 метрга җиткән бу зур ур-вал шәһәрне көньяктан, күчмәләр һөҗүменнән саклаган. Гомумән, зур шәһәр булган биредә, ләкин аның исеме әлегә билгеле түгел. Бәлки, киләчәктә археология кайбер башка фәннәр (эпиграфика, топонимика, палеолингвистика) ярдәмендә менә шуның кебек инде тарих битләреннән төшеп калган шәһәрләрнең исемнәрен табар. Хәзергә бер нәрсә ачык: Болгар дәүләтенең политик үзәкләреннән еракта да, аның көньяк җирләрендә зур экономика һәм культура үзәкләре булган. Әйе, Болгар иле чын мәгънәсендә шәһәрләр иле булган.

Хәзерге вакытта урта гасыр шәһәрлекләренең тулы археологик картасы төзелде. Ул 157 шәһәрлектән гыйбарәт, шуларның 120 се Татарстанда, утызы Ульяновск өлкәсендә, дүртесе Чувашстанда, өчесе Куйбышев өлкәсендә. 114 шәһәрлек Казан археологлары тарафыннан Бөек Ватан сугышыннан соң, аларның да күп өлеше соңгы унъеллыкта тикшерелде. Икенче бер статистиканың да зур фәнни әһәмияте бар: 38 шәһәрлек зур һәм кечкенә шәһәрләрнең калдыгы санала (шуларның 12 сенең тарихи исемнәре билгеле: Болгар, Бүләр, Суар, Ашлы, Җүкәтау, Тубылгытау, Кирмәнчек, Иске Казан, Казан, Арча, Тәтеш, Төрек), 20 шәһәрлек — хәрби кальгалар; калган күпчелеге — бәк утарлары, кирмән-замоклар.

Киләчәктә археологлар алдында тагын да зур эшләр тора. Казып тикшерелгән һәм тикшерелеп килүче берничә шәһәргә өстәп, төрле җирлеккә һәм төрле чорга кагылышлы төрле типтагы шәһәр, кирмән һәм хәрби кальгаларны җентекләп, стационар юл белән өйрәнү болгар җирендә шәһәрләр проблемасын, аларның барлыкка килү һәм үсеш

закончалыкларын, социаль һәм тарихи топографиясен ачыклауда зур эш булыр.

«Социалистик Татарстан», 1972, 2, 3 март.

БОРЫНГЫ БОЛГАРДА ИСЛАМ ДИНЕ КАБУЛ ИТЕЛҮГӘ 1100 ЕЛ[1]

Барыннан да элек, исламның үзенә, аның тарихта һәм хәзерге тормыштагы, күп кенә илләрнең рәсми идеологиясендәге роленә тукталып үтмичә ярамас, шунсыз мәсьәлә ачыкланып бетмәс. VII йөзнең беренче яртысында Гарәбстан ярымутравында (бүгенге Сәгуд Гарәбстаны) барлыкка килгән ислам дине хәзер дөньяда иң киң таралган диннәрдән санала. Исламның килеп чыгу мәсьәләсе әле ахыргача ачыкланып бетмәгән. Заманында академик В. Бартольд исламның барлыкка килүен социаль-экономик тарихның бер күренеше дип атаган иде. Исламның бүгенге тарихчылары, мәсьәләнең дини ягын инкарь итмәгән хәлдә, ислам зур бер чорның иҗтимагый фикере буларак туды, дип әйтәләр. Ә ул чор — гарәп дөньясының борынгы общиналар строеннан сыйнфый җәмгыятькә күчүе белән бәйле мөһим тарихи эпоха.

Нәкъ менә шундый бөек борылыш чорында зур акыл иясе, оста дипломат һәм зирәк политик Мөхәммәд (ул 570—632 елларда яшәгән) гарәпләрнең алдынгы кабиләләре арасында барлыкка килгән күтәрелешне, җәмгыять куйган яңа зур тарихи-социаль таләпләрне дөрес аңлап, өр-яңа тәгълиматка, бүтән чор идеологиясенә, дөньяга башкача карашка нигез сала. Шунысы бик тә әһәмиятле: ул заманнан бирле 13 гасырдан артык вакыт узып китте, дөнья гаҗәеп зур үзгәрешләр кичерде, ә ислам шул гомер эчендә искермәде генә түгел, ә бүгенге иң зур идеология системаларының берсенә әйләнде.

Бүгенге көндә ислам дөньяның 44 илендә хакимлек итүче идеология булып санала, ә аларда барлыгы 800 миллионга якын халык яши. Бу санга безнең илнең ислам динен тотучы яки пассив рәвештә шуның тарафдарлары булганнарны (аларның төгәл санын әйтүе кыен), шулай ук дөньяның бик күп илләрендәге мөселман җәмгыятьләрендәге (андый җәмгыятьләр бүгенге көндә Европа һәм Америка илләрендә дә шактый) мөслим вә мөслимәләрне дә кушсаң, бер миллиардка якын кеше килеп чыга. Гомумән,

---

[1] Бу язма «Татарстан яшьләре»ндә «Ерак заманнар кайтавазы» исеме белән басылды — 1989, 11 июль.

ислам дине, христианлыктан кала, дөньяда икенче иң зур дин санала.

Мәгълүм ки, ислам бигрәк тә Шәрыкта күп таралган. Бу — бөтен бер гарәп дөньясы, Якын һәм Урта Көнчыгыш илләре, Көньяк һәм Көньяк-Көнчыгыш Азия. Безнең гасырның урталарында аның тәэсире тропик Африка илләрендә дә нык көчәйде. Азия һәм Африканың алга киткән илләрендә соңгы вакытта диннең кеше шәхесенә һәм җәмгыятькә, шул исәптән политикага да йогынты ясау дәрәҗәсе Көнбатыш илләренекеннән шактый өстен тора, ә исламның иҗтимагый функцияләре исә христиан диненекеннән асылы белән дә, формасы белән дә нык аерылалар. Көнбатышның гына түгел, ә Көнчыгышның да башка диннәреннән аермалы буларак, исламның политика белән бәйләнеше күпкә көчле. Бу социаль мөнәсәбәтләрдә һәм идеологиядә генә түгел, ә дәүләт структурасында һәм иҗтимагый тормышта да ачык чагыла. Исламны өйрәнүчеләрнең күпчелеге билгеләп үткәнчә, ислам элек тә, бүген дә дин тәгълиматы буларак кына түгел, ә дөньяга караш, культура һәм милли үзенчәлек символы буларак та үсеш алды һәм ала.

Соңгы вакытта байтак илләрдә исламның политикалашуы, мөселман сәяси хәрәкәтенең киң колач җәюе күпләргә мәгълүм. Әйтик, Иранда 70 нче еллар ахырында башланган революцияне ислам көчләре алып барды, һәм алар җиңеп чыктылар. Кайбер башка ислам республикаларының үсеш процессында да мондый хәрәкәтнең әһәмияте хәлиткеч булды. Бүгенге көндә Палестинада туган катлаулы хәлдән чыгуда, гарәп илләренә каршы сионизм башлаган гадел булмаган көрәштә мөселман хәрәкәтенең прогрессив роле нык сизелә. Гомумән, бүгенге көннең Шәрык дөньясында, аның иҗтимагый тормышында «ислам факторы» калкып чыкты, ул күп кенә илләрне, политик даирәләрне һәм әйдәп баручы көчләрне уйланырга, аңа йөз белән борылырга мәҗбүр итте.

Ислам дине барлыкка килгәннән соң тиз арада канат җәя. Беренче меңъеллыкның ахырларында ул бүгенге илебез территориясенең кайбер районнарына — Төньяк Кавказдагы Хәзәр каханлыгына, бигрәк тә Урта Азиягә үтеп керә. Урта Азиядән төньякка, Идел буйларына — Болгар иренә тарала башлый. Болгарларга ислам диненең керә башлавы хакында күренекле фарсы географы Ибн Рустәнең 903—913 еллар арасында язган энциклопедик хезмәтендә мәгълүматлар бар: болгарларның патшасы Алмас (күп кенә галимнәр шушы форманы яклый, ә Алмуш түгел) инде ислам кабул иткән, алай гына да түгел, халыкның

күпчелеге ислам динендә, авылларда мәчет һәм мәктәпләр, мәзин һәм имамнар бар. Кигән киемнәре дә, каберлекләре дә мөселманча.

Кайбер галимнәр, Ибн Рустә үзе мөселман булгач, исламның ерак төньяк җирләрдә киң таралган булуын күрсәтү өчен болгар халкының күпчелеге ислам динендә, дип арттырып җибәргән, диләр. Бу фикердә, әлбәттә, хаклык бар, тик Ибн Рустә язмаларына игътибарсыз калып булмый. Болгарларга әле Ибн Фадлан килгәнче үк ислам диненең керә башлавы шул ук Ибн Фадланның үз язмаларыннан да күренә. Аларда тасвирланган тарихи вакыйгалар быелгы юбилейның нигез ташын тәшкил итәләр.

Әхмәт ибн Фадлан — атаклы гарәп сәяхәтчесе, үз заманының укымышлы кешесе. Болгар патшасы Алмасның үтенече буенча бөтендөнья мөселманнарының башлыгы булган Багдад хәлифәсе Җәгъфәр әл-Мөкътәдир болгарларга илчелек җибәрергә карар иткәч, илчелекнең секретаре итеп шул Ибн Фадлан билгеләнә, тора-бара ул аның мәгънәви җитәкчесенә үк әйләнеп китә. Илчелекнең төп вазифасы Багдад хәлифәсе исеменнән рәсми рәвештә Болгар җирендә ислам динен тарату була.

Илчелек Болгарга 922 елның май урталарында килеп җитә. Аның нәтиҗәләре һәм, гомумән, сәяхәт үзе Ибн Фадлан тарафыннан «Рисалә» дигән китапта тасвирлана. Аның төп нөсхәсе әлегә табылмаса да, төрле чорларда эшләнгән күчермәләре байтак. Бүгенге көндә иң тулы саналган һәм 1924 елда Иранның Мәшһәд шәһәрендә төрек-татар галиме Зәки Вәлиди тарафыннан табылган кульязма 1939 елда Германиядә Вәлидинең үзе һәм безнең илдә күренекле гарәп белгече һәм тарихчы А. Ковалевский тарафыннан дөньяга чыгарыла (1956 елда тулыландырылып кабат басыла).

Хәзерге ел исәбе (миләди) буенча 922 ел ул мөселман илләрендә элек кабул ителгән ел исәбе һиҗри белән 310 ел була (922 елның 1 маеннан 923 елның 20 апреленә кадәрге вакыт. Мәгълүм ки, мөселман ай елы христиан кояш елыннан 11 көнгә кыскарак). Быелгы 1989 ел исә шул ук һиҗри белән 1410 ел була (1989 елның 22 июле — 1990 елның 10 июле). Димәк, мөселман дөньясында кабул ителгән һиҗри белән 1410 елда Болгарда гарәп илчеләре ярдәмендә рәсми рәвештә дәүләт дине — ислам кабул ителүгә 1100 ел тула. Бу тарихи вакыйганың тагын да төгәлрәк вакыты — 1410 елның 16 мөхәррәме (гамәлдәге календарь белән 1989 елның 18 августы).

Болгарга ислам дине керә башлауның билгеләре белән Ибн Фадлан да очраша: Болгар патшасы һәм аның бәрән-

җәр атлы үзәк кабиләсе — мөселманнар, алар өчен агачтан мәчет салынган һәм мәзин манарадан намазга дәшеп азан әйтә; хотбә (җомга намазы) укыганда болгар патшасының исемен әйтеп дога кылалар; үлгәннәрне элеккечә мәҗүси йоласы белән дә, яңача — мөселманча да күмәләр. Әлегә аз гына таралган шушы ислам дине Урта Азиядән килеп кергән, бу хакта Алмас патшаның Ибн Фадлан белән булган әңгәмәсендә дә ачык әйтелә. Әмма болар әлегә исламның башлангычы, беренче билгеләре генә (Ибн Фадлан әйткәнчә, болгарлар юньләп дога да кыла белмиләр), халыкның аз санлы бәрәнҗәрләрдән кала күпчелеге әүвәлге мәҗүси динендә. Исламның әлегә ныклы нигезе юк, сыйнфый җәмгыять оешып бетмәгән. Менә шундый җәмгыять төзүне тәгәлләү, патшаның дәрәҗәсен күтәрү һәм властен үстерү, барлык болгар һәм кардәш кабиләләрне бер кул астына берләштерү өчен Алмаска оешып килүче илдә бер дин — яңа дәүләт динен рәсмиләштерергә кирәк була һәм шул максатта ул мөселман дөньясының башлыгы хәлифәгә мөрәҗәгать итә дә.

Гарәп илчеләре килүнең икенче көнендә үк болгар патшасына хәлифә исеменнән власть бирү тантанасы үткәрелә: Багдадтан шул тантаналар өчен махсус алып килгән ике байрак ачып җибәрәләр. Алмаска атаклы Габбасилар кия торган сәвад, ягъни кара төстәге кыйммәтле кием кидертәләр (Габбасилар — 750—1258 елларда, ягъни мөселман культурасының чәчәк аткан чорында идарә иткән гарәп хәлифәләре нәселе). Икенче көнне яңа хотбә укыла, анда Алмаска яңа исем — Габдулла ибн Җәгъфәр исеме кушыла (Җәгъфәр — хәлифә әл Моктәдирнең шәхси исеме) һәм «хак мөселманнар башлыгының хезмәтчесе» дигән дәрәҗә бирелә. Шуннан соң башка төрле тантаналар, мәҗлесләр үткәрелә, дини бәхәсләр дә булып ала. Ә бераздан соң болгар патшасы бөтен илдә рәсми рәвештә ислам динен кабул итү өчен барлык кабиләләрнең җыелышын җыя, бүгенгечә әйтсәк, съездын үткәрә. Атаклы совет тарихчысы академик Б. Греков һәм Болгар-Казан тарихының зур белгече археолог Н. Калинин бик дөрес билгеләп үткәнчә, 922 ел, ягъни һиҗри белән 310 ел, Болгарга ислам кертүнең мөһим датасы булып санала. Нәкъ шушы елдан башлап ислам рәсми дәүләт диненә һәм зур сәяси көчкә әйләнә.

VII йөздә, таркалган гарәп кабиләләрен берләштереп, бердәм дәүләт төзүдә ислам нинди зур роль уйнаган булса, шундый ук зур, берләштерүче рольне ислам болгар кабиләләрен бергә туплау, Идел буенда яңа дәүләт төзүдә дә уйный. Бу — бик тә әһәмиятле тарихи һәм политик

вакыйга. Шул вакыйгалардан соңгы вакыт — бөтен Болгар илендә исламның киң таралыш алу чоры. Рус елъязмаларында әйтелгәнчә, болгарлар 986 елда хәтта Киев Русена ислам дине тәкъдим итеп баралар. Ул вакытта Русьта әле христианлык кабул ителмәгән була. Бөек князь Владимир әлеге тәкъдимне кире кага: ислам диненең кайбер яклары, мәсәлән, хәмер эчәргә һәм дунгыз ите ашарга ярамау, малайларны сөннәткә утырту Русь өчен бармый, ди ул.

XI—XII йөз шәрык географлары һәм сәяхәтчеләре Бируни, Гардизи, әл-Бәкри, әл-Мәрвази, әл-Гарнати үзләренең әсәрләрендә Болгарны һәм болгарларны мөселман иле, мөселманнар дип язалар. Алтын Урда дәүләте төзелгәч, бигрәк тә аның белән Үзбәк хан идарә иткән чорда (1312—1342), Идел буенда һәм күрше өлкәләрдә ислам дине киң таралыш ала. Урданы исламлаштыруда элекке ислам һәм шәһәр культурасы үзәге булган Болгар әһәмиятле роль уйный. Казан ханлыгы чорында да исламның киң таралган булуы шик-шөбһә тудырмый: шул заманнан сакланып калган язма тарихи чыганаклар һәм матур әдәбият әсәрләре, шулай ук күп санлы кабер ташлары һәм алардагы язулар бу хакта ачык сөйли.

Һәммәбез яхшы хәтерли: узган ел бик тә тантаналы рәвештә Русьны чукындыруның 1000 еллыгы билгеләп үтелде. Бу юбилей, рус православие диненең рамкаларыннан чыгып, дөнья җәмәгатьчелегенең дә игътибарын җәлеп итте. Алай гына да түгел, Русьта христианлык кабул ителүнең 1000 еллыгы рус культурасы һәм борынгы язуының 1000 еллык бәйрәменә әйләнде. Шундый караштан чыгып Болгар дәүләтендә ислам кабул итүне дә фәнни яктан билгеләргә кирәк. Моннан 1100 ел элек туган җиребезгә шул чорның алдынгы гарәп культурасы (ә ул фәндә «Мөселман ренессансы» дип атала) үтеп керә, гарәп язуы барлыкка килә, ә шул язу нигезендә исә җирле болгар язуы, язма әдәбият туа. Ул әдәбиятның әле монголларга чаклы дәвергә караган җәүһәрләреннән «Кыйссаи Йосыф»ны белмәгән кеше юктыр. Ә соңгарак, Алтын Урда һәм Казан ханлыгы чорлары әдәбияты күп кенә атаклы шәхесләргә бай. Әйтик, Котб, Сәйф Сараи, Харәзми, Мәхмүт бине Гали, Баргузи, Мөхәммәдьяр һ. б. Бу язу, бу язма әдәбият мең елдан артык әүвәл болгар, аннан татар халкында укый-яза белүнең, гомумән, борынгы бай рухи культураның нигезе булды.

Зур юбилей алдыннан без шулар хакында уйларга, тарихыбызга яңача күз ташларга тиешбез. Элеккеге шикелле артык шөбһәләнергә, куркып калырга кирәкмәс. Мондый курку, куркытулар — Иван Грозный, Лука Конашевич, ка-

рагруһчылар, «бөек юлбашчы»лар заманыннан калган мирас ул. Православие дине — прогрессив, алдынгы, ә мөселманлык — реакцион, ул прогрессны артка өстери, кеше зиһенен агулый, дип дистәләрчә, йөзләрчә ел буе өйрәтеп киленгән «тәгълимат» нәтиҗәсе ул. Хәзер илебездә партия инициативасы белән революцион үзгәртеп кору бара. Бу яңарыш процессы күпләребезне уятты инде. 1985 елның апреле белән күтәрелгән җылы язгы җилләр «провинция», «периферия», «глубинка» дип йөртелгән безнең якларга да исте, ничәмә-ничә дистә еллар буе торгынлыкта «чәчәк атып», «бәхетле киләчәк» көтеп яшәгән без фәкыйрьләрнең дә җаннарын җылыта башлады.

Бу җылы җилдә соңгы вакытта салкын агымнар сизелгәләсә дә, яңа революцион күтәрелеш, демократик фикер йөртү тукталып калмас, дигән ышаныч бик зур. Һәм ул күтәрелешне, ул якты утны сүндермәүдә үзебезнең фидакарьлегебез, кыюлыгыбыз да кирәк. Политика, экономика, социаль сфера, экология мәсьәләләрендә генә түгел, ә тарихыбызны һәм культурабызны өйрәнүдә, шуны пропагандалауда зур тырышлык күрсәтеп, һәртөрле өркетүләрдән курыкмыйча, чын гражданлык горурлыгы белән алга барырга тиешбез. Ә инде кеше гомеренә бер тапкыр олугъ юбилей туры килгән икән, аны зур вакыйга итеп үткәрик!

«Татарстан яшьләре»,
1989 ел, 11 июль.

АЙСОЛТАННАР ИЛЕНДӘ

(Кереш сүз урынына)

Шагыйрь һәм галим Мостафа ага Ногманның якты истәлегенә багышлыйм

Елын төгәл хәтерләмим, 70 нче еллар башы иде булса кирәк. Әмма ае истә калган — августның соңгы көннәре узып бара иде. Мостафа абый белән метеорга утырып, Болгарга юл тоттык. Ул шул елларда борынгы Болгар белән Рус дәүләте арасындагы элемтә мөнәсәбәтләренә, 1229 елгы солых уңае белән булган ике арадагы алыш-биреш вакыйгаларына багышлап поэма язып йөри иде. Язма чыганакларны, фәнни хезмәтләрне җентекләп өйрәнгән, ә менә үзе әле Болгарда булмаган,

бергә барып, күрсәтеп, таныштырып кайтуны үтенде. Озакка сузмадык, берәр көннән, шулай итеп, юлга чыгып та киттек.

Ул Болгарның Мостафа абыйга ошаганлыгы! Хәрабәләр арасында йөргәндә мин аның күзләрендә яшьләр күрдем. Ифрат нечкә күңелле, тирән хисле шагыйрь иде мәрхүмҗан. Көне буе диярлек борынгы шәһәр мәйданында йөрдек, җиде чакрымга сузылган борынгы вал-өемнәрне үттек. Мин аңа сакланып калган таш пулатлар, манара һәм дөрбәләр, кабер ташлары хакында сөйлим, ул исе китеп, сабый балаларча йотылып тыңлый. Соңыннан ярты төнгә кадәр шул борынгы тарих турында сөйләшеп яттык, ә иртүк, әле кояш чыкканчы ук торып, Казанга кайту өчен пристаньга юнәлдек. Шагыйрь шагыйрь шул, яр буена басып, киң Иделгә, яңа чыгып килүче кояшка карап уйланып торды... Шунда туган хисләр шул елларда язылган «Болгар кызы Айсолтан» балладасында һәм «Шәһри Болгар» шигырендә чагылмый калмагандыр (соңыннан икесенә дә Рөстәм Яхин музыка язды). Мостафа абый поэмасын да язып бетерде булса кирәк. Әмма ул аны бастырып чыгарырга өлгермәде, вакытсыз дөнья куйды. Шул эшне ахырына җиткерергә дип йөргән Фәридә апа да (Мостафа абыйның хатыны) һич көтмәгәндә үлеп китте. Әсәр, кызганычка каршы, дөнья күрә алмый калды. Әмма Мостафа ага Ногман белән борынгы Болгарны үтүләр, аның «Айсолтан»нары минем өчен тирән бер хатирә, олы җанлы, нечкә хисле шагыйрьнең мәңгелек истәлеге булып калды. Болгарга тагын да бер барып чыксам яки аның турында яза башласам, иң әүвәл моннан 20 елга якын элек кылган шул сәяхәт искә төшә, Мостафа абыйның якты образы күз алдына килеп баса. Үземне аның алдында ниндидер бурычым бардыр сыман хис итәм, ул башлап язган Айсолтаннар тарихын, борынгы хатын-кызларыбызның үткәнендә тоткан рольләрен яктыртуны үземнең бер зур фәнни эшем дип саныйм. Болгар һәм Казан ханлыгы чорындагы мәшһүр хатын-кызларыбызның тарихын мин элегрәк «Социалистик Татарстан» (1988 ел, 22 май) һәм «Вечерняя Казань» (шул ук елның 8 декабре) газеталары битләрендә бераз яктырткан идем инде. Әмма шул хакта бүгенге татар матбугатының бөтен илебезгә тарала торган иң зур тиражлы «Азат хатын» журналында тулырак язып чыгуны үземнең әлеге шул изге бурычымны үтәү дип саныйм. Бу, һичшиксез, журналыбызның исеменә дә, җисеменә дә туры килер, дип уйлыйм.

Автор

Зәңгәр Идел буйларында җәйге таң,
Керләр чайкый болгар кызы Айсолтан...

Мостафа Ногман

Кешелек дөньясының килеп чыгышында һәм үсешендә хатын-кыз — гүзәл зат һәрвакыт аерым урын алып торган, чөнки кеше Ана карынында ярала, аның тарафыннан дөньяга тудырыла, имезелә, үстерелә, тәрбияләнә. Шуңа күрә, әлбәттә, хатын-кыз, аналар культы борынгы заманнардан бирле бик югары саналган. Палеолит дип аталган иң борынгы таш гасыр дәверенең беренче сәнгать әсәрләре — йөкле хатыннарның сөяктән һәм таштан юнып ясалган кечкенә сыннары. Йөз мең елларга сузылган матриархат, ягъни аналар хакимлеген ишетмәгән кеше юктыр, мөгаен. Ә легендар амазонкалар, ягъни Кече Азиядәге гаскәри хатын-кызлардан гына торган данлы бер кабиләләр союзы?! Ул хәрби гүзәлләр сугышта әсир ителгән ир-егетләр белән җенси мөнәсәбәткә кереп, алардан туган кызларны үзләрендә калдыра, ә малайларны әтиләре белән кире җибәрә торган булганнар.

Еллар дәвамында болгар шәһәрләрен, һәртөрле кирмән һәм ныгытма калдыкларын тикшереп йөргәндә, бигрәк тә аларның халык арасында «Кызлар каласы», «Кызлар уйный торган җир», «Кызлар тавы» исемнәре белән аталып йөргәннәрен очратсам, нигәдер, шул тарихи амазонкалар күз алдына килә. Болгар чорында да амазонкалар булгандыр, дип кистереп әйтәсем килми, тик Азов диңгезе буендагы Бөек Болгар дәүләте аша килгән ниндидер риваять-легендалар сакланмаган микән, дигән сораулар туа, әлбәттә. Һәрхәлдә әлегә сер булып калучы «Кызлар калалары» шул чорның тормышында, шәһәрләр тарихында хатын-кызларның актив роль уйнаулары хакында сөйлиләр.

Археология материаллары турында сөйләгәндә җир астыннан казып табылган алтын-көмеш ювелир әйберләрне дә искә алып үтми ярамас. Нәкъ менә ювелир сәнгатенең гүзәл үрнәкләреннән саналган искиткеч бай бизәкле төрле-төрле алкалар, беләзекләр, йөзекләр, муенсалар, чулпылар, каптырмалар, кул көзгеләре борынгы бабаларыбызның хатын-кыз җәмәгатенә зур ихтирамын бик ачык дәлилиләр.

Сакланып калган язма чыганакларда да болгар хатын-кызлары тарихының кайбер кызыклы сәхифәләре ачыла. Мәсәлән, атаклы Ибн Фадланның 922 елда (һиҗри белән 310 ел — мөселман календаре буенча санаганда моннан 1100 ел элек) язылган «Рисалә»сендә болгарларның хатын-кызга карата ачык мөнәсәбәте тасвирлана. Багдад илче-

ләрен Болгар патшасы Алмас үзенең яраннары (свитасы) белән бик тантаналы рәвештә каршы ала, тантана вакытында аның уң ягында хатыны утыра. «Аларның законнары һәм гадәтләре шундый»,— дип яза Ибн Фадлан. Каршылау тантанасында башка хатын-кызлар да катнаша. Гарәп илчеләре патша хатынына халифә бүләк иткән почетлы киемне кидергәч, башка хатын-кызлар, гадәт буенча, аның өстенә көмеш тәңкәләр — дирһәмнәр сибәләр.



Шәһәр Болгарда табылган алтын беләзек. Татарстанның берләштерелгән Дәүләт музеенда саклана

Гомумән, хатын-кызга шактый зур ирек куелган. Әле ислам дине кереп бетмәгән, әүвәлге мәҗүсилек кануннары шактый көчле хөкем сөргән ул заманда (X йөзнең башлары) хатын-кызлар хәтта ирләр белән бергә ялангач килеш су коеналар, тик шаярышу, зина кылышу юк. Зина кылу, караклык һәм кеше үтерү кебек үк, зур җинаять санала, аның өчен үлем җәзасы бирелә. Кызларны көчләп, теләгенә каршы кияүгә бирү гадәте дә булмаган, ахры. Моны Алмасның үз кызын Хәзәр каханына кияүгә бирергә теләмәү мисалында да күрергә була.

Болгарның рус елъязмалары буенча билгеле политик тарихында, исемнәре күрсәтелмәсә дә, кайбер хатын-кызларның роле чагылып китә. X—XI йөзләрдә Болгар дәүләте Киев Русе белән яхшы ук мөнәсәбәттә тора. Әмма XII йөздә, Иделнең югары агымында Төньяк-Көнчыгыш Русе дип аталган яңа бер дәүләт төзелгәч, бигрәк тә аның белән Андрей Боголюбский атлы кырыс һәм рәхимсез кенәз идарә итә башлагач, ике арадагы мөнәсәбәт шактый киеренке төс ала. Боголюбский Болгар җиренә берничә тапкыр һөҗүм оештыра, шәһәр-авылларны җимертә, халкын талый, кыра. Бу кенәз рус шәһәрләренә дә яу белән бара, 1169 елда Киевне ала. Аның атасы Юрий Долгорукий элегрәк Мәскәүне төзегәндә хөкем ителгән Кучка исемле боярның балалары баш күтәреп, 1174 елда Боголюбскийны үтерәләр. Шушы заговорда Андрейның хатыны да катнаша, ул болгар кызы була (кызганычка каршы исеме

аталмаган). Елъязмаларда әйтелгәнчә, ул үзенең явыз иренә «болгарларга күп зыян китергән өчен» үч саклаган була.

Мөстәкыйль Болгар дәүләтенең соңгы көннәрендә, ягъни XIII йөзнең 30 нчы елларында монгол яулары вакытындагы дәһшәтле вакыйгалар белән бәйле легендар Алтынчәч образы күпләргә мәгълүм. (Агыйдел буендагы авылларның берсендә язып алынган легендага таянып Муса Җәлил башта драматик поэма, аннан либретто яза; Нәҗип Җиһанов опера иҗат итә). Ул монголларга каршы үзенең дус кызы Каракүз белән сугышка китә. Алтынчәч — ирек сөюче, туган җиренең азатлыгы өчен көрәшкә чыккан һәм исеме сакланган беренче героик хатын-кыз образы.

Бераз гына соңрак чорга караган икенче бер ярым легендар образ — Габдулла ханның Аксак Тимер Болгарны алганда исән калган кызы, «Янмый торган кыз легендасы»ның героинясы. Явыз Җиһангир аны үзе белән Урта Азиягә алып китә, ул үлгәч кыз туган җиренә качып кайта, абыйлары Алтынбәк белән Галимбәкнең дә исән калып, Казан суы буенда яңа шәһәр төзегәннәрен ишетә һәм шунда барып, абыйларының гаскәр башлыгына кияүгә чыга. Кабере Иске Казаннан ерак түгел, Әйшә авылына каршы тау өстендә, «Гайшә бикә кабере» исеме белән мәгълүм («Тәварихе Болгария» исемле күпләргә билгеле язмада ул авыл «Гайшә бикә авылы» дип атала).

Бикә — би, бәк (кенәз) кызы, би хатыны дигән сүз, русча княжна, княгиня була инде. Бу исем XIV—XVI йөз кабер ташларында да очрый, мәсәлән, Айкыз бикә, Гәүһәр бикә, Ай бикәч, Гөлбаһар бикәч һ. б. (гомумән, болгар һәм татар кабер ташларының күп өлеше хатын-кызларга куелган). «Бикә» сүзе белән бәйле иң танылган исемнәрнең берсе, әлбәттә, Сөембикә.

Шулай итеп, без Сөембикәләр чорына — Казан ханлыгы дәверенә килеп керәбез. Бу дәвер вакыт ягыннан да безгә якынрак тора. Шуңа күрә әлеге чор язма чыганакларда да, беренче чиратта, рус елъязмаларында, күбрәк, киңрәк яктыртылган. Рус дәүләте белән ике арада барган политик элемтәләрнең бик тыгыз, бик актив чоры, ифрат та катлаулы, бик тә гыйбрәтле тарих. Көчле һәм каршылыклы, якты һәм тискәре шәхесләргә, зур политик эшлеклеләргә, шулай ук сатлык җаннарга да бай тарих. Көчле шәхесләр арасында хатын-кыз вәкилләре аерым бер урын алып торалар: Нурсолтан, Фатыйма, Гәүһәршад, Сөембикә...

Араларында иң көчлесе, Казан, гомумән, татар ханлыклары, аларның Рус дәүләте белән мөнәсәбәтендә зур роль уйнаганы — Нурсолтан. Атаклы рус тарихчысы Н. Карамзин аны «зирәк һәм дан яратучы хатын» дип

атый. Кайбер тарихи хезмәтләрдә Казан тарихының 1480 елдан 1520 елларга кадәр сузылган 40 еллык дәвере «Нурсолтан чоры» дип тә йөртелә. Кем соң ул Нурсолтан? Ул — күпләргә мәгълүм Идегәйнең оныгы булган Нугай Урдасы князе Тимернең кызы. Әтисе аны 1467 елда Казанның яшь ханы Ибраһимга (Казанның беренче ханы Мәхмүтәкнең кече улы) икенче хатынлыкка бирә. Ибраһим 1479 елда үлә. Нурсолтанның аннан өч баласы туа: Мөхәммәтәмин, Габделлатиф һәм кызлары Гәүһәршад. Мөхәммәтәмин — 1487—1496 һәм икенче тапкыр 1502—1518 елларда Казан ханы, шагыйрь; Габделлатиф шул аралыкта, ягъни 1497—1502 елларда хан була. Ибраһимнан соң Нурсолтан Кырым ханы Миңлегәрәйгә кияүгә чыга, аннан Сәхибгәрәй атлы улы туа, ул да соңгарак Казан ханы була (1512—1524 еллар).

Ундүртенче йөзнең сиксәненче еллар уртасында Казанда тәхет өчен ике зур партия арасында көрәш башлана. Ибраһимның беренче хатыны Фатыймадан Илһам атлы улы булып, әтисе үлгәч, ул тәхеткә утыра, 1487 елга кадәр идарә итә. Шул да мәгълүм булсын: Фатыйма Нугай Урдасыннан, аның кенәзе Йосыфның сеңлесе, ягъни Сөембикәнең түтәсе (Сөембикә — Йосыф кызы). Фатыйма җитәкчелегендәге партия Нугай кенәзлеге, аерым алганда, Урта Азия белән бәйләнеш яклы була, Көнчыгышка йөз тота. Нурсолтан исә Мәскәү белән союзны яклый. Нурсолтан белән Фатыйма, шулай итеп, икеләтә көндәш булалар: бер ир хатыны буларак та, капма-каршы ике зур политиканы алып баручылар буларак та. Башта Фатыйма партиясе җиңә, улы Илһам аның политикасын үткәрә, Русьның бөек князе Иван III 1487 елда Казанга һөҗүм ясый, шәһәрне ала. Илһам тәхеттән төшерелеп, үзенең әнисе һәм ике энесе белән (алар соныннан чукындырылалар) Белоозеро дигән шәһәргә озатылалар.

Илһам энеләренең язмышы да бик гыйбрәтле. Берсе Мәликтаһир, икенчесе Ходайгыл атлы. Соңгысы Петр исеме белән чукындырыла. Соңрак Иван III нең улы Василий III аңа үзенең сеңлесе Евдокияне кияүгә бирә. Аларның бер үк Анастасия исемле ике кызлары була, кияүләре — Рус дәүләтенең политик тарихында күренекле роль уйнаган шәхесләр: кенәз Федор Мстиславский, кенәз Василий Шуйский; Мәликтаһирны чукындырмасалар да, ике улын христиан итәләр, исемнәре шулай ук Федор һәм Василий, беренчесе соңыннан Бөек Новгород шәһәренең наместнигы итеп куела.

Иван III Казанны алгач, аның башка титуллары өстенә «Болгар патшасы» исеме дә кушыла. Казан алынса да,

ханлык бетерелми. Аның мөстәкыйльлеген саклап калуда Нурсолтанның роле зур була. Ул Иван III һәм аның хатыны Софья Палеолог белән бик яхшы, хәтта дусларча мөнәсәбәттә яши, алар бер-берсенә «туганым» дип эндәшәләр («брат мой», «сестрица моя»). Нурсолтан хәтта Иван III дән «бүтән бервакытта да Казанга, синең токымнарыңа зыян китермәм» дигән сүз дә ала. Кырым белән Мәскәү арасындагы киеренке мөнәсәбәтләрне йомшартуда да бу зирәк хатын әһәмиятле роль уйный.

Мөхәммәтәмин икенче тапкыр Казан тәхетенә утыргач, бигрәк тә 1505 елда Иван III үлгәннән соң, элекке политикасын кинәт үзгәртә, Мәскәү протекторатына чик куела. Төрле низаглар, ызгышлар булып ала, рус илчесен, сәүдәгәрләрен тотып кыйныйлар. Мәскәүнең 100 меңлек явы Казанга юнәлә, әмма Мөхәммәтәмин гаскәре тарафыннан тар-мар ителә. Нурсолтан, Василий III нең үтенече буенча, Кырымнан Казанга сәяхәт ясый, Мөхәммәтәминне Мәскәү белән килешергә үгетли, моны ул ике яктан да юкка кан коймау максатыннан эшли. Тик хан бу юлы әнисенең сүзен тыңламый.

1518 елда Мөхәммәтәмин кинәт үлеп китә (аны агулап үтергәннәр дигән риваять та бар). Василий III Казан тәхетенә Касыйм ханы Шәехәүлиярның олы улы Шаһгалине утырта, тик казанлылар аны өч елдан куып җибәрәләр. Казанга хан итеп Нурсолтанның кече улы Сәхибгәрәй куела, яңа партия — Кырым партиясе барлыкка килә, яңа политика башлана. Ул политика тәхеткә Сәхибгәрәйнең туганының улы Сафагәрәй утыргач һәм озакламый Нурсолтан үлгәч тагын да көчәя. Бу мөстәкыйль политика 1549 елга кадәр, Сафагәрәй үлгәнче дәвам итә.

Дөрес, Сафагәрәй тоташ идарә итми, ул ике тапкыр китәргә мәҗбүр була. Шул арада тәхеттә тагын Шаһгали, аның энесе Җангали утырып ала. Болары — Мәскәү тарафыннан куелган, Василий III нең һәм соңыннан аның улы Иван IV нең (Иван Грозный) җырын җырлаучылар. 1531—1536 елларда идарә иткән Җангали фетнә нәтиҗәсендә үтерелә. Заговорны Нурсолтанның кызы Гәүһәршад, аның ире Булат би җитәклиләр.

Җангалинең хатыны, Нугай кенәзе Йосыфның кызы Сөембикә, беренче иреннән соң Сафагәрәйгә кияүгә чыга, аннан Үтәмешгәрәй атлы улы туа. Сафагәрәй үлгәч, ике яшьлек Үтәмешне хан итеп куялар, аның исеменнән Сөембикә идарә итә. Акыллы һәм чибәр Сөембикәнең Казан даирәсендә абруе шактый зур була. Тик озакламый тагын тәхет өчен көрәш башлана. Иван Грозный гаскәр җибәреп,

Шаһгалине өченче тапкыр хан итеп куя, Сөембикәне улы белән Мәскәүгә алып китәләр. (Үтәмеш чукындырылып, аңа Александр исеме бирелә, 1566 елда үлә, Мәскәү Кремленең Архангель соборына күмелә. Шунда ук Иван Грозный һәм башка рус патшаларының да каберләре.)

Шаһгали Казан тарихында ифрат дәрәҗәдә тискәре роль уйнаган бер зат. Замандашлары аңа бик начар бәя бирәләр. Соңыннан К. Маркс та аның турында «күңел кайтаргыч, әшәке бер кеше булган, халык аны яратмаган, «рус ставленнигы» дип атаган»,— дип яза (Архив К. Маркса и Ф. Энгельса.— М., 1946.— 8 том.— 161 бит).

Шаһгали соңгы тапкыр Казаннан киткәндә дары мичкәләренә су салдырып китә, шулай итеп киләчәктә шәһәрне саклау эшенә зур зыян китерә. 1551 елның җәендә ул, Казанны алу өчен уңайлы булачак Свияжск крепостен төзүдә русларга зур булышлык күрсәтә, ә бер елдан соң инде Казанны алганда Иван Грозный армиясендә бер гаскәр башлыгы була. Соңыннан Грозный аңа Мәскәү әсире Сөембикәне хатынлыкка бирә.

Яраткан улыннан аерып, җаны сөймәгән бер әшәке адәмгә көчләп бирелгән Сөембикәнең соңгы көннәре билгеле түгел. Аның Шаһгали тарафыннан кыйнап үтерелгәнлеге хакында да сүз йөри. Һәрхәлдә, атасы Йосыфның Иван Грозныйга үпкәләп, ачуланып язган хатында шул хакта әйтелә. Кайда күмелгәнлеге дә ачык түгел — Касыйм шәһәрендәге Шаһгалинең гаилә мавзолеенда аңа куелган таш юк. Без моны 1960 елда архитектор һәм сәнгать белгече, зур галим Фуад Вәлиев белән кабат ачыклап кайттык.

Без кыскача гына тасвирлап үткән хатын-кыз дәүләт эшлеклеләренең күбесе чыгышлары белән Нугай Урдасыннан. Казан ханнары белән никахлашу нәтиҗәсендә алар Казан дәүләте белән аерылгысыз бәйләнешкә керәләр, аның тарихында мәңге уелмас эз калдыралар. Нугайлар белән бәйле кайбер культура элементлары, шул исәптән атаклы «Идегәй» эпосы да Казан татарлары арасына шул вакытта үтеп керә. Озакламый ул халкыбызның үз дастанына, үз байлыгына әверелә, тагын да баетыла.

Казан яулап алынып, ханлык бетерелгәч, әлбәттә, татар халкының элекке дәүләтчелегенә чик куела, хөкүмәт, администрация, суд, армия, гомумән, дәүләт механизмы юк ителә. Элекке ханнар, аларның якыннары Мәскәүгә озатылып, чукындырылалар, озакламый шунда үләләр (Үтәмеш — Александр, Ядегәр — Симеон), кайсылары Казанны саклаганда һәлак була, ә нindидер могҗиза белән

исән калып, качып китә алганнарының язмышы билгеле түгел.

Әлбәттә, фаҗига никадәр тирән, никадәр авыр булса да, тормыш тукталып калмый, яңа шартларда, яна дәүләт — Рус дәүләте составында дәвам итә. Үлгәннәр урынына яңалар туа, гасырлар белән бергә кешеләр дә алмашына. Әмма халык, аның борынгыдан килгән бай культурасы юкка чыкмый, нинди генә югалтулар, нинди генә авырлыклар кичерсә дә, нигезе нык булганлыктан, тагын да үсә, ныгый, баеый. Һәртөрле милли-социаль изүләрне, көчләп чукындыруларны, төрле кимсетүләрне үз җилкәсендә күтәргән татар халкы, татар хатын-кызы үзенең кешелек йөзен, горурлыгын, чисталыгын, әдәплелеген, намуслылыгын, инсафлыгын, түземлеген һәм тагын башка бик күп сыйфатларын саклап калган, аларны яңа буыннарга тапшырган. Ә ул гүзәл затка багышлап халкыбыз күпме җырлар җырлый, күпме көйләр көйли. «Кәләү Гайшә», «Гөлҗамал», «Зөбәрҗәт», «Тәзкирә», «Асылъяр», «Хәмдия», «Галиябану», соңра «Зөләйха», «Нурия», «Рәйхан»...

Мин аларны тынлап туя алмыйм, тыңлаган саен халкыбызның, хатын-кызларыбызның бай да, гыйбрәтле дә үткәне, моң-зарлары һәм бәхетле көннәре, чиккән михнәтләре һәм киләчәккә якты өметләре күз алдыннан үтә.

Тарихчы буларак, татар хатын-кызлары минем өчен халкыбызның данлы тарихында мәңге онытылмаслык, сагынып сөйләрлек якты эз калдырган героик тарихи шәхесләр: Алтынчәчләр, Нурсолтаннар, Сөембикәләр... Гасырлар буена халкыбызның күркәм сыйфатларын югалтмыйча, аны күз карасыдай саклап, үстереп килгән, азатлык өчен изге көрәшләрдә корбаннар биргән, чит җирләргә, чит илләргә китеп, туган илен сагынып яшәргә мәҗбүр булган асыл затлар, исемнәре билгеле дә, билгесез дә горур, кыю ханым вә туташлар, атаклы шагыйрәләр, мәгърифәтчеләр, мөгаллимәләр, беренче артисткалар, тугрылыклы сөйгән ярлар... Авыр сугыш елларында сөекле ирләрен, газиз балаларын мәңгегә югалткан, әле бүген дә шуларны өзелеп сагынып, төннәрен йокысыз үткәрүче ак әбиләр, әниләр... Халкыбызның бөтен матурлыгын, югары әхлакый сыйфатларын үзендә саклаган, дөнья җимертеп эшләп йөрүче апалар, хатыннар, сеңелләр, яшь киленнәр, чибәр кызлар — татар кызлары...

Бүгенге шомлы да, данлы да, хәтәр дә, өметле дә заманыбызның хатын-кызлары турында уйланганда, минем күз алдыма янә шигъри Айсолтаннар килеп баса:

Айсолтаннар нәселе ләкин һаман да
Яшәп килә гүзәл туган ил белән.
Бөек туган ил белән.

«Азат хатын»,
1989, 10 сан.

ТАШЛАР ҺӘМ ТАРИХИ МИРАС

Күрәмсең бу кабер ташын:
Башын игән, рәкүгъ иткән.

Дәрдмәнд

1917 елның ноябрендә, ягъни Октябрь революциясеннән соң ук кабул ителгән «Эшче һәм солдат депутатлары Советының өндәмәсе»ндә мондый сүзләр бар: «Гражданнар, бер ташка да кагылмагыз, истәлекләрне, биналарны, борынгы әйберләрне,документларны саклагыз — болар барысы да сезнең тарихыгыз, сезнең горурлыгыгыз, исегездә тотыгыз, шушы нигездә киләчәктә безнең яңа халык сәнгате үсеп чыгачак». Чынында исә әлеге өндәмә «якты киләчәк» көтеп яшәүче эшче-крестьян халкының җан әрнүе булып кына калды.

Гасырыбызның 20—30 нчы елларындагы вәхшилек-вандализмны шул чор кешеләре үз күзләре белән күргәннәр, яшьрәкләр исә бу хакта документаль фильмнар, архив кәгазьләре, күргәннәрнең сөйләүләре буенча беләләр.

20 нче һәм аннан соңгы елларда җимерделәр. Шуннан нәрсә калды? Хәрабәләр һәм буш диварлар, борынгы мәһабәт биналарның бүген чүп үләне басып киткән яки сукалап ташланган нигезләре калды, «иске» китап-кульязмаларны өеп яндырган учак урыннары калды.

Моннан 20 еллар элек бер төркем галимнәр Казанның татар зиратына бер көнлек экспедиция оештырганнар иде. Без археологлар, шактый гына беленеп торган бер чокырны казып, шуның төбендә инде череп бетә язган басма һәм кульязма китап калдыклары таптык. Аларны шул чокырга 30 нчы елларда биш олауга төяп алып килеп күмгән булганнар.

Соңгы вакытта мәгълүм булган кайбер архив материаллары бик тә гыйбрәтле. 20—30 еллардагы Үзәк Россия һәм Себер мөселманнары Диния нәзарәтенең башлыгы, атаклы татар галиме мөфти Риза Фәхретдинов Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитетына берничә тапкыр язмача һәм телдән мөрәҗәгать итеп, мөселман дини оешмаларының бик аянычлы хәлдә булуларын, мәчетләрнең күпләп ябы-



XVII йөз татар кабер ташы. Казан арты. Г. Рәхим фотосы. 1920 еллар

луларын бәян итә. Шул ышанычлы мәгълүматларга нигезләнеп, Башкарма Комитетның Президиум әгъзасы П. Г. Смидович Комитет рәисе М. И. Калининга 1930 елның 8 маенда хат яза, анда мондый сүзләр бар: «...мөселман дини оешмаларының бөтенесе (монда Үзәк Россия һәм Себер мөселманнары, ягъни нигездә татарлар күз алдында тотыла.— Р. Ф.) тәмам бетү, җир йөзеннән юкка чыгу алдында торалар... 12 мең мәчетнең 10 меңнән артыгы ябылган».

1985 елның языннан илебез, җәмгыятебез яңа сулыш ала башлады, халыкларда милли үзаң үсеше күтәрелеп китте, ә бу хәл союздаш һәм автономияле республикаларның төп милләтләрендә генә түгел, ә рус халкының үзендә дә нык сизелә башлады. Моңа борынгы рус дәүләтендә христианлык кабул ителүнең 1000 еллык юбилеен билгеләп үтү дә шактый этәргеч булды, шул уңай белән чиркәү-соборларны ремонтлау һәм ачу эше көчәеп китте. Ләкин әле Рәсәйнең үзендә дә тарих-архитектура истәлекләренең шактые игътибардан читтә кала бирә. Мондый игътибарсызлык, шөбһәсез, безнең татар истәлекләренә карата аеруча көчле, бигрәк тә республикабыздан читләрдә яшәүче милләттәшләребезнең тарихи мирасы аяныч хәлдә. Хәер, Татарстанның үзендәге күп кенә кыйммәтле тарих һәм культура ядкарьләре дә җимерелү хәлендә кала бирәләр...

Менә бу рәсемдәге кабер ташы XVII йөзгә, ягъни Казан ханлыгы алынганнан соңгы чорга карый. Ул — халкыбызның таш кисү, каллиграфия, сырлап бизәү сәнгатенең, гомумән, аның тарихы, теле һәм мәдәниятенең ис-



Шәһре Болгар урынында XVIII йөз башында төзелгән урыс чиркәвенең нигезенә салынган XIV гасыр болгар кабер ташлары. З. Бәширов фотосы, 1982

киткеч бай истәлеге. Аның киль сыман, башын очлатып эшләнгән формасы борынгы чорлар гамәли сәнгатенең бик матур чагылышы, телендә исә нинди бай шигърият! Бу таш 20 нче елларда халкыбызның күренекле әдәбият белгече һәм эпиграфисты Гали Рәхим тарафыннан фотога төшерелеп, башка шундый ук ташлар рәтендә нәшер дә ителә, тик соңыннан юкка чыга. Заманында болгар һәм татар кабер ташларын чиркәү нигезләренә салдылар, башка халыклар аларны йорт кирәк-ярагына, ишек алдын түшәргә тотты, ваклап мунча ташына салды. Әмма безнең халык аларны гасырлар буена кадерләп саклады, авыл зиратыннан читтә — басуда һәм су буендагыларының чардуган-коймаларын яңартып торды. Ләкин аларга караш безнең «бөек» чорыбызның казарма социализмын төзегәндә, коммунизм идеяләре белән рухланып, «искелеккә», дин-

гә каршы аяусыз көрәш алып барганда шактый үзгәрде. Бер авыл агае миңа бик дөрес аңлатып биргәнчә, мондый ташларга һәм башка борынгы истәлекләргә «слабуда чыгып, калхузлар оеша башлагач», нык зыян килде. Картлар үлә барып, дөнья иманын югалта барган яшьләр кулына кала башлагач, мондый кадерле ядкарьләрнең саны күзгә күренеп кимеде. Бер-ике генә мисал.

Әле 50 нче еллар башында гына Тәтеш районы, Олы Әтрәч янындагы борынгы болгар зиратында XIV гасырга караган һәм яхшы сакланган 25 кабер ташы була. Бүгенгесе көнгә шуларның унлабы юкка чыккан. Мамадыш районы, Кирмән авылыннан ерак түгел урнашкан шундый ук борынгы зиратта шул ук елларда 20 гә якын таш булган — узган ел мин анда нибары сигез таш санадым. Зиратның коймалары җимерелгән, шул кечкенә генә мәйданда көтү йөри, әйтерсең, колхоз көтүенә башка җир беткән. 60 нчы еллар башында Иске Казан зиратында XV—XVIII йөз кабер ташларын бульдозерлар белән ваттырган вандализмны күпләр ишетеп беләләрдер. Шунысы гыйбрәтле: кабер ташларын вату мәчет манараларын кисү кебек үк юньсез эш санала безнең халыкта, шул вәхшилекне эшләгән адәмнәр халык рәнҗешенә дучар булалар. Татарстан буйлап җәйге экспедицияләр ясап йөргәндә, мин кадерсезләнеп яткан ташлы зиратларны яки аерым кабер ташларын койма белән әйләндереп алуның кирәклеге хакында күп кенә авыл Советы һәм колхоз җитәкчеләренә мөрәҗәгать итеп карадым. Кайберләре: «Ярый, эшлибез аны»,— дигән була, тик барыбер эшләми; кайберләре: «Шул иске-москыны кайгыртып йөрмәсәң, башка эшең беттемени?» — дип кенә җибәрә. «Башка эш», аларча,— ит заданиесен арттырып үтәү (әйтерсең, кибетләр ит белән тулган), үтәлмәсә, партҗыелышлар җыеп, халыкны сүгү, аңа коммунистик мораль уку. Монысы инде партоешма секретарьлары вә башка интеллигенция эше. Менә бу — эш ичмасам! Ә синең ул иске ташларың ник кадалып китми шунда. Коймасыз һәм чардугансыз калган ул кадерле ядкарьләр өстендә сыер йөри, пычрата, тояклар астында кадерле язулар юкка чыгалар, житмәсә, шул җирне сука белән актарып китәргә дә күп сорамыйлар — суканы бит аны колхоз рәисе тартмый, ә трактор тарта. Мондый эш бер генә цивилизацияле илдә дә эшләнми, ә бары тик безнең «алдынгы» илебездә генә. Оят вә хурлык!

Дөрес, республикабызның тарих һәм культура мирасын саклау эшендә соңгы вакытта кайбер уңай адымнар да эшләнә башлады. СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият, тарих

институтында, СССР истәлекләренең бер өлеше буларак, ТАССР тарихи-культура истәлекләренең җыелмасы төзелә башлады, ул Мәскәүнең «Наука» нәшриятында басылып чыгарга тиеш. Күптән түгел республикабыз хөкүмәте борынгы Болгардан Кама буендагы Җүкәтау шәһәре калдыкларына кадәр «Көмеш дага» исемле туристик маршрут төзү турында карар кабул итте (хәлбуки, бу маршруттагы кайбер шәһәр калдыкларының фәнни интерпретациясе дәреслеккә туры килеп бетмәсә дә). Ниһаять, ТАССР Министрлар Советы каршында «Мирас» исемле региональ үзәк оешты; ул берничә комиссиядән тора, шулар арасында «Тарих һәм культура истәлекләрен саклау һәм алардан файдалану комиссиясе» дә бар.

Бер мәкаләдә Татарстанның һәм, гомумән, татар халкының тарихи мәдәни мирасын саклауның бөтен проблемаларын ачыклау, әлбәттә, мөмкин түгел. Без монда кайбер, иң төп мәсьәләләргә генә тукталып үтәрбез. Республикабызның тарихи мирасын саклауның иң актуаль проблемаларыннан борынгы мәдәни үзәкләребез булган шәһәрләрнең, беренче чиратта мәркәзебез Казан шәһәренең тарихи үзәген саклау мәсьәләсен атарга кирәк. Күпләрне — казанлыларны да, килгән кунакларны да — үзенең архитектура ансамбльләре һәм аерым мәһабәт бинаалары белән сокландыручы борынгы Казан — ул безнең горурлыгыбыз, гражданлык намусыбыз һәм вөҗданыбыз. Даһи Тукай әйтмешли, «мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары».

Мәһабәт Кремль, аның аерым архитектура ансамбльләре, беренче чиратта, әлбәттә, җырларда җырланган, риваять вә легендаларга кергән, халкыбызның тарихи канына сеңгән атаклы Сөембикә манарасы. Сүз уңаенда шуны да әйтеп үтик, комиссиябезнең якындагы утырышы аңа багышланачак: нәрсә ул — мәчет манарасымы, әллә дөрбәмавзолеймы; кайчан салынган — XVIII йөздәме, әллә XVI дамы; башында нәрсә булырга тиеш — аждаһа-еланмы, йә булмаса-аймы? Бу принципиаль мәсьәләләр җентекләп тикшерелергә, һәм комиссия кабул иткән карар шуннан соң үзенең юридик көчен алырга тиеш була.

Кремльдән тыш, Казан әле башка атаклы истәлекләре, XVI—XX йөз башының гүзәл архитектура объектлары белән дә данлыклы. Бүгенге көндә шундый 72 истәлек ремонт-реставрация эшләрен көтеп ята. Болар: атаклы фән һәм культура эшлеклеләре, революциянерлар, эшлекле даирәләренең (Фукс, Мәрҗани, Баруди, Әмирхан, Ямашев, Вахитов, Михляев, Свешников, Крестовников, Апанаев, Лебедев, Иванов һ. б.) исемнәре белән бәйле булган йорт-

лар, элекке мәктәпләр, нәшрият-типография бинаалары, мәчетләр вә мәдрәсәләр, чиркәүләр һәм монастырьлар. Күп биналарга мемориаль такталар куясы, начарларын адәм рәтлегә алыштырасы бар.

Мәчет вә мәдрәсә биналарын реставрацияләү һәм саклау эше турыдан-туры Казанның милли үзәгендә «Иске татар бистәсе» исемендә зур музей-саклагыч (заповедник) төзү белән бәйле. Мондый музей төзү турындагы игелекле фикер ТАССР Мәдәният министрлыгыннан чыкты, ахры. Музей-заповедник төзү ул — Казан һәм Болак артындагы элекке татар милли үзәген торгызу, андагы атаклы мәчет һәм мәдрәсәләрне, борынгы йортларны, урам-мәйданнарны үз хәленә кайтару һәм киләчәк өчен саклау дигән сүз. Бу — безнең халыкның, аның культура һәм фән эшлеклеләренең, республикабыз һәм шәһәрләребезнең рәсми оешмаларының якындагы, кичектермәс бурычы. Әлеге эшкә проектчылар һәм архитектор-реставраторлар мәсьәләнең бөтен мөһимлеген, аның барлык нечкәлекләрен, милли үзенчәлекләрен аңлап тотынырга тиешләр. Ул үзенчәлекләр, ул нечкәлекләр, ул мөһим детальләр рәтенә, мәсәлән, татарның иҗтимагый, сәяси һәм рухи тормышында зур роль уйнаган атаклы «Печән базары», мәшһүр «Болгар номерлары» да керә. Әйе, дөньяга, Казан артының Кушлавыч-Кырлайлары, Уральскиның «Мотыйгия» мәдрәсәләре белән беррәттән, бөек Тукайны биргән, һәр иманлы татар күңеленә газиз булган, мәрхәмәтле Болгар номерлары... Бу музей-саклагычны төзегәндә алдан әзерлек эшләре үткәрү, шул заманны үз күзләре белән күргән, әлегә исән булган шәхесләр белән җентекләп сөйләшү, бер генә детальне, үзенчәлекне дә ычкындырмыйча, кирәкле мәгълүматлар, әүвәлге рәсем һәм фотолар туплау бик тә зарур.

Казаннан читтә, ерак район-авылларда урнашкан тарих һәм культура истәлекләренең хәле тагын да кыенрак, аларны саклау, ремонтлау проблемалары бик тә кискен мәсьәләгә әйләнде. Хәзерге көндә республикабыз территориясендә реставраторларны көтеп ятучы 145 мөһим истәлек санала. Хәтта архитектурабызның кайбер уникаль истәлекләре дә бөтенләй җимерелү яки сүтелү алдында торалар. Арча районының Олы Мәңгәр һәм Олы Әтнә авылларында сакланып калган өчәр катлы ике агач йорт шундыйлардан. Заманында андый гүзәл корылмалар белән мәшһүр Казан арты дан тоткан, бүгенге көнгә исә ике бөртек йорт утырып калган, ә аларда халкыбызның борын-борыннан килә торган архитектура сәнгатенең матур традицияләре бик яхшы чагылыш тапкан. Олы Мәңгәрдәгесен, тәмам җимерелеп беткәнче Иске Казан җирлегенә күчереп,

татар халкының ачык һавада милли архитектура-тарих музей-заповедынгының үзәге итү мәсьәләсе республика матбугатында шактый күтәрелде инде, аерым бер даирәләрнең, шул як район халкының иҗтимагый фикеренә дә әйләнде. Әмма андый музей төзү мәсьәләсе заманыбызның каһәр төшкән бюрократик системасының калын вә биек диварына барып төртелде дә, тукталып калды. Массакүләм информация чараларының, исемнәре илгә танылган язучы һәм галимнәрнең катнашуы да бу мәсьәләне хәл итүгә бернинди ярдәм итә алмады. Музейлар төзүне үз өстенә ала торган оешманың ике кешесеннән бәйле булып калды бу эш. Алар өчен яңа музей төзү, дөресрәге, шул мәсьәләне яклау, тагын да югарырак оешмалар алдына кую, акча, «штатлар» сорау — яңа борчу-мәшәкать, «кычытмаган җиреңне кашу» ул.

Авылларда урнашкан, кайчандыр мәдәният учаклары булган һәм татар дөньясына исемнәре белән таралган аерым мәдрәсәләрнең таш биналары, әйтик, Арча районының атаклы Кышкар мәдрәсәсе, Кукмара районы Мәчкәрә авылындагы мәчет-мәдрәсәләр ярым җимерек хәлдә. 30 нчы елларның гына түгел, ә бүгенге ваемсызлык-җинаятьнең дә ачык чагылышы булып моңаеп торалар. Кабер ташларының нинди хәлдә ятулары хакында югарыда әйтеп киттек инде. Эш бер татар истәлекләрендә генә түгел. XVII—XIX йөзләрдә салынган, архитектура кыйммәте булган урыс чиркәүләренең дә хәле бик мөшкел.

Авыллардагы тарих һәм культура истәлекләрен саклау, аларга ремонт эшләрен тизләтүне нәрсәдән башларга соң? Безнең уебызча, «Татжилгражданстрой» тресты каршында республика (ТАССР) һәм җирле әһәмияткә ия булган истәлекләрне реставрацияләү белән шөгыльләнүче бүлекләр төзергә, ә шуларга архитекторларны договор нигезендә эшкә чакырырга кирәктер. Әлеге трестның һәр районда яхшы ук производство базасы булган бүлекләре эшләп килә, алардан дөрес файдалана белү шарт.

Без республикабызның тарих һәм мәдәният истәлекләрен саклауның, аны яхшыртуның төп мәсьәләләрен ачыкларга тырыштык. Безнең комиссия карамагында да, Мәдәният министрлыгында да, Тарих һәм культура истәлекләрен саклау җәмгыятебезнең Татарстан бүлегендә дә республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребезнең андый истәлекләре хакында тулы мәгълүматлар юк. Андый мәгълүматлар СССР истәлекләре җыелмасы төзелеп бетеп, басылып чыкканнан соң гына билгеле булачак, әлбәттә. Безнең комиссиянең, гомумән, фән һәм культура эшлеклеләренең, аерым һәвәскәр-энтузиастларның төп бурычла-



Пермь шәһәренең мәчете. 1917 елга кадәр төшерелгән фото. Мәчет бүгенге көнгәчә сакланмаган

рыннан берсе булып барлык республика, край һәм өлкәләргә милли мирас байлыгын җыйнау һәм пропагандалауга мөмкин булганча ярдәм итү тора. Төрле фәнни экспедицияләр, әйтик, археологик, этнографик, археогра-

фик, лингвистик һ. б. экспедиция отрядлары үзләренең җәйге экспедиция эшләрендә СССРдагы татар халкы вәкилләре яшәгән төбәкләрдә тупланган мәгълүматларга игътибарны икеләтә арттырырга тиешләр.

Бөтен Союзга таралган татар халкының тарихи мирасын барлау, саклау һәм пропагандалау эшендә СССРның Европа һәм Себер мәселманнары, ягъни нигездә татар мәчетләренең фотоальбомын әзерләп, бастырып чыгару — кичектергесез, зарури эш. Андый мәчетләрнең революциягә кадәр нәшер ителгән, аклы-каралы фотолардан торган альбомы инде күптән сирәк очрый торган басмага әйләнде. Аны хәзер, көндез шәм яндырып эзләсәң дә таба алмыйсың. Сүз фото-техниканың һәм полиграфиянең бүгенге көн таләпләренә җавап бирә алырлык, төсле фотолар белән бизәлгән художестволы альбом турында бара.

Нәшрият эшләре хакында сүз кузгаткач, тагын бер әһәмиятле мәсьәләне күтәрмичә мөмкин түгел. СССР мәдәният фонды тарафыннан нәшер ителеп, бөтен Союзга һәм чит илләргә таратыла торган «Наше наследие» исемле иҗтимагый-сәяси һәм фәнни-популяр журнал үрнәгендә безгә дә «Мирас» атлы шундый ук журнал чыгарырга кирәк.

Соңгы елларда халкыбызның Шиһап Мәрҗани һәм Газиз Гобәйдуллин кебек зур тарихчыларының әсәрләре басылып чыкты. Башка милләт вәкиле булган, әмма татар тарихын дөрес тасвирлауда заманында батырлык күрсәткән һәм шуның өчен репрессиягә эләккән М. Худяковның Казан ханлыгы чорын күтәргән очерклары нәшер ителә башлады. Республика газеталарында тагын бер тарихчы — Һади Атласиның исеме күренеп, аны реабилитацияләү мәсьәләләре чагылып китте. Әле безнең халкыбызның тагын ике зур тарихчысы бар. Алар: болгар, татар һәм, гомумән, төрки халыклар тарихы буенча җитди хезмәтләр калдырган, Казан ханлыгы чорына, Сөембикә манарасына да аерым багышлап китап вә мәкаләләр язган Зәки (Әхмәтзәки) Вәлиди һәм Габдулла (дөресрәге, Габделбари) Баттал. Тарихи мирас комиссиясе буларак, безнең комиссия бу зур тарихчыларны реабилитацияләү, аларның кыйммәтле әсәрләрен халыкка кире кайтару эшен принципиаль рәвештә күтәрергә тиеш. Бу өлкәдә без җәмәгатьчелекнең зур ярдәменә мохтаҗ. Алар турындагы теге яки бу кыйммәтле мәгълүматларны безнең комиссия исеменә җибәрүегезне үтенер идек (адрес: Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 2/31, СССР Фәннәр академиясе Казан фәнни үзәгенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты).

Халыкның үткәненә, аның чишмә башына һәм тирән тамырларына, гомерләрен уздырып баручы истәлек-хәрабәләренә мәхәббәт һәм илтифат булдыру, ташлар моңына колак салу — һәр игелекле затның гражданлык намусы, аның акыл һәм вөждан эше ул. Язмабызны ташлардан башлаган идек. Коръәннең икенче сүрәсендә ташлар арасыннан бәреп чыккан чишмәләр хакында әйтелә. Бу чишмәләр, шөбһәсез, кешеләргә хас зирәклек, киң күңеллелек, миһербанлылык чишмәләре булсын иде, ул чишмәләр кешеләргә безнең чал тарихыбызга һәм күп гасырлык мәдәниятебезгә, аның картайган һәм хасталанган истәлекләренә шәфкатьлелек хисләре арттырсыннар иде.

Кайбер ортодоксаль марксистлар һәм сугышчан атеистлар миңа: «Син нәрсә, коммунист башың белән Коръән сүзеннән башка рәтле сүз таба алмадыңмыни?!» — диярләр. Сүзнең рәтлесе-рәтсезе турында фикер йөртү шактый четерекле мәсьәлә ул, әмма теләгәндә Ленинга мөрәҗәгать итәргә була: «Кешелек дөньясы эшләп чыгарган барлык белем байлыклары белән үзеңнең зиһенеңне баетканда гына коммунист булырга мөмкин».

«Социалистик Татарстан»,
1990, 13 май

СӨЕМБИКӘ МАНАРАСЫ

Казан шәһәре, аның мәдәни һәм архитектура тарихының иң кызыклы, әмма катлаулы мәсьәләләреннән берсе рәвешендә Сөембикә манарасы, аның кайчан, кемнәр тарафыннан һәм нәрсә өчен төзелгән булуы турындагы мәсьәлә тора. Моның буенча тарих фәнендә ике төрле караш яши. Берәүләр манараны татар чоры истәлеге итеп саныйлар, икенчеләре аның соңрак, Иван Грозный Казанны алгач, руслар тарафыннан салынганлыгын дәгъвалыйлар. Сөембикә манарасын руслар салган, дигән фикер тарафдарлары түбәндәгеләр: Ф. Эрдман, В. Суслов, И. Грабарь — болар XIX йөз авторлары, безнең гасырда исә: П. Дульский, Н. Калинин, ә иң соңгы вакыт вәкилләреннән С. Айдаров, А. Халиков. Манараның татар архитектурасы истәлеге булуы турындагы фикерне революциягә кадәр Н. Баженов, К. Невоструев, С. Шпилевский, М. Пинегин, Н. Загоскин, П. Заринский, П. Невзоров кебек Мәскәү һәм Казанның рус галимнәре яклады, ә татар тарихчы галимнәреннән шушы ук фикердә торучылар: Ш. Мәрҗа-

ни, К. Насыйри, Г. Әхмәров, Һ. Атласи, З. Вәлиди, Г. Баттал булдылар. Совет чорында бу карашны В. Егерев, Г. Шамуков, Ф. Вәлиев, Ә. Мөхәммәдиев, Ф. Салихова куәтләп һәм яңа материаллар белән баетып чыктылар. Без фәкыйрегезне дә шушы фикердә дип белерсез.

Сөембикә манарасын русларныкы дип әйтүчеләр аның төзелү чорын төрлечә күрсәтәләр: 1552 елда Казан яулап алынгач та; Петр I нең әтисе Алексей Михайлович яки аның да әтисе Михаил Федорович дигән патшалар вакытында, ягъни XVII йөздә; Петр I нең үз чорында (XVII йөзнең ахыры — XVIII йөзнең беренче чиреге) һәм, ниһаять, Анна Иоанновна дигән хатын-кыз патша заманында — бу XVIII йөзнең 30 нчы еллары була инде. Төрле чорда идарә иткән төрле рус патшаларының исемнәрен атап чыгу үзе генә дә бу фикернең эзлексезлеге хакында сөйли, ничек кенә булса да манараның русныкы икәнен исбат итәргә тырышуларын күрсәтеп тора — кайсы патша чорында төзелгән булса да ярый, барыбер. Шунысы бик тә гыйбрәтле, әлеге идея тарафдарлары үз фикерләрен яклап бер генә ышанычлы дәлил, тарихи чыганак та китерә алмадылар. Шуңа күрә аларның фараз кылулары үз заманында Казан тарихының күренекле белгечләре тарафыннан шактый җиңел кире кагылды.

Сүзебезне шәрехләбрәк үтик. Сөембикә манарасы рус чорында салынган, дип уйлаучылар күбрәк Алексей Михайлович һәм Анна Иоанновна заманын атадылар. Анна патша вакытында төзелгән, дип исбатларга тырышучылар, шул чорда манара өстенә сәмруг кош сурәте, ягъни Россия империясенең гербы куелган, шулай булгач манара да шул заманда төзелгән булырга тиеш, диделәр. Бу «булырга тиеш»нең дәлилсезлеген күрсәтеп үтүчеләр шуңа бик дөрес итеп басым ясадылар: монда сүз манара төзелү турында түгел, ә нәкъ менә аңа хәтле ук булган манараның башына сәмруг кош сурәтен кую турында гына бара. Сөембикә манарасы Алексей патша яки аның әтисе заманнарында төзелгән, дияргә яратучылар мондыйрак дәлил китереп карадылар: манара янында урнашкан, элекке Нурали мәчете, соңыннан реставрацияләнеп «Дворцовая церковь» дип аталган чиркәү бинасын яңартканда (анда хәзер ашханә урнашкан) җир астында әлеге патшалар исеменнән сугылган берничә акча табылган. Мәчет бинасын чиркәүгә әйләндерү 1854 елда була, ә шул вакытта табылган акчалар хакында бары тик 7 елдан соң гына, ягъни 1861 елда, бик үк анык түгел хәбәр басыла. Анда ул акчаларның теге яки бу катламга караганлыгы хакында тәгаен әйтелмәгән, җитмәсә, XVII йөз рус акчаларының

XVI йөз татар мәчетенең нигезенә эләгүе һич кенә дә мөмкин түгел эш.

Сөембикә манарасының русныкы икәнен дәгъвалаучылар соңрак мондыйрак та фикер әйтеп чыктылар: янәсе, манара үзенең төзелеше белән рус архитектурасына якын. Әлеге фикерне В. Суслов дигән сәнгать тарихчысы күтәреп чыкты, ә аны куәтләп, художник һәм сәнгать белгече И. Грабарь: Казан манарасы Мәскәү Кремленең XVII йөздә корылган «Боровицкая» башнясына бик охшаган, шулай булгач, ул аннан соң төзелгән, дип язып чыкты. Сүз унаеннан әйтеп үтик: бу фикерне замандашларыбыздан кайбер архитектор һәм археологлар (С. Айдаров белән А. Халиков) кабатларга яраталар, «Боровицкая» башнясы Сөембикә манарасы өчен архитектур нигез булган, диләр. Мондый сорау туа: ни өчен соң нәкъ шулай, ә киресенчә түгел? Беренчесе Мәскәүнеке, икенчесе Казанныкы булган өчен генәме? Безнеңчә, бу җитди дәлил була алмый. Казанның кайбер архитектура истәлекләренең мәскәүдәгеләр өчен үрнәк булганлыгы тарихта билгеле инде. Мәсәлән, борынгы Казанның 8 манаралы Җамигъ мәчете Мәскәүнең Кызыл мәйданындагы атаклы Покров чиркәвенә (Василий Блаженный храмы) нигез булган. (Кызыксынган иптәшләргә бу хакта тулырак итеп атаклы тарихчылар Ш. Мәрҗани һәм М. Худяков хезмәтләреннән танышырга мөмкин.) Мәскәүдәге Казан вокзалының башнясы да Сөембикә манарасына, ягъни шәһәребезнең архитектур символына охшатып эшләнгән.

Әгәр дә В. Суслов һәм И. Грабарь ниндидер аңлашылмаучылык нәтиҗәсендә, русларга кадәр Казанда һәм бөтен Казан җирендә архитектура булмаган, дигән фикер әйткән булсалар (гәрчә бу фикернең мәгънәсезлеген шул чорда ук тупланган материаллар күрсәтеп торса да), соңгарак рус һәм татар галимнәре, мәсәлән, М. Худяков һәм Ф. Вәлиев, XVI йөзнең рус миниатюраларына, Касыйм һәм Кырым ханлыклары җирлегендә сакланып калган корылмаларга таянып (ә ул дәүләтләр белән Казан ханлыгы арасында киң сәяси, этник һәм мәдәни мөнәсәбәтләр хөкем сөргән), Казан шәһәренең татар чорына караган күп кенә архитектур формалары булганлыгын исбат иттеләр. Гомумән, соңгы берничә дистә ел буена алып барылган фәнни тикшеренүләр, бигрәк тә археологик казулар, шуны күрсәттеләр: казан-татар архитектура мәктәбенең тирән, нык тамырлары булган, алар болгар чорыннан килә. Җир өстендә сакланган һәм күпләргә таныш булган бер генә мисал китерик: шәһри Болгардагы атаклы Кара пулат чын мәгънәсендә Сөембикә манарасы өчен сәнгати нигез булып

тора — тегесендә дә, бусында да шул ук дүрткырлы ярус-лар (катлар) өстенә утыртылган сигезкырлыклар. Дөрес, соңгысында ярус лар саны күбрәк, әмма мәсьәлә саннарда түгел, ә системада. Сүз уңаеннан: узган гасырның күренекле немең географы һәм сәяхәтчесе, Россия Фәннәр академиясе әгъзасы А. Гумбольт Сөембикә манарасындагы нәкъ менә шул системага игътибар итеп, аның Шәрык архитектурасы үрнәге икәнлеген әйткән. Рус совет архитекторы, профессор В. Егерев Сөембикә манарасы хакындагы махсус хезмәтендә болай дип яза: «Манараның төзелешендәге композицион алымнар күләмнәренең ритмик эзлеклелеге арта баруында чагыла, әмма бу арта бару рус архитектурасындагы алымнарда бөтенләй аерылып тора... манараның вертикаль күтәрелеше һәм ярусның кискен, киртләчле булуында, бер каттан икенчесенә күчкәндә баскычлылыкны аерып күрсәтүдә чагыла: моның өчен югары катларда күзгә бәрелеп торучы горизонталь бүлемнәр эшләнгән, кыскасы, төзүче-оста ачыктан-ачык өскә таба үсешне киметә төшү, манараны какшамас нигезгә утырту, җиргә ныграк бастырып куюı, гомумән, корылманың көчен һәм куәтен күбрәк күрсәтүгә омтылган. Без монда бөтенләй икенче композицион алым, ягъни Көнчыгыш, аерым алганда, татар архитектурасына хас алым булуын билгеләп үтәбез». Без исә шуңа басым ясап үтик: бу сүзләрне ниндидер һәвәскәр түгел, ә югары класслы белгеч, профессионал язган.

В. Егерев шулай ук манараның эшләнешендәге татар архитектурасына хас кайбер мөһим элементларны да күрсәтеп үтә, шулар арасында: мәчет манараларын төзегәндә киң кулланыла торган күп катламлы кәрнизләр; тәрәзә урыннарын уеп эшләүдәге үзенчәлек; капительләрне (терәкләрнең өске өлешләрен) эшләгәндә кирпечләрне бер-берсенә өюдәге махсус алымнар һ. б. Ә инде Мәскәү Кремлендәге «Боровицкая» башнясына килгәндә, В. Егерев мондый фикер әйтә: XVIII йөзнең 80 нче еллар уртасында төзелеп беткән бу башняның формалашуында аңа хәтле үк салынган атаклы Казан манарасының ачык һәм нәфис силуэты үрнәк булган (бу хакта Казанда 1946 елда рус телендә чыккан «Башня Сююмбеки» исемле фәнни мәкаләләр җыентыгыннан укый аласыз).

Сөембикә манарасын руслар салган, дигән фикерне алга сөрүчеләр тагын бер дәлил китермәкче булалар: бу манара, диләр алар, XVIII йөзнең икенче яртысында яшәгән Голландия сәяхәтчесе Н. Витзенның китабына кертелгән Казан шәһәренең күренешләрендә юк. Беренче башлап бу хакта П. Дульский (ул Казан кешесе, сәнгать белгече)

язып чыкты; шушы ук фикер янә дә исемнәре телгә алынган кайбер Казан галимнәренең дә, Сөембикә манарасы XVII, хәтта XVIII йөздә төзелгән, дигән карашларының төп дәлилләреннән берсе булып тора. Әмма әле 1917 елда ук татар тарихчысы Г. Баттал мондый карашны шактый дөрес тәнкыйтьләп чыккан иде. Мәгълүм ки, Н. Витзен китабы Амстердамда өч тапкыр — 1692, 1707, 1785 елларда — басылып та, ул басмалар Казан китапханәләрендә беркайчан да булмаган һәм хәзер дә юк. Аларда бирелгән Казан күренешләрен, ягъни Кремльнең ике рәсемен, чиркәүләр тарихы белгече И. Покровский үзенең «Казан архиерей йорты» (Казан, 1916 ел, рус телендә) исемле китабында китерә һәм заманында Витзенның Казанда булу-булмавының билгеле түгеллеген, ә Европа һәм Азия илләре һәм шәһәрләренә кагылышлы төрле хәбәрләрне Мәскәүдә яшәп җыйганлыгын яза. Һәм менә Казан күренешләренең ничек итеп Н. Витзен китабына эләгүе хакында Г. Баттал, безгә калса, шактый эзлекле вә ышандырырлык фикер әйтә: «Бу хәлдә Казан шәһәрен Витзенга тәрсим итеп (рәсемгә алып.— *Р. Ф.*) җибәргәндә мөсаһәләнең (игътибар итмәүнең.— *Р. Ф.*) булуы, яки татарлардан калган әсәргә әһәмият бирмәү тәгасепнең (кирелегенең.— *Р. Ф.*) катышуы мөмкин түгелме? Әгәр бу манзаралар бер археологның яки Витзенның үзенең рәһбәрлеге (җитәкчелеге.— *Р. Ф.*) астында тәрсим ителгән булсалар иде, Сөенбикә («Сөембикә»нең әүвәлге язылышы, соңыннан «н» «м» белән чиратлашкан.— *Р. Ф.*) манарасы, әлбәттә, калмас иде, безгә бит аларның кем тарафыннан тәрсим ителүе мәгълүм түгел. Ихтимал, алар бер мөтәгассыйб (фанатик.— *Р. Ф.*) христиан руханиеның рәһбәрлеге астында тәрсим ителгәннәрдер, ихтимал монда да тарихи интерестан бигрәк «благочестие» (тәкъвалык) зур роль уйнагандыр» (Баттал Г. Сөембикә манарасы хакында.— «Аң» журналы, 1918, № 2, 35 бит). Бу — фараз кылу. Әмма Витзен китабындагы рәсемдә Сөембикә манарасы гына түгел, ә башка татар биналары, әйтик, Нурали мәчете һәм хан сарайларының калдыклары (ул заманда әле алар җимерелмәгән булалар) да юклыгын искә алсак, бу фараз итү бик тә ышандырырлык. Христиан динендәге кешенең мөселман, ягъни татар ядкәрләренә игътибар итмәгәнлеге тагын бер әйбердә ачык күренә: рәсемнең уң ягында, Болак елгасы артында «татар шәһәре» күрсәтелгән, әмма шунда мәчетләр урынына... чиркәүләр ясап куелган. Мондый хәл, шөбһәсез, рәссамның Казан шәһәренә христианлык карашыннан чыгып, бик тә тенденциоз, берьяклы килүе, мәчет вә башка мөселман ядкәрләренә күз йомуы хакында сөйли.

Шуңа күрә, Казан шәһәре һәм аның борынгы корылмаларының чын, тарихи йөзен күзаллаганда Н. Витзен китабына теркәлгән рәсемнәрне ышанычлы чыганак дип атап булмый.

Сөембикә манарасы хакында язган йөздә һәм безнең гасыр башларында тарих фәнендә булган мәгълүматлар һәм гыйбрәтле фикерләр кыскача менә шулар. Кайберәүләрнең Сөембикә манарасы ул XVII, хәтта XVIII йөз истәлеге дип, бернинди ышанычлы мәгълүматлар белән расланмаган фараз кылуларын аларның ук замандашлары һәм соңгырак чор галимнәре кире кактылар. Шунысы бик тә әһәмиятле, ул фаразларның нигезсезлеген татар галимнәре генә түгел, ә иң башлап рус тарихчылары билгеләп үттеләр, шулар арасында христиан рухани-тарихчылары да бар. Мәсәлән, Кремльдәге Благовещение соборының өлкән побы П. Невзоров һәм мәркәзебез тарихының зур белгече, архиепископ П. Заринский. Нәкъ менә алар манараның бервакытта да христианнар, ягъни руслар өчен истәлекле изге урын булмаганлыгына басым ясадылар, киресенчә, аның мөселманнар-татарлар өчен бик кадерле тарихи ядкәр икәнлеген раслап чыктылар.

Революциягә кадәр Сөембикә манарасы турында язган рус тарихчыларының иң күпчелеге (ә милли чыганакларны, халык авыз иҗаты әсәрләрен яхшы белгән үзебезнең олы тарихчыларыбызны әйткән дә юк инде) әлеге истәлеккә карата башка халыкларның түгел, нәкъ менә татарларның чиктән тыш ихтирамлы булуын, манараның татарлар өчен изге, илаһи бер урын икәнен, аның халык күңеленә мәңгелеккә кереп урнашканын кат-кат билгеләп үттеләр. Татар халкы үзенең сөекле кызы Сөембикә һәм аның исемен йөртүче данлыклы манара хакында гасырлар дәвамында җыр-бәетләр, риваять-легендалар иҗат иткән, аларны буыннардан буыннарга чәчми-түкми тапшырып килгән. Халык гасырлар буена манара төбендә гыйбадәт кылырга йөргән — боларның һәммәсе татар галимнәре һәм чын демократик рухлы рус тарихчыларының хезмәтләре аша ныклап фәнгә дә кереп урнашты.

Сөембикә манарасының борын-борыннан татар халкы өчен изге урын булганын искә алып, һәм, әлбәттә, аның турындагы фәнни материалларга нигезләнеп, РСФСРның Милләтләр эше буенча халык комиссариаты 1918 елның 24 январенда (яңа стиль белән 6 февральдә) В. И. Ленин күрсәтмәләре нигезендә «Казандагы Сөембикә манарасын мөселман хезмәт халкына бирергә» дигән карар чыгара һәм шул хакта телеграф белән Казан совдепына (бүгенчә әйтсәк, шәһәр Советына) хәбәр итә. Карарны үтәү нигезен-

дә дип уйларга кирәк, шул ук елда манара өстенә ай куела (аның башындагы сәмруг кош рәсеме 1917 елның сентябрендә төшерелгән була). Әмма ай 10 елдан соң, 20 нче еллар ахырында (1928 яки 1929 ел, кызганычка каршы, төгәл мәгълүматым юк) «халык дошманнары» дип каһәрләнгән «солтангалиевчеләр»гә һәм гомумән Татарстанда «милләтчелек»кә каршы аяусыз көрәш башланган чорда бәреп төшерелә. Белгәнебезчә, Мирсәет Солтангалиев һәм аның иптәшләре бүгенге көндә тулысынча акланды, заманында алар өстенә ягылган нахак бәлаләр, аларга каршы эшләнгән кара эшләр җинаять дип табылды. Шуңа күрә, Сталин репрессияләренең башланган чорында ук үткәрелгән эшне, ягъни Сөембикә манарасыннан айны бәреп төшерүне дә законсызлык, башбаштаклык дип бәяләргә кирәк.

30—50 нче еллар тоталитаризмы һәм лозунглар, казарма социализмы чорында, җитмәсә, мәсхәрә итеп, башыннан ае да бәреп төшерелгәч, Сөембикә манарасы хакындагы революциягә кадәр тупланган фәнни-иҗтимагый фикер һәм Совет хөкүмәте органнарының үз карары белән дә исәпләшми башладылар, чынында аларны оныттылар. Дөрес, Бөек Ватан сугышының беренче елында ук илебезнең әһәмиятле культура истәлекләре белән беррәттән Сөембикә манарасының да үлчәмнәре алынды. Бу эш, иң беренче чиратта, дошман самолетларының шәһәрләрне бомбага тоту мөмкинлекләрен истә тотып, ул истәлекләр турында тулы мәгълүматлар туплау максатында эшләнде. Бу үлчәмнәр Казан фәнни җәмәгатьчелегенең якыннан кызыксынуы астында, зур төгәллек белән башкарылды. Шул эшләр нигезендә манара турында гыйльми хезмәтләр-мәкаләләр язылды, манарага тарихи-архитектур анализ профессор В. Егерев тарафыннан эшләнде; аның карашлары белән без югарыда танышып үттек. Сөембикә манарасының татар архитектура истәлеге булуы турындагы фикер В. Егерев хезмәтенең башыннан ахырына кадәр кызыл җеп булып узса да, аның салынган елы итеп ул XVII йөзне атый. Мондый аңлашылмаучылыкның төп сәбәбе шунда ки, ул вакытта күпләрне 1854 елда табылган һәм инде безгә таныш булган берничә рус акчасы аптырашта калдыра, бутый. Моның шулай икәнлеге галимнең үз сүзләрендә дә күренә: манара XVII йөздә төзелгән, дип раслауда төп дәлил булып кайчандыр аның янында табылган «бары тик берничә акча» гына санала, ди ул.

Манара XVII гасырда салынган, дигән фикерне ул елларда бик тырышып яклаган кеше мәгълүм тарихчы-археолог Н. Калинин булды. Кремльдә тикшеренүләр алып

барганда ул, манара нигезе янында кечкенә генә бер шурф-чокыр казып, аның XVII йөздә салынганлыгы турында нәтиҗә ясый. Ул вакытта Н. Калинин башкарган эшләрнең материаллары (сызымнар, фоторәсем, отчет һ. б.) белән танышкач, миндә, ягъни археологта, шундый фикер туды: ул материаллар манара нигезен XVII йөз белән генә түгел, ә гомумән нинди дә булса археологик катлам белән бәйләргә мөмкинлек бирмиләр. Күз алдына китерү өчен шәрехләбрәк әйтик: «шурф» —кое авызы яки аннан да кечерәк үлчәмле бер чокыр-казылма, һәм шуның нигезендә генә манара хәтле манараның «яшен» билгеләргә һич кенә дә мөмкин түгел. Ләкин шуңа да карамастан, Н. Калинин, Сөембикә манарасы XVII гасырда төзелгән, дип язды. Шулай бит ул—аның татарныкы икәнен исбат итәр өчен, бәлки, китап язарга кирәктер, ә менә руслар салганлыгын «раслар» өчен ике авыз сүз әйтү җитә, чөнки заманында бөтен тарих «Кыскача курс»ка нигезләнгән коммунистик идеологиягә, «милләтчелек»кә каршы кискен көрәшкә корылган иде. XVII йөз турындагы сүз «Татарстан тарихы»ның бер чыгарылышыннан икенчесенә күчеп йөрде, тарихи-географик әдәбиятта, беллетристикада, һәртөрле белешмә һәм юл күрсәткечләрдә, масса-күләм-информация чараларында урын алды. Шул ук дата манарага кагылган тактага ныгытып язып куелды, Кремль буйлап экскурсия үткәреп йөрүче «гид»ларның авызыннан төшмәде. Кремльгә берәр эш белән барып кайтканда, төркем-төркем булып басып торучы сәяхәтчеләр яныннан узышлый кызыксынып колак салсаң, Иван Грозный, «Казанның Рус дәүләтенә кушылуы», Сөембикә манарасы һ. б. турында нихәтле мәгънәсез, ялган сүз ишетеп, хәйраннар булып китәсең. Ирексездән сорау туа: шулай дип сөйләргә кайда һәм кемнәр укыта икән соң аларны? «Укытучылар» итеп тә кирәкле, ышанычлы кешеләрен чакыралардыр инде...

Сөембикә манарасының татарларныкы булганлыгы хакындагы фәнни-иҗтимагый фикернең яңарышы 1918 елдан соң нәкъ ярты гасыр узгач, ягъни 1968 елда «Казан утлары» журналында (9 нчы сан) Габдулла ага Шамуковның манара турында күләмле генә мәкаләсе басылу белән башланды. Журналның ул вакыттагы мөхәррире Р. Мостафин бик зирәк эш эшләде: ул Г. Шамуков мәкаләсен бастырып кына калмады, ә аның буенча «түгәрәк өстәл» янында сөйләшү оештырып, мәкалә янына шул материалларны да өстәде. Мәкаләдәге фикерләр, шулай итеп, бер Габдулла аганың гына түгел, ә сөйләшүдә катнашкан һәм аны яклаган (бер кешедән кала) архитекторлар, археолог, этно-

граф, рәссам һәм язучыларның Сөембикә манарасы хакында уртак фикере дә булды.

Мәкаләдә манара тарихы буенча фәндә тупланган мәгълүмат һәм карашларга җитди анализ ясалган иде, шуңа күрә бүгенге кайбер архитекторларның ул язмага һәм аның авторына булган тискәре карашы белән килешеп булмый. Шунысы бик мөһим, Г. Шамуков Сөембикә манарасы хакында артист буларак түгел (С. Айдаров эре генә билгеләп үткәнчә, ул «артист Шамуков» гына түгел, ә СССРның халык артисты иде), ә татар культурасының күренекле вәкиле, заманының тирән белемле һәм киң эрудияцияле, алдынгы карашлы һәм принципиаль, туры сүзле зыялысы буларак язды. Брежнев-Суслов тоталитар идеологиясенең башлангыч чорында нәкъ менә шушы кеше милли культурабыз истәлекләренең аянычлы хәле һәм шул истәлекләрнең иң кадерлесе булган Сөембикә манарасы турында дөрес сүз әйтергә курыкмады. Шуның өчен аны, ул чорларда гадәти булганча, тиешле органнарга да чакырып йөрттеләр. Тик мәрхүм алардан гына курка торган зат түгел иде.

Мөтәхәссис (специалист) — голәмә дәшергә курыккан ул заманда Сөембикә манарасы хакындагы хакыйкатьне яклап сүз әйткән Габдулла ага Шамуковны мин чын күңелдән зур ихтирам вә сагыну хисләре белән искә алам.

Г. Шамуковтан соң манараның татар истәлеге булуы хакындагы мәсьәләдә артка чигенеш башланып, тагын рус чорында, ягъни әлеге шул XVII, хәтта XVIII йөзләрдә салынганлыгы турындагы карашлар калкып чыкты. Бу юлы инде аны татар халкының үз уллары — С. Айдаров белән А. Халиков күтәрделәр. Заманында С. Шпилевский, Н. Загоскин, В. Егерев һәм башка алдынгы рус галимнәренең Сөембикә манарасы турында язган гадел фикерләреннән соң боларның язмалары бик тә гыйбрәтле төс ала. Бу ике галим нигездә В. Суслов, И. Грабарь һәм Н. Калинин фикерләрен кабатлыйлар, һәм ул фикерләрнең дәлилле булмаганлыгын без югарыда күреп үттек инде, шуңа күрә алар белән бәхәскә кереп торуның монда кирәге юк. Җитмәсә, бу ике галимнең Сөембикә манарасы буенча ялгышлары тарихчы-археолог Ә. Мөхәммәдиев һәм географ Ф. Салихованың «Вечерняя Казань» газетасында басылган мәкаләләрендә (1988, 12 март һәм 1990, 14 май) бик дөрес, профессиональ бәя алды. Мөмкинлектән файдаланып А. Халиков һәм С. Айдаровның әлеге мәсьәләдә элементар, фактик ялгышлар җибәрүләрен, булган хезмәтләрдән дөрес файдаланмауларын белдереп үтәсе килә. Мәсәлән, архитектор Айдаров манараны XVIII йөзнеке дип

әйткәндә археолог Халиковка таяна. Халиков үзе аны XVII гасыр истәлеге дип атый. Шул ук С. Айдаровның: профессор В. Егерев Сөембикә манарасын рус архитектурасы әсәре дип санады, дигән сүзләре, йомшак итеп әйткәндә, чеп-чи ялган, чөнки Егеревның бу мәсьәләдәге бөтенләй икенче төрле фикере күпләргә мәгълүм (аның белән без дә алдарак танышып киттек инде). Әйтик, А. Халиков Нугай кенәзе Йосыфның кызы Сөембикәне Юныс кызы дип атый икән (чынында Юныс ул Сөембикәнең туганы), аңысы аның эше. Кайберәүләр әйтер тагын: барыбер түгелмени — Йосыфмы, Юнысмы, нигә вакланып торырга инде? Бу инде теге: Василий III ме, Иван IV ме — барыбер бит инде, дигән кебек була. Кем өчендер, бәлки, барыбердер, әмма фәндә вак әйберләр булмый. Шунысы кызганыч: Сөембикә манарасының татарныкы булуы турында сүз чыкса, бөек халык вәкилләре: «Үзегезнең үк галимнәрегез аны руслар салган дип әйтәләр бит»,— дип авызны капларга яраталар. Татар тарихы фәнендә беренче тапкыр, Сөембикә манарасы татарныкы түгел, дип әйтеп чыгу, күрәсең, әлеге ике галим өчен заманча фикер йөртү булгандыр инде...

Инде килеп, Сөембикә манарасының нәрсә булганлыгы турында. Революциягә кадәрге тарихчыларның күбесе аны янәшәдәге Нурали (Нургали) мәчетенең манарасы булган дип яздылар. Татар галимнәре манараны халыкның борын-борыннан «Хан мәчете» дип атап йөрткәнлеген дә өстәп әйттеләр. Бу — бик мөһим әйбер, чөнки гасырлар дәвамында өзелми килгән халык хәтере әлеге мәсьәләдә ышандырырлык дәлил булып тора. Тагын шунысы бик әһәмиятле: Сөембикә манарасы һәм Нурали мәчете турында язучылар бу ике истәлекнең бер-берсенә матди якынлыгы, шул ук вакытта Кремльдәге рус корылмаларыннан үзгә буларак, аларның ташландык хәлдә ятуын билгеләп үттеләр. Бу уңайдан бер генә хәбәр китерик: узган гасырның 30 нчы елларында Рәсәйдә булып, күп кенә атаклы тарихи истәлекләрне, шул исәптән Сөембикә манарасын да рәсемгә алган һәм аның хакында халык арасында риваятьләр җыйган француз сәяхәтчесе Д. Жюльвекур болай дип яза: «Манара да, аның белән тоташкан мәчет тә бөтенләй диярлек ташланган: ләкин вакыт дигәнең аларны әле нык үзгәртмәгән. Алар өстендә үлән һәм вак агачлар үсә, тик иске татар цементы җиңүчеләрнең игътибарсызлыгына гына каршы торырлык». Әһәмият итик: бу сүзләр Нурали мәчетен рус чиркәвенә әйләндергәнче, аның ташландык хәлдә яткан вакытында язылганнар. Бу ике истәлекнең бербөтен булуын искә алсаң, кайбер тарихчылар-



Сөембикә манарасы һәм урыс чиркәвенә әверелдерелгән элекке Нурали мәчете бинасы. Э. Турнереллиның 1830 еллар азагында ясаган рәсеме

ның (А. Халиков): Сөембикә манарасы «писцовый кенәгәләр»дә юк дигән сүзе белән килешүе кыен. Мәгълүм ки, ул кенәгәләр Казан алынып, 13—15 ел үткәч, 1565—1568 елларда төзелгәннәр һәм аларда «Сөембикә манара»сы дип аталган аерым бер корылма телгә алынмый, әмма кенәгә төзүчеләр Кремльдәге өч мәчетне атыйлар: «Хан сарас янында», «Благовещение каршында» (бу чиркәү Казан яуланып берничә ел үткәч, 1556—60 елларда төзелә) һәм «Нурали мәчете». Мәгълүм ки, мәчетләр гадәттә манаралы булалар һәм алар үзләренең манаралары белән бербөтен итеп каралалар (берәү дә мәсәлән, Мәрҗани мәчете һәм аның манарасы дип сөйләми, ә Мәрҗани мәчете дип кенә әйтә). Әлбәттә, борынгы Казанның мәчетләре дә шундый булган. Иван Грозный армиясенең бер гаскәр башлыгы, шул вакыттагы Казанны үз күзе белән

күргән А. Курбский: «Анда хан сарайлары һәм бик тә биек таш мәчетләр бар...» — дип яза. Монда һич шик юктыр, мәчетләрнең «бик тә биек» манаралары хакында сүз бара. Бу мәчетләрнең өчесе, әлбәттә, «писцовый кенәгәләр»не төзегәндә булганнар һәм писерләр аларны шул килеш кәгазьгә теркәп тә куйганнар.

Мондый сорау тууы мөмкин: нишләп соң «хан мәчете», Нурали хан булмаган бит? Әйе, атаклы Ширин нәселеннән булган Булат улы Нурали — хан түгел, әмма ул — карачы, биләр бие (бәкләри бәк), ягъни кенәзләр кенәзе, бөек кенәз була, феодаль иерархиядә ханнан кала икенче кеше. Андый олы шәхесләрне соңыннан бездә «хан» дип атау гадәте булган. Дөрес, монда бөтен сорауларга да төгәл җавап биреп бетерү мөмкин түгел, кайбер нәрсәләрнең әле ачыкланасы бар. Нурали мәчете бер, «Хан мәчете» икенче булган булуы да мөмкин. Риваятьләрдә болай дип тә әйтелә: Сөембикә үзе салдырган мәчеттә ире Сафагәрәйне җирли һәм аның кабере өстендә гыйбадәт кылып торганда үзен руслар әсир итәләр, манара да шуңа күрә аның исемен йөртә. Сөембикәне 1551 елда Мәскәүгә әсирлеккә алып китәр алдыннан аның мәчеткә, ире кабере янына кереп, аның белән хушлашуы турында «Казан тарихы» исемле рус чыганагында да язылa (аның авторы Казан алыныр алдыннан 20 ел буе шунда әсирлектә яши, күп вакытын Сафагәрәйдә хезмәт итә). Ул да мәгълүм булсын: әлеге язмада Сафагәрәйнең табуты турында әйтелә, моның ул заманнардагы патшаларны һәм ханнарны күмү гадәте буенча, таш табут-саркофаг булуы да мөмкин.

Башка халыклардагы кебек, бездә дә дәүләт башлыкларын гыйбадәтханәләрдә (бездә — мәчетләрдә) яки алар янында күмү гадәте булган. Шәһри Болгарда, мәсәлән, Кечс манара янында «Ханнар зираты» бар. Югарыда без А. Курбскийның Казандагы «бик тә биек таш мәчетләр» хакындагы сүзләрен китердек. Аларны дәвам итеп, ул болай дип яза: «...шунда аларның патшалары күмелгән». Күрәсез, халык иҗаты әсәрләре тарихи чыганакларга каршы килмиләр, Сөембикә манарасының, ягъни әүвәлге мәчет манарасының аскы катындагы күпләргә мәгълүм зур бушлыкның хан кабере өчен махсус эшләнгән булуы, мәсәлән, миндә шик тудырмый. Анда таш табут-саркофаг булганмы яки кабер ташымы — анысын әйтүе кыен, чөнки ул урын ташлар һәм асфальт белән капланган һәм анда бервакытта да археологик казулар алып барылмаган. Җитмәсә, хан каберенең Казанны яулап алганда юкка чыккан булуы да бик табигый хәл.

Фәндә шулай ук әлеге манараның, дөресрәге, аның аскы катының ханнар сараена кереп йөрү өчен капка булганлыгы турында да фикер бар. Манараны руслар салган, дигән идеяне яклаучылар аның XVIII йөздә губернатор йортына кереп йөрү өчен капка буларак төзелгәнлеген әйтергә яраталар, һәм бу фикер бүгенге Казандагы рус җәмәгатьчелегенең аерым даирәләренә таралып өлгергән инде. Әмма югарыда исемнәре аталган, революциягә кадәрге рус тарихчыларының күбесе бик дөрес әйтеп киткәнчә, ул вакытта капка итеп астында уңайлы бушлыгы булган һәм аңа хәтле үк төзелгән әзер манара — Сөембикә манарасы файдаланылган.

Ниһаять, манара башында нәрсә булырга тиешлеге мәсьәләсе. С. Айдаров «Вечерняя Казань» газетасында басылган мәкаләсендә (1989, 21 һәм 23 октябрь) Казан реставрациясе остаханәләренә бу проблема буенча өч төрле тәкъдим кергәнлеген әйтә, 1) аждаһа елан сурәте; 2) шул ук аждаһа өстенә куелган урак белән чүкеч рәсеме; 3) ай. Автор үзе икенче тәкъдимне хуплый. Мондый сорау туа: аждаһа өстенә кунаклаган эшче-крестьян властеның символы нәрсә хакында сөйли икән соң — аларның тыныч яшәве турындамы, әллә ике арада канлы сугыш чыгып, Советларның бөек җиңүе хакындамы?

Казан шәһәренең гербы әлеге шул аждаһа рәсеме икәнлеге күпләргә мәгълүм. Менә шул гербны Сөембикә манарасының, ягъни мәчет манарасының өстенә утыртып куясы итәләр кайберәүләр. Гадәттә гербларны вокзал стеналарына, почта ишекләренә, хөкүмәт биналарына ябыштыралар, ә чиркәү гөмбәзләренә һәм мәчет манараларына сәламәт акыллы кешеләр тәре һәм ай куялар. Халыкта «Хан мәчете» исеме белән киң таралган һәм чынында да элек мәчет манарасы булган Сөембикә манарасына ай менеп утырырга тиеш.

Югарыда сөйләгәннәрдән чыгып, шундый нәтиҗә ясыйк:

1. Сөембикә манарасының 1552 елда Казанны яулап алганнан соң төзелүе хакында фәндә бер генә документ, бер генә тарихи чыганак та юк. Әгәр дә шул чорда, ягъни XVI йөзнең икенче яртысы — XVIII йөзләрдә салынган булса, һичшиксез шул заманның рәсми документларында яки башка төрле язмаларда теркәлгән булыр иде, чөнки Казанның руслар төзегән күп кенә архитектура истәлекләренең даталары билгеле: Кремльдәге Благовещенск соборы, Спасс һәм Никольск башнялары (1556—1560 еллар), алардан ерак түгел урнашкан Петропавел чиркәве (1720 еллар) һ. б.

2. Әгәр дә манараны руслар салган булса, ул шул рус чорының иҗтимагый фикерендә чагылыш тапкан, рус халкының тарихи хәтерендә сакланып калган булыр иде. Рус халкы бервакытта да аны үзенең изге җире дип санамады, аның турында җырлар җырламады, аның янына килеп чукынмады, аңа икона һәм тәре куймады. Үзенең «святыня»ларына мәхәббәт саклаган рус халкының үз башнясын Казан ханлыгы тарихында якты эз калдырган, аның бәйсезлеге өчен көрәшкән, татар халкының күңеленә мәңгегә кереп урнашкан, ислам динендәге кеше исеме белән атавы гамәлгә сыймаслык эш.

3. Сөембикә манарасы татар халкының иң кадерле, иң газиз тарихи истәлеге ул. Халкыбыз аның турында гасырлар буенча риваять-легендалар, җыр-бәетләр тудырган, аны буыннардан-буыннарга чәчми-түкми, кадер-хөрмәт белән тапшырып барган, гасырлар дәвамында аның янына Коръән укырга йөргән. Сөембикә манарасы татар халкының канында, йөрәк түрендә, аның мәңгелек тарихи хәтерендә. Боларның һәммәсен дә инкарь итәргә тырышу, аларга каршы көрәшү халык тарафыннан кискен каршылыкка очрады һәм очраячак.

4. Үзенең архитектур чишелеше, стиль үзенчәлекләре, композицион алымнары, эшләнешендәге мөһим элементлары һәм бизәлеше ягыннан Сөембикә манарасы татар архитектура сәнгатенең ачык үрнәге булып тора. Ярусларының кискен-контрастлы булуы, күзгә бәрелеп торган баскычлылыгы белән манара рус хәрби башняларыннан һәм чиркәү колокольняларыннан бик нык аерылып тора — боларына корылманың бер өлешеннән икенчесенә әкренләп, салмак күчү, гомумән, сыгылмалылык, пластиклык хас.

5. Октябрь революциясеннән соң ук Совет хөкүмәте органнары тарафыннан кабул ителгән «Казандагы Сөембикә манарасын мөселман хезмәт халкына бирергә» дигән карарны үтәү йөзеннән һәм халык үтенечен искә алып, элекке мәчет манарасы булган Сөембикә манарасына ай куярга, дөресрәге, 20 нче еллар азагындагы гаделсезлек нәтиҗәсендә алып ташланган айны торгызырга.

ХАТИМӘ (Эпилог). Комиссия утырышыннан соң берничә көн узгач, эштән кайтып килгәндә мине зур гына кара сакаллы, бераз «чиертеп» тә алган берәү очратты. Ул үзе аерым даирәләрдә билгеле кеше, хәтта иконалар тарихы буенча белгеч тә санала. Безнең комиссия карары турында ишеткән булган, әлбәттә. Шуңа күрә мине каршы да алган һәм минә шактый җитди кыяфәт белән кисәтеп үк ташлады: «Әгәр дә манара өстенә ай куйсагыз, шул

көнне үк без сезнең ул манарагызны сүтеп ыргытырбыз!» Кемнәр була инде ул «без»? — дигән сөалемә җавап биреп тормады, эре-эре атлап китеп үк барды. Болар Иван Грозный чорларын сагынып, мәчет манараларындагы айларга эчләре пошып яшәүчеләр инде. Аларның хәтта христиан-монархистлар союзының Казандагы кечерәк бер бүлеге әгъзалары булу икәнлеге дә билгеле. Хәзер алар Сөембикәгә ай куйдырмау буенча һәртөрле планнар корып, төрле оешмаларга, хәтта хөкүмәт органнарына хатлар язып, татарларны элек куркыткан «милләтчелек» белән куркытырга дип «изге» ният белән йөриләр. Мин үзем аның ише кара сакаллардан гына курка торган кеше түгел һәм андый кара йөрәкләрдән безнең яшьләребез дә курыкмас дип уйлыйм. Иншалла, курка торган заманалар үтеп бара.

«Социалистик Татарстан»,
1990, 15 июль.

Искәрмә: Татарстан республикасы хөкүмәтенең карары нигезендә 1990 елның 26 сентябрендә Сөембикә манарасына ай куелды. Бу изге эшне башкаруда республика мәдәният министрының урынбасары, безнең комиссия әгъзасы Габбас әфәнде Мөхәммәтшинның тырышлыгы зур булды.

ХӘТЕРЕБЕЗНЕ ЯҢАРТЫЙК

Олы шагыйребез Сибгат ага Хәким бөек Тукай турындагы язмаларының берсендә болай дигән иде: «Яз аенда туган, яз аенда үлгән...» Әйе, апрельдә дөньяга килеп, апрельдә китеп барган Тукаебыз. Халкыбызның икенче бер бөек таланты Сәйдәш декабрьдә туып, декабрьдә дөнья куйган. Татарстанның бай һәм данлы, шул ук вакытта әрнүле тарихыннан, ул тарихта якты эз калдырган гали затлар тормышыннан шуңа охшашлы гыйбрәтле хәлләргә тагын да юлыгасың. Халкыбызның бәгъре, аның менә ничә йөз ел инде сагынып-саргаеп искә ала торган гүзәл кызы Сөембикә Казанга 1533 елның августында килеп, 1551 елның августында мәңгегә китеп бара. Соңгы, чын милли дәүләтебез булган Казан ханлыгының оешкан көне төгәл мәгълүм — ул 1445 елның 1 нче, яңа стиль белән 14 октябрь. Ә аның юкка чыккан, һәлак булган көне — 1552 елның 2 нче, яңача 15 октябре. Димәк, көзен туган, көзен үлгән... Болар һәммәсе дә очраклы гына туры килүме, әллә моның хәзергә аңлатып бирә алмаслык ниндидер

эчке, серле бер кануны бармы — сүзем ул хакта түгел. Бу уңайдан бер мөһим әйбергә игътибар юнәлтеп, басым ясап үтәсем генә килә.

XX гасырның быел башланган соңгы унъеллыгы халкыбыз тарихының менә шушы олуг вә әрнүле вакыйгаларын, асыл затларын искә алу чоры да булсын иде. Быелның 25 августында Сөембикәне үзенең бердәнбер улы, Казанның соңгы ханнарыннан булган Үтәмешгәрәй белән әсир итеп Мәскәүгә алып китүгә 440 ел тула. Дәүләтнең мөстәкыйльлеге, аның иминлеге хакына дип, үзен һәм газиз баласын корбан иткән зирәк Сөембикә — татар халкының мәңгелек тарихи хәтерендә. Ул хәтерне быел зурлап бер яңартыйк, Сөембикәне сагыш вә моң белән искә алыйк, милләттәшләр! Яраланган, ләкин горур хәтеребез киләсе елның 15 октябрендә Казан яулап алынуга, Казан ханлыгы бетерелүгә шулай ук 440 ел тулганда тагын бер кат яңарсын. «Татар күңеле ниләр сизгәнен» (Тукай) күрсеннәр, гыйбрәт алсыннар. Әлегә иманын саклап кала алган бер генә татар да ул матәмнәрдән читтә калмасын.

Элекке «Азат хатын» журналының узган елгы 10 санында басылган «Сөембикә һәм Сөембикә манарасы» исемле мәкаләдә мин Сөембикәгә һәйкәл кую кирәклеген дә язып чыккан идем. Ул тәкъдимне тагын бер кабатлыйм. Хосусан, минем күз алдыма улы Үтәмешгәрәйне кочаклап басып торучы моңсу йөзле, әмма горур кыяфәтле чибәр татар хатыны булып килеп баса ул. Быелның 25 августында Сөембикә манарасы янына җыйналган халык белән шул булачак сынга нигез ташы салынсын иде. Үтәмешгәрәйнең Мәскәү Кремлендә, Архангель соборындагы таш саркофаг эчендә яткан сөякләрен Казанга алып кайтып күмү мәсьәләсен дә күтәрергә кирәк. Нигә, башка халыклар үзләренең газиз улларының сөякләрен чит илләрдән хәтле алып кайтып күмәләр бит әле. Нишләп безгә дә ярамасын икән?..

Үзебезнең тарихи мирас комиссиясенең чираттагы утырышын без 1552 елда Казанны дошманнардан саклаганда һәлак булганнарга зур бер һәйкәл-монумент төзү мәсьәләсенә багышларга ниятлибез. Без бу эштә киң җәмәгатьчелекнең, бөтен халыкның зур ярдәменә, якыннан булышлык итүенә мохтаҗбыз.

Һәйкәлләр мәсьәләсенә берничә ачыклык кертү кирәктер. Кайвакыт аерым кешеләр авызыннан, кайбер хатлардан шундый сүзләр ишетергә-укырга туры килә: мөселманнарда кешеләргә һәйкәл кую гадәте юк, пәйгамбәребез Мөхәммәт галиәссәламга, мәсәлән, бер җирдә дә сын куелмаган. Дөрес, пәйгамбәргә һәйкәл юк һәм ул кирәк тә

түгелдер. Чөнки Аллаһы Тәгаләнең җирдәге илчесе булган Мөхәммәт ул һәр хак мөселманның рухында. Һәр хак мөселман, мөбарәк эшкә тотыныр алдыннан һәм кулына Коръән алган саен, Ходасын һәм пәйгамбәрен искә төшерә, аларга мөрәҗәгать итә. Пәйгамбәрләргә һәйкәлләр куймасалар да, кешеләргә — тарихта күренекле эз калдырган, батырлыклар эшләгән, халык бәхете өчен изге көрәштә корбан булганнарга һәйкәл-монументлар һәм сыннар куела. Алар мөселман дөньясында — Төркиядә дә, гарәп илләрендә дә бар.

Кайберәүләр, Сөембикәгә дә, Казанны саклаганда һәлак булганнарга да бер һәйкәл булырга тиеш, диләр. Ә нигә аларны берләштерергә икән? Сөембикә дә, аның улы да 1552 елда һәлак булмаганнар бит. Җитмәсә, бездә монарчы үзебезнең тарихи шәхесләребезгә, борынгы милли каһарманнарыбызга һәйкәл-монументлар булмады, башкаларныкына табынып яшәдек. Аларның берничә булуында файдадан башка берни дә юк. Тик башта бу мәсьәләне җәмәгатьчелек фикеренә әйләндерергә, проектларга конкурс игълан итеп, һәйкәлләр куяр өчен отышлы урыннар сайларга һәм, әлбәттә, иң мөһиме — акча табарга кирәк. «Мескен булып торган» 440 елда «тәкъдир безне ничек изгәнен» (Тукай) яхшы аңлаган татар халкы, иншалла, бу изге эшкә битараф калмас.

1551—1552 елларда Мәскәүгә алып кителгән бихисап зур байлыгыбызны — алтын-көмешләрне, асылташларны, затлы киемнәрне, Казан ханнарының алтын таҗын, хан таягын, тәхетне, дәүләт байлыгын һәм башка кадерле тарихи мирасны халкыбызга, үз җиребезгә кире кайтаруны таләп итәргә вакыт җитте. Менә шулай төрле чорларда, төрле җирләргә таралган, халкыбызның бәһа биреп бетерә алмаслык тарихи мирасын барлау һәм аны үзенең законлы хуҗасына — татар халкына кире кайтарырга бик вакыт. Шулай ук бер Татарстанда гына түгел, ә бөтен Союзда диярлек, хәтта чит илләрдә дә шактый таралыш алган тарихи-мәдәни истәлекләребезне (мәчет, мәдрәсә биналары, атаклы шәхесләр белән бәйле булган йортлар, аларның каберләре, тарихи кульъязмалар һ. б.) табу, барлау, берәүгә дә кирәк булмыйча тузып-җимерелеп ятканнарын торгызу, үз хәленә кайтару, алар турында китаплар һәм фотоальбомнар бастыру, 1917—1920 еллардан соң чит илләргә китәргә мәҗбүр булган, 30 нчы елларда каһәрләнгән һәм оныттырылган тарихчыларыбызның хезмәтләрен дөньяга чыгару һәм, гомумән, олуг тарихи байлыгыбызны торгызу, пропагандалау һәм киләчәк өчен саклау максатында, «Тарихи мирас» фонды төзү бик тә мөһим һәм

«Бабалар кабре янында күңел зар...» Иске Казан каберлегендә, Муллахаҗи кабере янында. Автор фотосы, 1979

зарури бурыч булып килеп басты. Кесәсендә сукыр бер тиене дә булмаган комиссия белән генә эшләрне башкару бик авыр, еш кына мөмкин дә түгел. Җитмәсә, якын арада эшләнәчәк эшләр булып Сөембикәгә һәм 1552 ел корбаннарына һәйкәл-монумент төзү тора. Сүз, инде оешкан әдәби мирас фондыннан башка, тарихи мирас фонды булдыру турында бара.

Әйткәнемчә, 1445 елның 1 октябрендә Казан ханлыгы төзелә (монда сүз Казан шәһәре һәм аның җитәкчелегендәге башлангыч Казан кенәзлеге турында түгел, ә Алтын Урда дәүләте таркалгач барлыкка килгән зур бер мөстәкыйль дәүләт — Казан ханлыгы турында бара. Рус чыганакларында ул «царство Казанское» дип атала). Һәм менә дүрт елдан (ягъни гамәлдәге календарь буенча 1995 елның 14 октябрендә) шул тарихи вакыйгага 550 ел тула. Казан ханлыгы ул безнең фаҗигале тарихыбыз гына түгел, иң беренче чиратта, данлы вакыйгаларга, бөек шәхесләргә, борынгы зур мәдәнияткә бай олуг дәүләтебез дә. Хәтер сандыгыгызга салып куйсагыз иде шушы түгәрәк датаны, гафил булмасагыз, белми калмасагыз иде, туганнар.

Революциягә кадәрге Казан университеты профессоры, күренекле тарихчы, этнограф һәм тел белеме галиме тюрколог Н. Ф. Катанов Казан ханлыгы дәверенә багышланган үзенең бер фәнни хезмәтендә: «Татарлар үз тарих-



Олуг Мөхәммәт хан. Н. Исламов рәсеме

ларын хәтерлиләр»,— дигән иде. Без, бүгенге татарлар да, үзебезнең тарихыбызны хәтеребездән чыгармасак, онытмасак иде.

Милли дәүләтләр, тарихи даталар хакында сүз чыккач, тагын бер мөһим чор турында сүз әйтми һич мөмкин түгел. Тагын ике елдан, 1993 елның башында Алтын Урда дәүләте төзелүгә 750 ел тула. Әйе, 1944 елда ВКП(б) Үзәк Комитетының күпләргә мәгълүм карары белән каһәрләнгән, тоталитар идеологиянең һәм православие чиркәвенең кан дошманына әйләнгән, әмма урта гасырлар тарихында, иң әүвәл татар халкының үткәнендә онытылмаслык эз калдырган, гаҗәеп бай матди һәм рухи мәдәнияткә ия булган искиткеч зур дәүләт ул Алтын Урда. Моңарчы безнең буын да, бездән алдагылар да чит дәүләтләр, чит империяләр, «бөек халык»лар тарихын өйрәнеп, шуларга мөкиббән китеп үсте.

Бүгенге «модный» сүз белән әйткәндә, стереотип фикер йөртүдән, наданлыктан арынырга, тарихи аңыбызны, үткән чорларның берсенә генә дә күз йоммыйча, һәр дәвергә тиешле игътибар итеп, тарихыбызны яңадан язарга вакыт җитте, җәмәгать.

Башкалар үзләренең корольләре, патшалары, бөек кенәзләре белән горурланган чакта, безнең халык үзенең

ханнары өчен хурланып яшәде. Дөресрәге, аны шулай яшәргә мәҗбүр иттеләр. Дистә, йөз еллар дәвамында аның башына тукып, шул ханнарның «ерткычлыклары», «вәхшилекләре», алар җитәкләгән дәүләтнең «караклар оясы» булганлыгы хакында ялган сүз сөйләделәр, миен агуладылар. Арыныйк бу ялганнан, бу наданлыктан, дуслар! Без бүген Үзбәк ханнар һәм Идегәйләр, Олы Мөхәммәт һәм Мәхмүтәкләр, Ибраһим һәм Сафагәрәй ханнар, Булат һәм Нургали Шириннар, Нурсолтаннар, Гәүһәршадлар, Сөембикәләрнең чын тарихларын белергә, шул гали шәхесләр, алар кылган бөек эшләр белән горурланырга, ул горурлыкны үзебезнең балаларыбызга һәм оныкларыбызга тапшырырга тиешбез.

Моннан 85 ел элек, бишенче елның азатлык таңы атып килгән чакта, 19 яшьлек Тукай, киләчәкнең бөек Тукае, илһамланып-дәртләнеп мондый юллар язган иде:

Татарлар рәфгате[1], шаны сикез кат күкләрә китсен;
Әбәд-сәрмәд[2] бу милләтне Ходаем бәхтияр[3] итсен.

Бу бөеклеккә, бу данга, бу бәхеткә ирешү өчен Тукай халыкны гыйлемнәр бакчасына керергә, наданлыктан арынырга, уянырга чакырды. Үткәнебез өчен горурланыйк, хәтеребезне яңартып, киләчәккә өмет баглыйк, туганнар.

«Социалистик Татарстан»,
1991, 29 март.

БЕЗ—БЕР ХАЛЫК

Телдә, фикердә, эштә берлек!

И. Гаспралы

Кырым татарларының һәм, гомумән, бөтен татар халкының олуг әдибе, мәгърифәтчесе һәм сәяси эшлеклесе Исмәгыйль бәй Гаспралы (Гаспринский) язып калдырган бу бөек сүзләр әле күптән түгел генә — 18—22 мартта Симферополь шәһәрендә (элекке чын исеме — Ак мәчет) шушы гали затның тууына 140 ел тулуга багышлап уздырылган халыкара фәнни конференциянең төп девизы булды. Конференциягә Төркиядән махсус самолет белән 42 кешелек зур делегация, Америкадан, Франциядән, Польшадан галимнәр килгән иде. Шулай ук безнең илнең төрле республикаларыннан һәм Мәскәү, Ленинград, Киев

---

[1] Рәфгать — бөеклек.
[2] Әбәд-сәрмәд — мәңге-мәңге.
[3] Бәхтияр — бәхетле.

кебек шәһәрләрдән дә төрле фән вәкилләре җыйналды. Әлбәттә, дистә еллар буенча тыелып килгән, җитмәсә нахакка рәнҗетелгән халыкның улы булган бу зур шәхесне чынлап зурлау өчен әлеге 4—5 көн генә аз иде. Әмма булган кадәресенә дә җыйналган кунаклар да, татарлар үзләре дә бик мәмнүн булдылар. Тантаналар һәм башка төрле җыелышлар, очрашулар күңелләрдә ифрат җылы хисләр уятты, мәңге онытылмаслык хатирәләр калдырды. Күргән гыйбрәтләр дә тау чаклы булды.

Әлбәттә, татарларның Кырымга кайтуы искиткеч зур авырлык белән барган бер вакытта шундый конференция уздыру үзе бер батырлык һәм мондый башлангыч эшнең йөз төрле мәшәкатьләре бар. Шуңа күрәдер дә инде, кайбер кимчелекләр дә булмады түгел. Әйтик, докладларның күпчелеге секцияләрдә тыңланып, алар өчен бары тик ике көндә 2—3 сәгать вакыт бирелде. Шуңа күрә күпләр үзләренең чыгышларын кыскарттылар, кайберәүләр бөтенләй дә сөйли алмый калдылар. Фәкыйрегез дә татар халкының этник тарихы, Алтын Урда һәм аннан соң барлыкка килгән татар дәүләтләре — Кырым һәм Казан ханлыклары арасындагы сәяси вә этномәдәни мөнәсәбәтләр хакындагы докладының кыскача эчтәлеген 7—8 минут эчендә тиз-тиз генә сөйләп чыга алды.

Әмма эш фәнни докладта гына түгел әле. Аны бүтән җирдә, башка вакытта да укып була. Кырымдагы очрашуларның иң мөһиме шунда ки, фәнни конференция һәртөрле тантаналар, башка төрле мәдәни чаралар белән чиратлашып, баетылып барды. Бу бөтен бер халыкның ярты гасырга якын сөргендә булганнан соң туган җиренә әйләнеп кайтып уздырган беренче милли бәйрәме булды. Моның Кырымдагы милләттәшләребез өчен сәяси әһәмияте чиксез зур, ул тантаналарны татарларга кырын күз белән карарга өйрәнгән башка халыклар, җирле властьлар да күрде. Ниһаять, бу тантаналар дөнья җәмәгатьчелегенә мәгълүм булды, чит илләрдән килгән кунакларның күбесенең бу хакта үз илләренә кайткач сөйләүләре һәм язып чыгулары шөбһәсез.

Конференция белән чиратлаштырылып алып барылган тантаналарның берничәсе турында әйтеп үтим. Шәһәр үзәгендә, кечерәк бер парк эчендә Гаспралыга куелган һәйкәлнең таш белән билгеләнгән урынын ачу булды. Шунда ук тиз генә оештырылган концертта — җырлыйлар, биләр, матур сүзләр сөйлиләр — гомум шатлык. Икенче көнне Гаспралы укыткан шәһәр гимназиясе бинасына истәлек тактасы элү тантанасы... Кырым татар рәссамнарының һәм, гомумән, андагы татар тормышын чагылдырган баш-



Бакчасарайда Кырым ханнарының сарае

ка художникларның әсәрләреннән ике җирдә күргәзмә оештырылган иде. Гыйбрәтле рәсемнәр дә шактый. Менә «Кара болыт» исемле кечерәк бер этюд: 1944 ел, җиреннән куылган, хәлсезләнгән халык кара төнгә каршы пычрак юлдан караңгылыкка атлый... Авыр тәэсир... Яки менә НКВД формасын кигән һәм тешләрен ыржайткан бер вәхши Гаспринскийның атаклы «Тәрҗеман» газетасын яндыра. Газета белән бергә халык рухын яндырмакчы. Әмма аны алай гына яндыра, бетерә алмассың, заманасы ул түгел. Әнә халык туган җиренә әйләнеп кайтып, үзенең бөек атасының (кырымлылар Исмәгыйль бәйне шулай дип олылыйлар) юбилеен бәйрәм итә!

Симферопольдән Бакчасарайга сәяхәт кылдык. Бакчасарай — Кырым ханлыгының пайтәхете, башкаласы урнашкан шәһәр; андагы хан сарае пулатлары, мәчетләре, дөрбәләре, зираты әле дә бар. Менә шушы борынгы сарайның ишек алдында, зур-зур паласлар җәеп намаз уку булды. Иң әүвәл биек манарага менеп ике мәзин шушы кечкенә генә шәһәргә яңгыратып азан әйттеләр. Намаз башланды. Анда — илләренә кайткан татар картлары (и газизкәйләр, ничек куанышалар!), төрекләр, укый белгән башка кунаклар. Намаз тәмам булгач, Мостафа Җәмилевне һәм башлап укыган төрек зыялысын (ул чыгышы белән Кырымнан) кат-кат килеп кочакладылар, тәбрикләштеләр.

Ә менә шул сәяхәтнең ахыры ифрат гыйбрәтле, җан өшеткеч булды. Шәһәр читендәге бер җирдә Исмәгыйль бәй Гаспралының кабере урнашкан урын, шунда ук ул җитәкләгән атаклы Зынҗырлы мәдрәсәсе бидалары бар. Каберне 30 нчы елларда җир белән тигезләгән булганнар, аның урынын соңгы елларда гына картлардан сораштыра-сораштыра чамалап табып, өстенә чардуган корып куйганнар, янында ук зур гына гранит таштан билге дә тора. Ә менә мәдрәсә бинасы... Бу — бөтен татар җирендәге иң борынгы мәдрәсә, урта гасырлар университеты. Ул 1501 елда Кырым ханы Миңлегәрәй тарафыннан төзелеп, 410 ел буена өзлексез уку йорты булып хезмәт иткән, ә 1910 елда аның янында ук ике катлы яңа бина салганнар. Монда Казаннан килеп безнең атаклы зыялыларыбыздан Фатих Кәрими һәм Һади Максуди (бөек шәхес Садри Максудиның абыйсы) берничә ел мөгаллимлек итеп китәләр. Менә шушы атаклы уку йортының борынгы (уникаль!) бинасы — бүгенге көндә ярым җимерек хәрабә. Ишек өстенә кадакланган тактага язган «памятник охраняется государством» дигән сүзләр мәсхәрә, урысның үз сүзе белән әйтсәк, кощунство булып яңгырый. Бинаның түшәме җимерелеп төшкән, эче тулы чүп, балчык һәм ватык кирпеч

өемнәре. Бу кирпечләр — Алтын Урда һәм шуннан соңгы татар ханлыклары чорына хас булган тарихи кирпечләр, аларның һәрберсен музейга куярлык. Мәдрәсәнең эчке стеналарына әшәке сүзләр язылган. Әле ярый, ишегенә аркылы салынган борынгы зынҗыры сакланып калган. Мәдрәсәгә кергәндә шул зынҗыр астыннан бөгелеп, башны иеп керә торган булганнар, мәдрәсәнең исеме дә шуннан алынган. Аның янында ук Миңлегәрәй ханның дөрбәсе (мавзолее). Тик ишеге бикле, чит ил кешеләре киләсен белгәч, зур гына йозак элеп куйганнар. Ни өчен дисезме, чөнки эчендә... бәдрәф, элекке мәдрәсә территориясендә урнашкан җүләрләр йортындагылар өчен тәрәтханә. Аның ишеге өстендә дә шул ук «дәүләт тарафыннан саклана» язуы. Әйе, хан кабере өстендәге тәрәт итү урынын дәүләт тарафыннан сакламыйча ярамый шул. Мондый вәхшилек менә шушы дәүләттә генә була ала! Төрекләр түгел, безнекеләр телсез калды. Тамаша тәмам булгач, импровизацион бер митинг булды. Анда төрекләр, бер Мәскәү галиме, инде моңарчы Кырымда булгалап, күп гыйбрәтләр күреп кайткан һәм шулар турында язып чыккан безнең Батулла да бер ачынып, нәфрәтләнеп сөйләп алдылар. Ачынмаска, нәфрәтләнмәскә мөмкин түгел иде шул.

Миңлегәрәй исемен телгә алгач, тарихка мөрәҗәгать итми һич мөмкин түгел. XV йөзнең 20 нче еллары азагындагы Алтын Урда ханы олуг Мөхәммәт бер үк вакытта Кырым белән дә идарә итә, чөнки Кырым Урданың көнбатыш өлеше була. Атаклы Тукай-Тимер династиясеннән булган бу хан соңыннан Казан ханнарының яңа династиянәселенә нигез сала (дөрес, ул үзе бер вакытта да Казан тәхетендә утырмый, яңа дәүләтнең беренче ханы булып аның олы улы Мәхмүтәк санала). Менә шушы Олы Мөхәммәтнең оныгы һәм Мәхмүтәкнең улы Ибраһим — Казанның иң көчле һәм атаклы ханнарыннан (1467—1479 еллар) була. Аның икенче хатыны, Нугай Урдасының бие Тимер кызы атаклы Нурсолтанның өч баласы була: уллары Мөхәмммәтәмин белән Габделлатиф, кызлары Гәүһәршад. Мөхәммәтәмин — 1487—1496 һәм 1502—1518 елларда, Габделлатиф 1497—1502 елларда Казан ханнары булып торалар, Гәүһәршад та күренекле шәхес — ул үзенең ире, атаклы карачы (бәкләри бәк, бөек кенәз) Булат Ширин белән бергәләп дәүләтнең мөстәкыйльлеге өчен иң актив көрәшүчеләрдән.

Ибраһим үлгәч, Нурсолтан Кырым ханы Миңлегәрәйгә кияүгә чыга, Мәскәү белән Казан һәм Кырым арасындагы киеренкелекне йомшартуда бу зирәк хатынның өлеше искиткеч зур була. Миңлегәрәй ханнан Кырымда аның Сә-

Кырымдагы Гезлев (Евпатория) шәһәрендә 1552 елда салынган Җамигъ мәчет

хибгәрәй атлы улы туа, соңгарак, 1521—1524 елларда, ул да Казан ханы була (дәүләтнең «Сәхибгәрәй хан ярлыгы» дигән әһәмиятле тарихи документы күпләргә мәгълүмдер). Казанның тагын да бер мәшһүр ханнарыннан Сафагәрәй — әлеге Сәхибгәрәйнең абыйсы булган Фатихгәрәйнең улы (монысы Миңлегәрәйнең беренче хатыныннан туган бала). Сафагәрәйнең хатыны гүзәл Сөембикә икәнлеген һәм аларның бердәнбер уллары Үтәмешгәрәйнең Казанның иң соңгы ханнарыннан булганлыгын да күпләр белә.

Күрәсез, бу ике дәүләт — Кырым һәм Казан ханлыклары арасындагы сәяси мөнәсәбәтләр бер-берсе белән ифрат тыгыз бәйләнештә булганнар. Әлбәттә, ул бәйләнешләр сәясәт һәм ханнар туганлыгы белән генә чикләнмәгән. Ике арадагы этник һәм мәдәни якынлык та бик тыгыз булган. Казанда күп кенә кырымлылар, ә Кырымда исә казанлылар яшәгән, бер-берсенә өйләнешкәннәр, балалар тудырганнар, кан алышканнар.

Кан димәктән, ул — ике халык өчен чит кан түгел, ә Алтын Урда, ягъни бөтен бер татар халкының гомуми дәүләте чорыннан ук килүче уртак кан. Тарихи чыганаклар буенча, Кырым һәм Казан ханлыкларының икесендә дә бер үк исемдәге дүрт зур ыру булган: Аргын, Барын, Кыпчак, Ширин (әлеге нәселләрнең башка татар ханлыклары һәм Нугай Урдасы өчен дә хас булганлыгы мәгълүм). Ә алар исә Алтын Урда чорыннан ук киләләр. Әгәр дә шушы олуг дәүләт таркалмаган булса, бүгенге аерым этнографик төркемнәргә бүлгәләнмәгән, чын мәгънәсендә бердәм татар халкы барлыкка килгән булыр иде. Заманы өчен бик зур территорияне (Иртеш елгасыннан Кырымга кадәр булган җирләр) биләп торган Алтын Урда дәүләте бигрәк тә XIII йөз ахырлары — XIV йөзнең беренче яртысында чын мәгънәсендә бердәм, куәтле, бай матди һәм рухи мәдәнияткә ия зур дәүләт булган. Аның иминлеге шулкадәр нык булган, шул чор сәяхәтчеләренең язуы буенча, атлы арбага утырган ялгыз кеше юлында бернинди куркынычка юлыкмыйча, исән-имин килеш Үргәнечтән (Урта Азия) Кырымга кадәр барып җитә алган.

Дөрес, бу иминлеккә, бу куәткә соңга табарак, XV йөзнең 10—20 нче елларында, бигрәк тә атаклы бәкләрбәк Идегәй үлгәч, зыян килә. Әмма ул вакытта да әле Алтын Урданың бөтенлеге, көче шактый сакланган була. Сүзебез дәлиллерәк булсын өчен, XV йөздә шул җирләрне үз күзләре белән күргән ике генә кешенең язмаларына мөрәҗәгать итеп алыйк. Аларның берсе 1436—1452 елларда Азак (хәзерге Азов) шәһәрендә яшәгән, Венециядән килгән дипломат һәм сәяхәтче Иосифат Барбаро: «Татар

далаларында 1438 елда Олы Мөхәммәт хан идарә итте, ул безнеңчә император Бөек Мөхәммәт дигәнне аңлата... Татарлар менә дигән аучылар... Татарлар бик күп һәм кирәк вакытта алар өч меңнән алып дүрт меңгә кадәр гаскәр куя алалар (монда сүз Кырымдагы Кефе, хәзерге Феодосия шәһәренең гаскәре турында бара.— *Р. Ф.*)... Идел — күп сулы һәм гаҗәеп киң елга, ул Баку (Каспий.— *Р. Ф.*) диңгезенә коя... Әгәр дә шул елга белән... Мәскәүгә таба йөзсәң, унбиш көн буена елга ягы буйлап Тартар җиренең бик күп санлы кабиләләре белән очрашасың». (Көнбатыш Европада «татар» сүзе уртадагы «р» белән «тартар» рәвешендә дә йөргән.) Яки менә икенче бер автор — бусы Шәрык кешесе, төрек солтаны Мөхәммәт I дә секретарь булып хезмәт иткән, соңыннан Аксак Тимернең биографы, Сарайда, Хаҗитарханда, Кырым һәм Харәземдә булган атаклы гарәп тарихчысы һәм язучысы Шиһабеттин ибне Гарәбшаһ: «Бу — төрле җәнлекләр һәм төрки кабиләләр белән тулган, һәрьяктан чикләнгән (сакланган.— *Р. Ф.*) һәм бар өлешләре дә эшкәртелә торган, бик киң, шифалы һавага һәм саф суга бай, чын мәгънәсендә татар җире. Аның кешеләре — чын ирләр, сугышчылары — менә дигән укчылар. Телләре ягыннан алар оста сүзле, иң матур телдә сөйләүче төркиләр».

Литваның бөек кенәзе Витаутас (Витовт) 1429 елда Ливон ордены магистрына язган хатында үзенең дусты һәм Кырымдагы күршесе Олы Мөхәммәтне Алтын Урданы үз кулында нык тотып торучы иң куәтле хан дип атый. Олы Мөхәммәттән элек бер үк вакытта Кырым һәм Әстерхан (Хаҗитархан) белән идарә иткән Дәүләтбирде хан да шул ук Витовтка Кефедән бер итальян сәүдәгәре язган хатта татар җиренең хуҗасы булган император дип атала. Ә бу вакытларда исә Сарайда, ягъни Урданың үзәк җирләрендә, аның туганы Гыязетдин хан булып утыра. Әлеге хан, шулай ук Дәүләтбирде, соңгарак Олы Мөхәммәт исемнәреннән Алтын Урданың төрле шәһәрләрендә көмеш акча сугыла, һәм бу акча дәүләтнең бөтен җиренә дә тарала. Мин, мәсәлән, 1972 елдан бирле инде Иске Казанны казыйм — ә ул Урдага буйсынган җирләрнең иң төньяк шәһәре булган — менә шунда әлеге өч хан исеменнән сугылган акчалар хәтсез табылды инде. Алар Сарайда, Хаҗитарханда, Болгарда (Болгар әл-Җәдид — Иске Казан) сугылганнар. Бу акчаларның шулай киң таралыш алуы әлеге дәүләт икътисадының (экономика) шактый тотрыклы булуы хакында сөйли.

Күрәсез, төрле тарихи чыганаклар буенча (урын аз булганлыктан, без аларның берничәсен генә атау белән чик-

ләндек), бөтен Алтын Урда җирләре бербөтен дәүләт, гомум сәяси, икътисади, мәдәни һәм этник дөнья булып күз алдына килә. Бу дәүләт таркалгач (ә аның чын сәбәпләрен әле ныклап торып өйрәнәсе бар), ул җирдә барлыкка килгән аерым татар дәүләтләре арасындагы сәяси һәм башка мөнәсәбәтләр элекке традиция рәвешендә шактый нык дәвам итә. Әмма алар инде бербөтен дәүләт булмыйлар. Әүвәлге бердәм территория бүленә, ул ханлыклар арасын XVI гасырда шактый үсешкә ирешкән рус дәүләте биләп ала башлый. Ә инде алар барысы да соңгысы тарафыннан берәм-берәм яулап алынгач һәм элеккеге татар дәүләтләре юкка чыккач, аларның халыклары арасындагы арадашлыкка, этник һәм мәдәни мөнәсәбәтләргә җитди зыян килә. Шактый соңрак, 1783 елда гына, яулап алынган Кырым ханлыгы үзенең якын күршесе Төркиягә йөз тота башлый. Кырымда төрек йогынтысы көчәя. Ике арадагы тел һәм мәдәни (архитектура, музыка һ. б.) якынлык нәкъ менә шушы XVII—XVIII йөзләрдә нык үсеп китә. Элек Алтын Урда, соңра Казан һәм Кырым ханлыклары чорында да, анда әле бик якын бер тел, бер этнос булса, хәзер инде телдәге аерма шактый сиздерә башлый, һәм көньяк угыз элементы көчәя, кырымтатар һәм казантатар телләренең беркадер аермалыгына китерә.

Кайберәүләр, Кырым татарларының теле Казан татарларыныкыннан бөтенләй аерым тел, дип әйтергә яраталар. Бу — ялгыш фикер! Алар икесе дә бер тел, башлыча XIV йөздә үк формалашкан төрки-татар теле. Әмма, әйткәнебезчә, мәгълүм сәбәпләр аркасында килеп чыккан бүлгәләнү, деконсолидация, җитмәсә икенче бер, тагын да көчлерәк һәм күп халыклы дәүләт йогынтысына эләгү тел һәм мәдәнияткә үзгәрешләр кертми калмый.

Ләкин кырымлылар (Кырымда яшәгәннәре!) төрекләр тарафыннан ассимиляцияләнмәделәр. Кырым татарлары төрекләр түгел, ә «татар» исемен йөртүче татарлар, әүвәлге татар ханлыгының, ягъни башка татар дәүләтләре белән янәшә яшәгән дәүләтнең халкы. Ни өчен элекке дүрт ханлыкның, ягъни Казан, Себер, Әстерхан, Касыйм дәүләтләренең халыклары булган казан, себер, әстерхан һәм касыйм татарлары бүген бер халык тәшкил итсен дә, ди, шул дәүләтләр белән бер үк нигездә, бер үк чорда барлыкка килгән һәм янәшә яшәгән бишенче татар ханлыгының гына халкы бөтенләй икенче бер халык булсын икән? Әле бит телдәге аермалык ике төрле халык булуын исбатламый. Хәтта ике телдә сөйләшүче, бер-берсен аңламаган бер үк халыкка мисалларны табып була. Мордваларны гына алыйк: бу халыкның ике этнографик төркеме,

ягъни эрзя белән мукшы бер-берсен бөтенләй аңламый, икесе өчен ике әдәби тел формалашкан, ике төрле гәзит чыга һ. б. Көчле консолидация-берләшүгә ия булган яһүдиләрне генә ал тагын: ивритлар белән идишлар бер-берсен аңлый алмый интегәләр.

Димәк, сөйләм теле, хәтта әдәби тел тәңгәл килмәү генә әле этник һәм мәдәни тарихы уртак булган бер халыкны икегә бүлә дигән сүз түгел. Казан татарлары кырым татарларын аңлый алмыйлар, дип әйтү дә шик тудыра. Мин кырымлылар арасында берничә көн булып, алар белән сөйләшеп йөрдем, шул ике-өч көн бер-беребезне аңлашу өчен житә язды.

Әлбәттә, бу ике этнографик төркем арасында телдән башка кайбер мәдәни аермалар да бар. Аларның XVII—XVIII йөзләрдәге деконсолидация, кырымлыларның Төркия йогынтысына эләгү нәтиҗәсе булганлыгы югарыда әйтеп үтелде. Антропологик яктан да бераз үзгәлек сизелә: бездә чуарлык күзгә ташлана — монда борынгы татарлар да (монгол түгел, ә төрки телле, VI йөздән билгеле булган «татар» исемле кабиләләр), болгарлар, кыпчаклар да, хәтта җирле фин, ягъни «ар-чирмеш»е дә бар. Ә Кырымда, башлыча, татар-кыпчак, ә Кара диңгез буенда яшәгәннәрендә угыз-төрек элементлары күренә. Андый аерманы бүгенге татар халкының башка төркемнәрендә дә табып була.

Әмма болар барысы да элементлар гына һәм алар һич кенә дә бөтен бер татар халкын — әле Алтын Урда чорында ук бер халык булып формалаша башлаган халыкны берничә этноска, аерым халыкларга бүлми.

Ниһаять, хөрмәтле укучыларның игътибарын тагын бер әйбергә юнәлтеп үтәсе килә. Соңгы 1989 елда үткәрелгән перепись, ягъни халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре буенча, кырым татарлары аерым күрсәтелгәннәр. Бу аларның соңгы елларда милли үзаңнарының нык үсеп китүе, туган җирләренә кире кайтып милли республикаларын торгызу теләге белән аңлатыла. Әмма элек бөтен татарлар да бер исем белән «татар» дип йөртелделәр. 1881 елда Россия мөселманнары, ягъни нигездә татарлар турында урысча язган «Русское мусульманство» исемле мәгълүм китабында Исмәгыйль бәй Гаспралы бөтен татарларны, шул исәптән кырымлыларны да «без — татарлар» дип атый. Әйе, илебезнең төрле җирләренә сибелеп яшәргә, хәтта чит илләргә таралырга мәҗбүр булсак та, без — бер халык, татарлар.

«Социалистик Татарстан»,
1991, 24 апрель.

АЛТЫН УРДА ҺӘМ ТАТАР ТАРИХЫ

...Тарихта «Җуҗи олысы» исеме белән мәгълүм Алтын Урда дәүләте бөтен Евразиядә урта гасырларның иң зур дәүләте, элеккеге күчмә һәм яңа шәһәр культурасының классик симбиоз-кушылмасын тәшкил иткән бай цивилизация үзәге булган. Дөнья сәясәтенең игътибар үзәгендә торуы, хәтта шул сәясәткә тәэсир итә алу көче ягыннан аны элегрәк яшәгән Габбасилар дәүләте (Багдад халифәлеге, 750—1258 еллар) белән генә чагыштырып булыр иде.

Әгәр дә Алтын Урданы төзүчеләр булып чыңгызлы монголлар саналса, дәүләтнең төп халкын элеккеге җирле, кардәш төрки кабиләләр—кыпчаклар, шулай ук болгарлар, маҗарлар, угызлар, хазарларның калдыклары һәм, безнең карашыбызча, Үзәк Азиядән күчеп килгән төрки телле татар кабиләләре тәшкил иткән. Аларның бер өлеше көнбатышка әле монгол яулары башланганчы ук күчеп килгәннәр, ә икенчеләре исә XIII йөзнең 20—40 нчы елларында Чыңгыз хан һәм Бату хан (Батый) житәкчелегендә Көнбатыш Себерне һәм Көнчыгыш Европаны яулап алу сугышларында катнашканнар.

Әгәр дә Алтын Урданың этник дөньясында башка төрки халыкларның булуы фәндә шик тудырмаса, монголлардан үзгә булган татарларның төркилеге мәсьәләсе төрле чорларда күптөрле бәхәсләр уятты. Үткән йөзләрнең күренекле урыс тарихчылары В. Татищев һәм Н. Карамзин монголларны һәм татарларны бер-берсеннән аерып карап, Алтын Урдада татарлар күбрәк булган дип язсалар, бүгенге совет тарихчыларының кайберләре шул борынгы татарларның Чыңгыз һәм Бату ханнар гаскәрләрендә булмаганлыгын һәм аларның, гомумән, хәзерге татар халкының этник тарихына бернинди катнашы юклыгын дәгъвалыйлар.

Бу бик тә мөһим, принципиаль мәсьәлә, чөнки аны хәл итүгә халкыбызның борынгы тарихының ифрат та житди фәнни проблемалары бәйле. Шуңа күрә илебезнең зур төрки халыкларыннан булган татар халкының аерылгысыз өлеше һәм аңа исем биргән борынгы татарларның тарихы белән танышып үтү бик тә зарури булыр. Нәкъ менә шул башлангыч тарих белән Алтын Урданың гомумтарихи мәсьәләләре, аларны бүгенге көн, яңача фикер йөртү таләпләреннән чыгып хәл итү аерылгысыз бәйләнгән.

Иң элек, хөрмәтле укучыларга Алтын Урданың үзе турында кыска гына белешмә биреп үтик. Алтын Урда — XIII йөзнең беренче яртысында төзелгән Монгол империясенең көнбатыш өлеше; ул көнчыгышта Иртеш елгасын-

нан — көнбатышта Дунай ярларына, төньякта Болгардан — көньякта Кавказның атаклы Дәрбәнд тарлавыгына хәтле булган бик зур территорияне биләп торган. Бу олуг дәүләт үзе ике зур олыска (өлкәгә) бүленеп, көнбатыштагы төп өлеше Ак Урда, ягъни Алтын Урда үзе, ә көнчыгыштагысы Күк Урда дип аталганнар — монысына Урта Азиядәге һәм Казахстандагы җирләр кергән. Бу бүленешнең нигезендә элек кыпчаклар белән угызлар арасында узган кабиләара чик ята. «Алтын Урда» сүзе бу дәүләт ханнарының «алтын чатыр»ларына нисбәтле аталган. «Алтын» һәм «ак» сүзләре ул чорларда синонимик, бер мәгънәне аңлаткан сүзләр дә булганнар. Атаклы «Идегәй» дастанында, мәсәлән, «Алтын Урда, Ак Урда» билгеләмәсе еш очрый. Шул ук дастанда һәм XIV йөздә Алтын Урдада, аның башкаласы Сарай шәһәрендә булган атаклы гарәп сәяхәтчесе Ибн Баттута язмаларында хан сарае «Алтын Таш» дип тә атала. «Урда» сүзе ханнарның күченеп йөргән чордагы ставка-резиденциясен яки шундагы хан чатырын аңлаткан. Бу исем соңгарак кайбер шәһәрләргә дә күчкән, мәсәлән, Урда әл Муаззәм, Урда әл Җәдид, Урда Базар дигән шәһәрләр булганлыгы билгеле. Алтын Урда гарәп-фарсы географик әдәбияты буенча Җуҗи олысы дип тә мәгълүм, ә ул билгеләмә Монгол империясен төзегән Чыңгыз ханның олы улы Җуҗи исеме белән бәйле. Чыңгыз үзенең улына көнбатыштагы әле яулап алынмаган, әмма алынырга тиешле җирләрне васыять итә һәм алар озакламый яуланалар да. Тик бу эшне Җуҗи үзе түгел (чөнки ул әтисе Чыңгыз белән бер елны — 1227 елда үлеп китә), ә аның улы, ягъни Чыңгыз ханның оныгы Бату башкара. Ул 1236—1240 елларда бөтен Көнчыгыш Европаны басып ала. Ике елдан соң, 1243 елның башында, Венгриядән яудан кайткач, Бату Идел буенда төпләнә һәм шунда яңа дәүләт — Алтын Урда дәүләтен төзи. Баштарак ул рәсми рәвештә Монгол империясенең бер өлеше санала, тик Бату хан тиздән мөстәкыйльлеккә ирешә, һәм ул төзегән яңа дәүләт бик нык көчәеп китә. Аның әтисе Җуҗиның, ягъни шул җирләргә Чыңгыз хан үзе хуҗа итеп билгеләгән кешенең исеме белән Алтын Урда шулай итеп Җуҗи олысы, аның ханнары җуҗилылар (чыңгызлыларның бер династиясе), ә алар исеменнән сугылган көмеш акча-дирһәмнәр җуҗи акчалары дип тә аталалар. Ниһаять Алтын Урданың рәсми булмаган, әмма шул заманнарда шактый киң таралган тагын бер исеме бар — ул «Дәшти Кыпчак» (Кыпчак даласы); дәүләтнең үзәк җирләре элекке кыпчак далаларын биләп торган, шуңа нисбәтле шулай аталган да.

Әйтелгәнчә, Алтын Урда 1243 елның башында төзелә һәм шул тарихи вакыйгага 1993 елның башында 750 ел тула.

Менә шушы Алтын Урда дәүләтен төзүдә катнашкан, алай гына да түгел, аның төп халыкларыннан булган татарларның борынгы тарихы белән танышып китик. «Татар» исемле төрки кабиләләр Көньяк Себер һәм Үзәк Азия җирләрен биләп торган Көнчыгыш Төрки каханлыгының башлыклары, яки каханнары (бөек ханнары) истәлегенә куелган язулы ташлар буенча VI гасырдан ук мәгълүм. Мәсәлән, Истәми кахан һәм Бумын каханны искә алу мәҗлесенә җыелганнар арасында «Утуз татар» (утыз татар) вәкилләре дә булган. Бу татарлар Билге каханның әтисе Илтәрис кахан җитәкчелегендәге тю-гю кабиләләренә каршы сугышканнар. Билге кахан үзе «Тукуз татар» (тугыз татар) кабиләләре белән орышкан, ә алар угызлар белән берлектә булганнар. Димәк, шул чорның көчле кабиләләре белән сугышлар алып барган төрки телле татарлар шактый куәтле берләшмәләр булганнар. «Утыз» һәм «тугыз» саннарының зур төрки-татар берлегендәге кабиләләр саны булганлыгы шик тудырмый. Борынгы татарлар IX—X йөзләрнең Кытай чыганакларында да искә алыналар, кытайлар аларны «та-тань», күбрәк «да-да» дип атаганнар.

Менә шушы татарларның бер өлеше көнбатышка күчеп китә — алар X—XI йөзләрнең кайбер чыганакларында телгә алыналар. 985 елда төзелгән «Хөдүд әл галәм» (Дөнья чикләре) исемле атаклы фарсы язмасында, мәсәлән, татарлар Төрки каханлыгы җимерелгәннән соң төзелгән Караханилар дәүләтендә итеп күрсәтелә. XI гасырда яшәгән мәгълүм уйгыр язучысы һәм тел галиме Мәхмүт Кашгари үзенең мәшһүр сүзлегендә 20 төрки кабилә арасында татарларны да атый, ә шул ук йөзнең фарсы галиме әл-Гардизи үзенең «Зайн әл әхбәр» (Хәбәрләрнең күрке) исемле тарих китабында татар кабиләләре берлегеннән булган кешеләрнең Кимәк каханлыгын төзүдә хәлиткеч урын тотканнары турында хәбәр китерә. Ул да мәгълүм булсын: кимәкләр — VIII—X йөзләрдә Көнбатыш Себердә, Иртеш елгасы буйларында яшәгән һәм, әйткәнемчә, каханлык төзегән зур төрки кабиләләр, аларның көнбатыш өлеше кыпчаклар исемендә мәгълүм. Күрәсез, татарлар белән кыпчаклар шул вакытларда ук инде бик нык аралашкан булганнар, дөресрәге, алар кардәш кавем булып зур дәүләт тотканнар. Башка кайбер чыганаклар, мәсәлән, урыс елъязмалары, шулай ук XVII йөз Хива ханы һәм тарихчысы Әбелгазый туплаган мәгълүматлар буенча да, татар-

ларның әле монгол яуларына кадәр үк Көнчыгыш Европада булганлыгы билгеле.

Борынгы татарларның югарыда санап үтелгән тарихи чыганаклар буенча таныш булган көнбатыш төркеменең якынча булса да саннарын атау, Көнчыгыш Европа халыкларының шул чор тарихында тоткан урынын төгәл билгеләү әлегә мөмкин түгел, әмма ышанычлы итеп шуны әйтергә була: шул борынгы татарлар тора-бара, башка кардәш төрки кабиләләр белән берлектә, Алтын Урда дәүләтендә барган тарихи-этник процесста турыдан-туры катнашканнар.

Әмма татарларның тарихта шактый зур эз калдырган дәвере—аларның элеккеге үз җирләрендә, ягъни Көньяк Себер һәм Үзәк Азия далаларында монголлар белән күрше булып яшәп, Монгол дәүләтен төзүдә катнашу чоры. Монголлар һәм аларның көньяк-көнчыгыш күршеләре булган татарлар хакында кыйммәтле хәбәрләр тупланган XIII—XVII йөз монгол, кытай, фарсы һәм гарәп тарихи чыганакларын җентекләп тикшергәннән соң, татарларның, монголлардан үзгә, төрки телле кабиләләр булганлыгына һич шик калмый. Хәтта кайбер хәбәрләрнең каршылыклы булуларына да карамастан, төрки татарларының тарихы монгол һәм аларга кардәш кабиләләр, мәсәлән, кэрэитлар, меркитләр, ойротлар, найманнардан бик нык аерылып тора. XIII гасырның «Мэн-да бэй-лу» (Монгол-татарларның тулы тасвирламасы) исемле кытай хроникасында татарлар «аерым ша-то ыруыннан» диелә. Ша-то кабиләләре—VII йөздә хәзерге Фирганә җирләрендә яшәгән көнбатыш төрки кабиләләр. VIII—X йөзләрдә алар бүгенге Кытайның төньягына, Ганьсю һәм Шаньсю провинцияләренә күченеп китәләр.

Шик юк, ша-то кабиләләреннән чыгучы әлеге татарлар заманында көнбатышка, ягъни Көнбатыш Себергә һәм Көнчыгыш Европага киткән татарлардан (алар хакында югарыда сөйләнде) көнчыгышта, Үзәк Азиядә калган татар кабиләләре булганнар. Кытай чыганаклары аларны «ак татарлар»—«бай да-да» дип атыйлар, кайберләрендә «онгутлар» исеме белән дә мәгълүм (монгол истәлекләрендә—чаган татарлар). Урта гасырларның бөек фарсы тарихчысы Рәшидетдин (XIV йөз) онгутларны төркиләр дип әйтә. Кытай чыганакларын бик җентекләп өйрәнгән Рәсәй тарихчысы П. Кафаров (Палладий, XIX гасыр) һәм совет галиме Н. Мункуев шундый ук фикердә торалар. Ак татарлар хакында беренче тарихи хәбәрләрне биргән «Мэн-да бэй-лу» авторы аларның тышкы кыяфәтенә һәм холыкларына да игътибар иткән: «Ак татарлар дип аталучы

татарларның буй-сыннары зифа, үзләре әдәпле һәм ата-аналарын ихтирам итәләр».

Әлеге хроникада, алардан башка, кыргый татарлар (шэн да-да) һәм кара татарлар (хэй да-да) турында да языла, боларына Чыңгыз хан, аның барлык полководецлары, министрлары, сановниклары керә. Бу «татарлар», ягъни монголлар «җәлпәк битле, киң яңаклылар. Күзләренең өске керфекләре юк. Сакаллары бик сирәк, тышкы кыяфәтләре шактый ямьсез». Кыскасы, монда антропологик яктан да бер-берсеннән нык аерылып торган төрле кабиләләр хакында сүз бара (шул ук вакытта Чыңгыз ханның, башка монголлардан — кара һәм кыргый «татар-лар»дан — үзгә буларак, зур һәм мәһабәт гәүдәле, киң маңгайлы, озын сакаллы булуы да әйтелә; аның әнисенең татар булганлыгы хакында да кайбер хәбәрләр йөри). Ә инде «Мэн-да бэй-лу» авторының монголларны да «татар-лар» дип атавын әлеге язманы тәрҗемә итеп һәм шәрехләп бастырган Н. Мункуев болай аңлата: чын татарлар белән беренче кат очрашкан кытайлар «татар» исемен аларның төньяк күршеләре булган монголларга карата да кулланганнар. Мәгълүм ки, татарлар кытайлар белән монголлар арасындагы җирдә яшәгәннәр.

Монголларның һәм аларның күршеләре белән татарларның тарихы «Мэн-да бэй-лу»дан башка кайбер бүтән атаклы тарихи чыганакларда да яктыртылган, шулардан: «Монгол ун-ниуча тобчаган» («Монголларның яшерен тарихы»; урыс тарих фәнендә «Сокровенное сказание» дип тә мәгълүм) исемле XIII йөз монгол язмасы; Рәшидетдиннең «Җәмигъ әт тәварих» (Елъязмалар җыентыгы) исемле универсаль хезмәте һәм XVII йөздә төзелгән «Алтан тобчи» (Алтын риваять) дигән монгол елъязмасы. Әлбәттә, шушы чыганакларда шактый тулы тасвирланган татар һәм монгол тарихына җентекләп тукталу бер мәкаләдә генә һич мөмкин түгел. Ике арадагы ул дошманлык татарлар Чыңгызның әтисе Есүгәй баһадурны үтергәч (ә Есүгәй татарларның юлбашчысын әсир иткән була) көчәеп китә. Шул вакыт Чыңгыз хан татарларны кырып бетерергә әмер бирә. 1198 елгы зур сугышта татарлар җиңелсәләр дә, кырылып бетмиләр, дүрт зур кабилә тәшкил итәләр: чаган татар (алар хакында югарыда әйтелде инде, ягъни онгутлар — ак татарлар), алчы татар, дутаут татар һәм алухай татар. Рәшидетдин хәбәр иткәнчә, 1202 елдагы сугышта кабат җиңелгәч, күп кенә татарлар көнбатышка китәләр — күрәсең, алар бу якларга күчкәләп торганнар. Татарларны кырып бетерү турында Чыңгыз тагын бер әмер бирә, тик монысы да өлешчә генә үтәлә. Дөрес, Чыңгыз ханның

шовинистик сәясәте нәтиҗәсендә аларның бер өлеше юк ителгән, күпмедер өлеше чит җирләргә киткән, беркадәресе монголлар тарафыннан ассимиляцияләнгән, йотылган. Әгәр дә Рәшидетдин шундый йотылу хакында язган икән, ул иң әүвәл монголлар белән янәшә яшәп, алар белән даими мөнәсәбәттә булган татар кабиләләрен күз алдында тоткан. Аның үзенең үк икенче бер урында язуынча, татарлар бик күп санлы булганнар. Ул 14 төрки кабиләне атый, шуларның иң зурысы татарлар иде, алар 70 мең гаиләдән тордылар, ди. «Аларның гадәттән тыш бөеклеге һәм дәрәҗәле булулары аркасында, башка кабиләләр, төрләренен һәм исемнәренең аерымлыкларына карамастан, шул исем астына берләштеләр һәм татарлар дип атала башладылар»,— дип бәя бирә бөек тарихчы борынгы татарларга.

Шуңа күрә, йотылу ике яклы булган, дип уйларга да урын бар. Ул чор монголларның телендәге төрки сүзләр, һичшиксез, татарлардан кергән. Шунысын да әйтеп үтик: Чыңгыз хан үзе дә татарча белгән, ул хакта фарсы чыганакларында бик ышанычлы хәбәрләр бар. Әмма татарларга булган элекке дошманлыкны ул бервакытта да онытмаган һәм үзенең киң күләмдә яулап алу сугышларын башлагач, аларны беренче итеп, көчләп сугышка кертә торган булган. Бу хакта шул заман вакыйгаларын үз күзләре белән күргән Европа сәяхәтчеләре бик ачык язалар.

Яуда алдан килгән сугышчыларның исеме, ягъни «татар» сүзнең ничек итеп бөтен монгол гаскәре өчен гомуми исемгә әйләнеп китүе турында, миңа калса, бераз берьяклырак язылды. Тарихи әдәбиятта шулай ук XIV йөз гарәп тарихчысы әл-Гомәринең көнчыгыштан килгән татарларның җирле кыпчаклар тарафыннан ассимиляцияләнүе турындагы сүзләренә дә күп игътибар ителде. Ләкин шунысы мөһим, әл-Гомәри татарлар турында гына түгел, монголлар хакында да яза. XIII гасырның Көнбатыш Европа сәяхәтче-миссионерлары Рубрук һәм Плано Карпини татарларның һәм монголларның төрле кабилә булганлыкларын искәртәләр. Бу уңайдан Рубрукның язмалары бигрәк тә әһәмиятле. Монгол империясенең Чыңгыздан соң булган бөек ханы Мэнгу кахан һәм Алтын Урда ханы Бату, аларның якыннары белән очрашып сөйләшкән бу галим-сәяхәтче: «Алар татарлар дип аталырга теләмиләр, чөнки татарлар башка халык, ә үзләрен маоллар, ягъни монголлар дип атыйлар»,— ди.

Алтын Урдада татарларның монголларга караганда күбрәк булганлыгы хакында В. Татищев һәм Н. Карамзин фикерләре югарыда әйтелде. Бу фикерләрне революциягә кадәрге урыс археологы, востоковед Н. Веселовский, биг-

рәк тә безнең заманның татар тарихчысы М. Сәфәргалиев шактый дәлилле итеп яклап чыктылар. Мәгълүм ки, Чыңгыз хан көнбатыш җирләрне яулап алу өчен Җуҗига бары тик 4 меңлек монгол гаскәре бирә, һәм ул гаскәр, Җуҗи үлгәч, аның улы Батуга кала. Дөрес, соңгарак, 1235 елда үткәрелгән монгол корылтаенда Европаны басып алу карары кабул ителгәч, Бату армиясе бик нык көчәйтелә һәм аңа монголларның күп санлы, иң яхшы сугышчылары бирелә. 1238 елда ул вакыйгаларны үз күзләре белән күргән сәяхәтче, венгр монахы Юлиан язып калдырган хәбәрләргә караганда, аларның саны 135 мең тәшкил иткән. Ә аның замандашы Сентковский мәгълүматларыннан күренгәнчә, бу сан хәтта 160 меңгә җиткән. Әмма бу зур саннар монголларның Көнчыгыш Европаны басып алу чорына, ягъни 1236—1240 елларга гына карый. Ул сугышлар тәмам булгач, монголларның төп өлеше кире үз илләренә, ягъни Үзәк Монголиягә кайтып китәләр, ә Алтын Урдада аз санлы монгол элитасы һәм алардан чагыштыргысыз күп татарлар һәм башка кабиләләр кала.

Шулай итеп, VI йөздән үк инде эпиграфик истәлекләр һәм тарихи чыганаклар буенча мәгълүм булган татарлар монголлардан үзгә халык булганнар. Алар соңга таба да, мәсәлән, Монгол дәүләте төзелгән чорларда, монголлардан нык аерылып торганнар. Бу аермалык 1220—1240 еллардагы дәһшәтле яулар вакытында һәм Алтын Урда дәүләте төзелгән заманда да үзен гел сиздереп, алай гына да түгел, монголлар белән татарлар арасындагы элеккеге дошманлык аларны бер-берсеннән аерып торган. Аз санлы монгол аристократиясе — ханнар һәм аларның якыннары, дәүләт эшлеклеләре, гаскәр башлыклары, башка югары катлам — шактый тиз арада төрки халык, ягъни кыпчаклар, татарлар һ. б. арасында сеңеп, йотылып беткән.

Әйтик, Бату һәм аның энесе Бәркә ханнар әле монгол булсалар, алар нәселеннән килгән, 1312—1342 елларда идарә иткән, Алтын Урданың иң куәтле вә данлыклы ханы булган Үзбәк инде төркиләшкән, татар ханы. Җуҗи олысының башлангыч чорында — XIII йөзнең икенче яртысында — монгол теле рәсми тел, бигрәк тә дәүләтара мөнәсәбәтләр теле булып саналса, шуннан соңгы чорда, XIV гасырда, ягъни Алтын Урданың нык үсешкә ирешкән заманында, ул тел юкка чыга. Бу чорда аның сөйләм һәм әдәби теле генә түгел, хәтта рәсми дәүләт теле дә — төрки, ягъни кыпчак-татар теле. Бу хакта шул заманнан калган язма истәлекләр — «Коман мәҗмугасы» исемле атаклы лөгать һәм башка кайбер сүзлекләр, XIV йөз татар әдәбиятының үлемсез әсәрләре, шул ук чорның Алтын Урда

хакында язган гарәп-фарсы географларының һәм тарихчыларының әсәрләре, ниһаять, Туктамыш һәм Тимеркотлык ярлыклары бик тә ачык, дәлилле итеп сөйлиләр.

Ә инде татарларны корал тоттырып, монгол яуларына көчләп кертканнәр икән, бу — гадәти бер әйбер. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, монгол гаскәрендә, татарлардан башка, бүтән халыклар, мәсәлән, кыпчаклар, мажарлар, чиркәсләр, хәтта урыслар да булган. Әйе, әйе, нәкъ менә урыслар; кайбер чыганакларда алар хәтта беренче булып телгә алыналар. Бүген шулай дип әйтергә яраталар: Иван Грозный өчен хәзерге урыс халкы, Гитлер өчен немецлар җавап бирми. Соң, шулай булгач, Чыңгыз һәм Бату, җитмәсә, чит кавемнән булган ханнар өчен бүгенге татарлар җавап бирергә тиешме? Әлбәттә, юк!

Борынгы татарлар турында сүз алып барганда аларның кыпчаклар белән кан кардәш булганлыкларына басым ясап үтми һич мөмкин түгел. Ул ике кардәш халык төрки телләрнең төньяк төркеменә кергәннәр. Бу этник якынлык әле борынгы Кимәк каханлыгы чорыннан ук мәгълүм, ул хакта югарыда әйтелде инде. Һәм юкка гына татарлар соңыннан, 1223 елда, Төньяк Кавказ киңлекләрендә берләшкән алан-кыпчак гаскәре белән очрашкач, кыпчаклардан аланнарны ташлап китүләрен сорамыйлар: «Без һәм сез бер ырудан, ә аланнар сезнекеләр түгел» — менә бу сүзләрне шул елларда иҗат иткән күренекле гарәп тарихчысы Ибн әл-Әсир язып калдырган.

Сүз уңаеннан шуны әйтеп үтик, бу тарихчы татарларны төрки кабиләләр дип атый: «...ислам илләренә зур төрки кабилә булган татарлар килеп керделәр, алар Кытай ягындагы Тамгач тауларында яшәгәннәр». Бу хәбәр без югарыда татарлар турында танышып үткән кытай, монгол һәм Рәшидетдин язмалары белән аваздаш (Тамгач таулары турындагысы гына яңа хәбәр). Рәшидетдин димәктән, ул татар тарихы белән даими кызыксынган; татарларның кыпчаклар белән туганлыгы турындагы тарихи сүзләр аның кулъязмасына да теркәлгән: «Без һәм сез — бер халык һәм бер кабиләдән, ә аланнар безгә ят кешеләр». Бу сүзләр беркадәр демагогик калыпка салынып бирелсә дә, алар татарлар белән кыпчакларның нәкъ менә кардәш, бик тә якын халыклар булганлыгын чагылдыра. Татарлар монда кыпчакларның туганлык хисләреннән бик оста файдаланганнар.

Әгәр дә Алтын Урданың этник дөньясы ул дәүләт яшәешенең беренче чорында (XIII йөзнең икенче — XIV йөзнең беренче яртысы) әле күбрәк «кыпчаклар» дип һәм алар яшәгән җирләр элеккеге гадәт буенча «Дәшти Кып-

чак» дип аталсалар, аннан соңгы дәвердә бу инде — татар дөньясы: «татар җире», «татарлар», «татар ханнары», «татар гаскәре», «татар теле», хәтта «татар дине». Җитмәсә, ул җирдәге халыкның татарлар икәнлегенә күп санлы тарихи чыганакларда басым ясап әйтелә.

Менә шушы борын-борыннан халык исеме булган «татар» сүзен кайберәүләр «политик атама» гына дип әйтергә ярата; имеш, «татар» сүзе ул — ясалма бер исем, урыслар тарафыннан безнең халыкка тагылган чит бер атама гына. Бу — уйдырма, ялган! Бик тә ышанычлы, беренчел тарихи чыганаклар буенча инде VI йөздән үк этноним, ягъни тулы бер халыкның үзатамасы буларак мәгълүм булган «татар» исеменә урысның һич кенә дә катнашы юк һәм ул вакытта татарлар яшәгән җирдә урыс бөтенләй булмаган. Андагы, ягъни Үзәк Азиядәге мәшһүр тарихи вакыйгалар, шул дөньяның төрки кабиләләр тарихы урыс чыганакларында бервакытта да чагылыш тапмаган. «Татар»ның борынборыннан төрки халык исеме булганлыгын инкарь итәргә маташучылар — әлеге кабилә-халыклар чорын һәм аннан соңгарак та булган татар тарихын, ягъни Болгар, Алтын Урда дәверләрен өйрәнүгә бернинди дә катнашлары булмаган, шуңа күрә аны юньләп белмәгән, компетентсыз кешеләр. Болар халкыбызның тарих биргән газиз исемен, «татар» исемен сүгеп, аны икенчегә — «болгар»га алыштырырга дип кеше котыртып, шулай итеп, чынында татар халкын бүлгәләргә, санын киметергә тырышып, аның бөтенлегенә, бердәмлегенә әйтеп бирә алмаслык зыян эшләп йөрүчеләр!

Мин башта ук әйттем: бер мәкаләдә генә Алтын Урда кебек зур дәүләт тарихын яктырту һич мөмкин булмаган хәл, дидем, шуңа күрә бу язмада ул тарихның кайбер якларына гына, иң әүвәл этник тарихка беркадәр игътибар ителде. Күп мәсьәләләр белән беррәттән мине Алтын Урданың дәүләт буларак яшәүдән туктавы, таркалу сәбәпләре борчый. Бик тә катлаулы, буталчык мәсьәлә. Кайчан да булса ачыкланыр, әлегә исә минем шуңа иманым камил: әгәр дә шушы олуг дәүләт таркалмаган булса, бүген аерым этнографик төркемнәргә бүленмәгән, чын мәгънәсендә бердәм татар халкы барлыкка килгән булыр иде. Алтын Урданың таркалуы XV йөз башларында татар халкының формалашып бетүенә комачаулый һәм ул тарихиэтник процесс шул зур җирлектә барлыкка килгән аерым татар дәүләтләре — Казан, Кырым, Себер, Әстерхан, Касыйм ханлыклары чорында тәмамлана. Объектив тарихи сәбәпләр аркасында бүген этнографик төркемнәр дип аталучы, шул дәүләтләрнең исемнәре ябышып калган, бер-

кадәр тел һәм мәдәни үзенчәлекләре дә булган аерым этно-географик төркемнәр барлыкка килә. Әмма алар барысы да бер халык — «татар» исемен йөртүче татар халкы, ә бу исем, ягъни борынгы татарларның этнонимы, бөтен татар халкын берләштерүче ныклы нигезгә әйләнә. Алтын Урда яшәешенең соңгы чоры, аннан соң барлыкка килгән татар дәүләтләре, иң әүвәл, Казан һәм Кырым ханлыклары арасындагы тыгыз сәяси һәм этник мөнәсәбәтләр, консолидация һәм вакытлыча деконсолидация мәсьәләләре хакында мин «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Без — бер халык» дигән мәкаләмдә (1991, 24 апрель) язган идем. Кызыксынган укучылар бу мәкаләгә кабат мөрәҗәгать итә алалар. Монда шуны гына өстәп, ассызыклап үтик: Алтын Урда ул — татар халкының урта гасырлардагы гомуми дәүләте, соңыннан шул җирлектә барлыкка килгән аерым татар халыкларының уртак нигезе.

Һәм менә татар халкы илле елга якын инде үзенең шул олуг дәүләтенең тарихыннан мәхрүм булып яши. Моның сәбәбе ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августында кабул ителгән «Татарстан партия оешмасында массаполитик һәм идеология эшенең торышы һәм аны яхшырту чаралары турында» дигән карары, шул карар белән татар халкының тарихында һәм мәдәниятендә Алтын Урданың ролен юкка чыгарып, куркытып кую булды. Бу карар шуннан соң кабул ителгән башка карарларга да, мәсәлән, СССР Фәннәр академиясенең ул вакыттагы Тарих һәм философия бүлеге, ВКП(б)ның Татарстан һәм Кырым өлкә комитетлары кабул иткән башка карарларга да күрсәтмә булды, ә алар барысы да Алтын Урданы татар тарихында искиткеч тискәре роль уйнаган бер дәүләт дип бәяләделәр. Шуннан соң үткән ярты гасыр дәверендә Алтын Урда тарихы Татарстанда бикле көе торды. Бу тарих буенча фәнни монографияләр, махсус мәкаләләр басылмады диярлек (Казан университеты профессоры М. Госмановның Җуҗи олысының ярлыклары хакында соңгы елларда дөнья күргән китабыннан гайре). Бу тарихны өйрәнү Г. Ибраһимов исемендәге институтның эш планнарына кертелмәде, аның буенча бер генә аспирант та әзерләнмәде, диссертация язылмады. «Татарстан АССР тарихы»ның берничә чыгарылышында да «Алтын Урда» сүзе Болгар дәүләтенең бер чорын бәяләү өчен генә кулланылды, анда да Алтын Урдага карата тискәре караш хөкем сөрде. Югарыдан булган күрсәтмәләргә таянып һәм үзәктә чыгарылган хезмәтләргә ияреп, «Урда игосы», «татар-монгол игосы» дигән мәгънәсез сүзләр күп язылды. Бу эшләр, әлеге дә баягы, шул 1944 елгы карар яктылыгында эшләнде. Хәер,

эш әлеге карарда гына да түгелдер. Болар һәммәсе дә аңа хәтле үк алып барылган совет тоталитар идеологиясенең, берничә гасыр дәвам иткән урыс хакимиятенең империячел фикер йөртүенең «җимешләре» иде.

Алтын Урданың бай шәһәр мәдәнияте, шул шәһәрләрдә гаҗәеп зур үсешкә ирешкән һөнәрчелек: архитектура-төзелеш, ювелир сәнгате, металлургия, корал эшләү, пыяла өрү, затлы савыт-саба җитештерү, таш кисү, сөяк эшкәртү һ. б., шул һөнәрчелектән калган бихисап күп матди культура калдыклары моңарчы татар халкының традицион мәдәнияте белән чагыштырып өйрәнелмәде. Сарай һәм башка шәһәрләрне казыган Мәскәү-Ленинград археологлары ул истәлекләргә татар халкының этник тарихы күзлегеннән чыгып якын килмәделәр, ә Казанда исә Алтын Урда мәдәнияте, әйткәнемчә, ябык тема булып кала бирде. Дистә еллар дәвамында игътибар үзәгендә бары тик болгар матди культурасы булды һәм бары тик шул халәттән чыгып кына татар этногенезын хәл итәргә тырышылды. Алтын Урдага, аның цивилизациясенә йөз белән борылырга, шул бай мәдәниятне Урда җирлегендә барлыкка килгән татар ханлыкларының (Казан, Кырым, Себер һ. б.) тарихи-мәдәни мирасы белән чагыштырып өйрәнергә вакыт җитте генә түгел, ул зарурат безне бүген стенага китереп терәде. XX гасыр үтеп бара, һәм вакыт безне моңарчы булган хаталарны төзәтергә, газиз халкыбызның борынгы һәм урта гасыр тарихын өйрәнүдәге беръяклылыктан, стереотип фикер йөртүдән арынырга чакыра. Чакыра гына түгел, ул безне киләчәк буыннар алдында бүтән ялгышлар ясамаска мәҗбүр итә.

Әлбәттә, татар халкы яшәгән зур җирнең әле Алтын Урдага хәтле үк туган үзенчәлекле һәм бай мәдәни үзәкләре булган. Шундыйларның берсе — X—XIII йөз башларында яшәгән һәм күпләргә мәгълүм Болгар дәүләте. Болгар мәдәнияте — казан татарлары мәдәниятенең, ә болгарлар үзләре — казан татарлары этногенезының тотрыклы нигезләренең берсе. Әмма шушы ук казан татарларының халык буларак формалашуында башка төрки халыклар — борынгы татарлар, кыпчаклар, нугайлар, хәтта угро-фин кабиләләре дә катнашканнар.

Бөтен Болгар җирен аркылыга-буйга дигәндәй йөреп чыккан археолог, Болгарның күп санлы археологик истәлекләре, аның бай һәм кызыклы тарихы турында фәнни монографияләр, мәкаләләр язган галим буларак, ул тарих миңа бик якын, кадерле. Ул хакта язганнарым — минем фәнни намусым, һәм ул хезмәтләремнән мин, әлбәттә, һич кенә дә ваз кичәргә җыенмыйм. Ләкин шул ук вакытта

кайбер фикерләр искерделәр дә. Бу бик тә табигый хәл, чөнки елдан-ел бай, хәтта өр-яңа археологик мәгълүматлар туплана, матди культура һәм аңа бәйле борынгы рухи мәдәният хакында безнең карашларыбыз байый, хәтта үзгәрә. Шөбһәсез, без үзебез дә үзгәрәбез. Сталинның казарма социализмы, тоталитар режим идеологиясеннән котыла, коллык психологиясеннән, буйсынучанлык һәм курку философиясеннән арына барып үзгәрәбез. Моңарчы каһәрләнгән чын тарихыбызны күтәрү, аны бүгенге һәм киләчәк буыннарга дөрес итеп җиткерү халәтен аңлап үзгәрәбез. Уяну килде, күп нәрсәләргә күзебез ачылды.

Болгар тарихы — татар халкының урта гасырлар тарихының бер өлеше ул. Күп җирләрдә тупланып яшәүче бөтен татар халкының дүрттән өч өлеше Татарстаннан, ә өчтән ике өлеше Урта Иделдән читтә яши. Бу дөреслек тарихчылардан һәм башка гыйлем ияләреннән халкыбызның барлык этнографик төркемнәренең, моңарчы игътибардан читтә кала биргән милләттәшләребезнең үткәнен, тел һәм мәдәни тарихын бер үк дәрәҗәдә тигез өйрәнүне таләп итә. Нәкъ менә шул зарурлыктан чыгып, бөтен татарның урта гасырлардагы гомум дәүләте булган Алтын Урда тарихын, аннан соң барлыкка килгән аерым татар дәүләтләренең тарихларын ачу бик тә мөһим бурыч булып килеп баса.

Алтын Урда — бөтен татар халкы бердәмлегенең, бәйсезлегенең, суверенлыгының чын тарихи нигезе ул!

«Социалистик Татарстан»,
1991, 30, 31 август, 3 сентябрь.

БЕРДӘМЛЕКТӘ — КӨЧ

Бергәнеке берәгәйле
Себер татарлары мәкале

Телләре ягыннан татар теленең көнчыгыш диалектын тәшкил итүче Себер татарлары халкыбызның мәгълүм этнографик төркемнәреннән санала. 1989 елгы Бөтенсоюз халык исәбен алу нәтиҗәләре буенча, Көнбатыш Себердә, ягъни элек Себер ханлыгы урнашкан җирдә, 391 мең татар яши. Дөрес, алар арасында Идел-Урал якларыннан күченеп килгән татарлар да бар. Әмма күрсәтелгән санның күпчелек өлешен Себер татарлары үзләре тәшкил итәләр, дип уйларга кирәк.

Үткән йөзнең мәшһүр востоковед-тюркологы һәм этнографы академик В. Радлов Себер татарларының телләре

ягыннан ике төп төркемгә — Бараба татарларына һәм Иртеш (яки Иртеш-Табул) татарларына бүленгәнлеген язган иде. Әгәр дә Бараба диалекты төрки телнең көнчыгыш тармагына нисбәтле, мәсәлән, алтайлар, уйгурлар теленә якын булса, халыкның күпчелеген тәшкил иткән Иртеш-Табул татарлары көнбатыш, ягъни кыпчак төркеменә керәләр. Шуннан соңгы булган лингвистик һәм этнографик әдәбиятта нигездә шушы бүленеш саклана. Хәер, кайбер галимнәр, аларга өстәп, Томск татарлары барлыгын да әйтәләр.

Бөтен Евразиянең зур вә кодрәтле дәүләте булган Алтын Урда XV гасыр башында әлегә тәмам мәгълүм булмаган сәбәпләр аркасында таркалу чорына керә. Бу таркалуны татарның бөек тарихи шәхесе, бәкләри бәк һәм атаклы полководец Идегәй вакытлыча туктатып тора һәм дәүләтнең әүвәлге көч-куәтен шактый торгыза. Тик ул 1419 елда Җаек буенда үзенең дошманы Кадыйрбирде белән сугышта һәлак була. Көнчыгыш олыслар (өлкәләр) белән идарә итү өчен Идегәй тарафыннан хан итеп куелган Дәрвиш тә шул ук елда үлә, һәм тәхеткә Шибаннар нәселеннән булган Хаҗимөхәммәт утыра. Ул да мәгълүм булсын: Шибан хан ул — Бату ханның (Батыйның) туганы. Аларның бабалары — Чыңгыз хан үлгәч, элек ул төзегән Монгол империясе берничә кисәккә бүленә. Көнбатыш җирләрдә мөстәкыйль Алтын Урда дәүләте төзелеп, аның белән Бату идарә итә башлый. Шул ук вакытта ул аерым олысларга үзенең туганнарын утырта. Мәсәлән, Көнбатыш Себерне Урда-Иченга һәм Шибанга бүлеп бирә — соңгысы Урал белән Иртеш арасындагы җирләргә хуҗа була. Һәм менә шушы Шибаннан булачак Себер ханнарының нәсел очы башлана. Югарыда телгә алынган Хаҗимөхәммәт — Шибанның сигезенче, инде татарлашкан буын оныгы.

Әлбәттә, Хаҗимөхәммәт яңа дәүләткә нигез сала, аның ханнарының нәселен башлап җибәрә. Әмма Себердәге бөтен татар җирләрен чынлап бер дәүләткә берләштергән кеше аның улы Мәхмүтәк була. Ул, 1429 елда әтисе шул ук шибаннар нәселеннән булган Әбелхәер атлы бер ханзадә тарафыннан үтерелгәч, хан дип игълан ителә. Шул рәвешчә, Себер ханлыгы Алтын Урда тәмам таркалгач, аның җирләрендә барлыкка килгән аерым татар ханлыкларының беренчесе була. Аннан соң башка ханлыклар оеша башлый. 1433 елда Кырым ханлыгы, 1445 елда Казан ханлыгы, 1450 еллар башында Касыйм һәм 1459 елда Әстерхан ханлыклары оеша. Әлбәттә, монда шул ук Алтын Урда җирендә 1420—1430 елларда барлыкка килгән тагын бер мөстәкыйль дәүләт берәмлеген — Нугай Урда-



Себер ханнарының тажы. Мәскәүнең Дәүләт кораллар палатасында саклана

сын да онытырга ярамый. Аның халкы да нигездә татарлар — нугай татарлары.

Себер ханлыгының башлангыч чорында ул биләгән җирләр турында төгәл мәгълүматлар булмаса да, дәүләт яшәешенең соңгы дәверендәге, ягъни Ермак яулары вакытындагы мәйданы зур булган. Аңа электәге Шибан олысы һәм аннан көнчыгыштагы Урда-Ичен олысының да күп кенә җирләре кергән. Ханлык көнбатышта Урал таулары һәм түбән таба Урал елгасы буйлап Казан ханлыгы һәм Нугай Урдасы белән чикләнгән. Төньяктагы җирләре Обь елгасының тамагына хәтле барып җиткән, көнчыгышта һәм көньякта шул ук Обьнең урта агымы һәм Бараба далалары җәелеп киткән. Шушы җирдә, татарлардан башка, бигрәк тә төньякта, җирле остяк һәм вогул кабиләләре дә яшәгән.

Әле 1270 елларда ук Кытайга сәяхәте вакытында Көньяк Себердә, Бараба далаларында булган атаклы итальян сәяхәтчесе Марко Поло язмаларына караганда, ул җирләрнең төрки халкы, ягъни бүгенге татарларның бабалары,

күпләп терлек — ат, сыер, сарык вә дөя — асраганнар, яраткан азыклары сыер ите һәм сөт булган. Төньяк җирләр һәртөрле киеккә бай; анда кеш, ас, тиен һәм кара төлке аулаганнар. Шул кыйммәтле мехлардан затлы туннар тектәннәр, аларны үзләрендә дә калдырганнар, читкә дә чыгарганнар (бер тун, мәсәлән, мең бизант торган — шул заман өчен бик югары бәя). Төньяк кабиләләрдән татарлар ясак та җыйганнар. Көнбатыштагы җирләр белән Монгол империясенең башкаласы Каракорым һәм Кытай арасындагы сәүдә юлы да Көнбатыш Себер аркылы үткән.

Әгәр дә ул вакытларда халык күбрәк хайван асраучылык белән мәшгуль булса, соңга таба игенчелек белән шөгыльләнә башлыйлар. XV—XVI йөзләрдә татарлар тары, арпа, солы һәм бодай иккәннәр — бу хакта язма, археологик чыганаклар ачык сөйлиләр. Археологик казулар Көнбатыш Себердә шулай ук һөнәрчелекнең дә шактый алга киткәнлеген раслый. Металлургия, туку һәм тегү эшләре, мех эшкәртү, тире иләү һәм башка төр һөнәрчелек булганын исбатлаучы табылдыклар шактый күп тупланган. Алтын Урда һәм Себер ханлыгы чорына караган затлы савыт-саба, көмештән һәм асылташлардан эшләнгән ювелир әйберләр, селадон, ягъни кыйммәтле кытай фарфоры, гарәп һәм җуҗи акчалары — болар һәммәсе урта гасырның гомумтатар дөньясына хас булган кадерле археологик ядкәрләр.

Көнбатыш Себернең тулы археологик картасы төзелмәгән булса да, язма чыганаклар буенча мәгълүм булганнары һәм казып өйрәнелгәннәре Себер ханлыгында шәһәрләрнең булганлыгын раслый. Шулар арасында иң борынгы шәһәр Себер яки Искер, Төмән (Чынгы Тура), Тонтур, Табул, шулай ук әлегә өйрәнелмәгән Касыйм Тура, Яулы Тура, Кызыл Тура кебек шәһәрләр, Самар, Царев шәһәрлекләре (городище) исемен йөртүче урыннар. Кайбер борынгы шәһәрләрдә табылган истәлекләр монументаль архитектура һәм төзелеш эшенең шактый югары дәрәҗәдә торганлыгын күрсәтә. Себердә булган сәяхәтчеләрнең язмаларында да төрле җирләрдә очраган борынгы хәрабәләр арасында таш мәчет, таш пулат калдыкларының еш күзгә ташлануы әйтелә. Шәһәрләрнең исемнәре дә, күргәнебезчә, татар исемнәре, мәсәлән, Төмән — ун мең гаскәр башлыгын аңлатучы шул ук «төмән» сүзеннән; Искер «иске ер» (йер — җир)дән. «Иске шәһәр» мәгънәсе, гомумән, татар җире өчен шактый хас әйбер, ягъни яңа шәһәр, яңа башкала төзелгәч, элеккесенә «иске» атамасы өстәлә. Шундыйлардан Алтын Урданың үзәк җирләрендәге Иске Сарай һәм Яңа Сарай, Казан ханлыгындагы Иске Казан һәм

Яңа Казан, Кырымда яңа шәһәр Бакчасарайга кадәр башкала булган Иске Кырымны (Солхат) күрсәтергә мөмкин.

Моннан берничә ай элек «Социалистик Татарстан»да басылган «Алтын Урда һәм татар тарихы» исемле мәкаләдә (30, 31 август, 3 сентябрь саннары) мин болай дип язган идем: «Әгәр дә шушы олуг дәүләт (ягъни Алтын Урда) таркалмаган булса, бүген аерым этнографик төркемнәргә бүленмәгән чын мәгънәсендә бердәм татар халкы барлыкка килгән булыр иде». Мин бу фикеремне бүген дә кабатлыйм һәм шуңа аерым басым ясап үтәм: бер үк халыкның төрле төркемнәрендә кайбер тел һәм этнографик аермалыклар булу һич кенә дә ул халыкның бербөтен этнос булуын юкка чыгармый.

Алтын Урданың, әйткәнемчә, әлегә чын сәбәпләре ачыкланып җитмәгән таркалуы XV йөз башларында татарның халык буларак формалашып бетүенә комачаулый. Ул тарихи-этник процесс шул җирлектә барлыкка килгән аерым татар дәүләтләре — Казан, Кырым, Себер, Әстерхан, Касыйм ханлыклары чорында тәмамлана. Объектив тарихи сәбәпләр аркасында бүген этнографик төркемнәр дип атала һәм шул дәүләтләрнең исемнәре дә кушылып әйтелә торган, бераз тел һәм мәдәни үзенчәлекләре дә булган аерым географик төркемнәр барлыкка килә. Әмма алар барысы да бер халык — «татар» исемен йөртүче татар халкы. Ә бу исем, ягъни төрки телле борынгы татарларның этноним-үзатамасы, бөтен татар халкын берләштерүче ныклы нигезгә әйләнә. Шунысы бик тә мөһим: заманында бит алар берсе дә теге яки бу җирлек һәм шәһәр исемен кушып Казан татарлары, Себер татарлары, Кырым татарлары һ. б. дип әйтелмәгәннәр, ә бер сүз белән «татарлар» дип кенә аталганнар. Географик кушымталар фәнни термин буларак соңыннан барлыкка киләләр.

Алтын Урданың соңгы һәм аерым татар ханлыкларының башлангыч чорына кагылышлы тарихи чыганакларны, шулар нигезендә язылган чын фәнни хезмәтләрне бик җентекләп, ифрат кызыклы вә гыйбрәтле вакыйгаларга бай булган татар тарихын бик тә беләсе килеп, «фәлән татарлар безнеке түгел, төгәненең тарихына безнең катнашыбыз юк» дигән ялгыш, надан һәм хыянәтчел карашка иярмичә, ихлас күңелдән укып чыккан намуслы затка шул мәгълүм булыр: Көнбатыш Себердән Кырымгача, Казаннан Төньяк Кавказгача кадәр булган җирләр — татарлар халык буларак формалашкан татар җирләре, аның борынгы шәһәрләре — татар шәһәрләре, халкы — татарлар, теле — татар теле. Шул чордагы вакыйгалар, аларда катнашкан ханнар, дәүләт эшлеклеләре, гаскәр башлыклары, сугышчылар

һ. б. шулкадәр бер-берсе белән аралашып бетканнәр, андагы төрле этник дөнья турында сүз алып барырга түгел, хәтта уйларга да урын калмый. Югарыда санап үтелгән биш татар ханлыгы (алтынчысы Нугай Урдасы) арасындагы сәяси һәм милли багланышлар шулкадәр бәйләнешкәннәр ки, аларны бик теләсәң дә бер-берсеннән аера алмассың. Якын күршеләр булган Казан һәм Себер, Себер вә Нугай, Нугай һәм Әстерхан арасы гына түгел, ә Казан — Кырым, тагын да ераграк булган Кырым — Себер аралыгы да шул гомум вакыйгалар яктылыгында бик тә якын күренәләр. Очлары очка бәйләнеп беткән нәселләр, уртак нәселдән килүче ханнар, аларның берсенең бер ханлыкта, туганының яки туганнан туганының икенче ханлыкта утырулары, алай гына да түгел, бер үк хан дәүләттән дәүләткә, тәхеттән тәхеткә күчкән очракта да бернинди тылмачка да мохтаҗ булмавы — болар һәммәсе дә берлек хакында сөйләмимени? Шөбһәсез, шул хакта!

Халкыбызның борынгы һәм урта гасырлардагы үткәне, аның килеп чыгышы һәм гомумән этник тарихы белән бернечә дистә ел шөгыльләнүче профессиональ тарихчы-археолог буларак, минем бик тә җаваплы рәвештә шуны белдерәсем килә: XV—XVI йөзләрдәге татар җирләре, татар халкы — бер этник дөнья! Әгәр дә мин нindидер сихри көчкә, илаһи кодрәткә ия булсам, Алтын Урданың үзендә һәм соңрак Кырымда хан булып торган, Казан ханнарының нәселенә нигез салган Олы Мөхәммәтне, аның Казан һәм Касыйм ханнары булган ике улы Мәхмүтәк белән Касыймны, Кырым һәм Олы Урда тәхетләрендә утырган Кече Мөхәммәт белән Сәетәхмәтне, беренчесенең улы — Әстерхан ханы Әхмәтне, Кырым һәм Әстерхан ханы Дәүләтбирдене, аның абыйсы — Алтын Урда ханы Гыязетдинне, аның улы — Кырымның беренче ханы Хаҗигәрәйне; Урда ханы Тимеркотлыкта, Кырым ханы Сәетәхмәттә гаскәр башлыгы булган, гомумән, башта Алтын Урданың, соңыннан Нугай һәм Себер җирләренең куәте өчен зур көрәш алып барган, татар халкы, беренче чиратта, Казан һәм Себер татарлары арасында киң таралган атаклы «Идегәй» дастанының төп герое легендар Идегәйне, аның төрле ханнарда, мәсәлән, Олы Мөхәммәттә, Хаҗимөхәммәттә, Урда һәм Себер ханы Боракта, шулай ук Себер ханы Әбелхәердә гаскәр башлыклары булган уллары Мансур, Нәүрүз, оныгы Ваккасны, Нугай Урдасының көч-куәтен торгызу өчен көрәшкән кече улы Нуретдинне; Идегәйнең тагын бер оныгы — Нугай бие Тимернең кызы Нурсолтанны, аның Казан ханы Ибраһимнан туган һәм үзләре дә Казан ханнары булган Мөхәммәтәмин белән Габделла-

тифны, кызы Гәүһәршадны, аның ире Булат бине һәм аларның улы, атаклы карачы, бәкләри бәк Нургали Ширинны, Нурсолтанның Кырым ханы Миңлегәрәйдән туган, соңыннан Кырым һәм Казан ханы булган улы Сәхибгәрәйне, аның туганнан туганы, Казан ханы Сафагәрәйне, Сафагәрәйнең хатыны, Нугай бие Йосыф кызы һәм Казан ханбикәсе, татар халкының милли герое Сөембикәне вә тагын бик күпләрне каберләреннән торгызыр идем дә, үз авызларыннан үзләренең, ата-бабаларының тарихларын сөйләтер идем. Иманым камил, алар татар телендә гомумтатар тарихын сөйләп бирерләр иде.

Ә мин, тарихчы буларак, шул ук татар телендә язылган, әле бүген дә һәр татарга бик тә аңлашыла торган күп кенә ярлыкларны: Алтын Урда ханнары Тайдула, Бирдебәк, Түләк, Туктамыш, Тимеркотлыкларның, Кырым ханнары Хаҗигәрәй, Сәгадәтгәрәй, Миңлегәрәй һәм башкаларның, Казан ханнары Ибраһим вә Сәхибгәрәйләрнең ярлыкларын, аларда тулып яткан һәм бүгенге татар сүзләреннән берни белән дә аерылмаган бик күп атамаларны — феодаль һәм рухани терминология, идарә бүленеше, җир биләү тәртибе, икътисади төшенчәләр, ясак, салым җыю тәртибен аңлаткан сүзләрне мисалга китерер идем. Менә тыңлагыз: хан, мөфти, шәех, казый, суфый, илче, битекче, юлаучы, кимәче, тамгачы, ясак, салым, бурыч, амбар малы, бурла тамгасы, ындыр хакы...— бүген һәркемгә аңлашыла торган бу сүзләр, бу атамалар XIV—XVI йөзләрдә — булсын Сарайда, булсын Кырымда, булсын Казанда — нәкъ менә шулай әйтелгәннәр һәм язылганнар.

Ә сез, хөрмәтле укучылар, XIV—XVI йөз татар әдәбиятының гүзәл ядкәрләре саналган, һәр укымышлы татар тарафыннан үз итеп, яратып укылган һәм укыла торган, Алтын Урда башкаласы Сарай шәһәрендә иҗат ителгән урта гасыр поэмаларын: Котбның «Хөсрәү вә Ширин»ен, Харәзминең «Мәхәббәтнамә»сен, Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ын, ниһаять Сәйф әс Сараиның җәүһәрләр җәүһәре булган «Гөлстан»ын искә төшерер идегез. Ә мин сезгә кушылып, чыгышлары белән Алтын Урдадан булган, соңга таба Кырым, Касыйм һәм Казан ханлыкларының иң атаклы карачылар нәселе саналган Ширин, Барын, Аргын, Кыпчак ыруглары, шул ук карачылар нәселенең Нугай Урдасы һәм Себер ханлыгында да булганлыгы турында сөйләр идем.

Мөхтәрәм укучылар әйтерләр, нәрсә соң, шулкадәр үк идеал берлек булганмыни, диярләр. Юк, мин идеаллаштырмыйм. Татарның бүгенге һәр этнографик төркемнең әле Алтын Урдага хәтле үк нигез ташларын салуда катнашкан аерым компонентлары булган. Казан татарларын-

да ул, шөбһәсез,— Идел буе болгарлары, мишәрләрдә — мажарлар, әстарханлыларда — хәзәрләр; Себер татарларында Алтай төркиләре, бигрәк тә Иртеш буйларында VIII—X йөзләрдә яшәгән кимәкләр, аларның XI йөздән «кыпчак» исеме белән мәгълүм булган көнбатыш төркеме; әле монгол яуларына кадәр үк Көнчыгыш Төрки каханлыгыннан көчәнеп килгән һәм шул ук кимәкләр җәмгыятен төзүгә зур өлеш керткән төрки телле борынгы татар кабиләләре. Әмма болар һәммәсе дә төрки телләр гаиләсенең төньяк төркемен тәшкил итүче бик тә якын кардәш кабиләләр булганнар. Ә инде бөтен татарны берләштерүче көч — ул Алтын Урда дәүләтенең төп төрки халкын тәшкил иткән зур татар-кыпчак этносы. Антропологик яктан да төрлелек бар, әйтик, Кырым, Казан татарлары һәм мишәрләр нигездә европалы булсалар, әстерхан-нугай, бигрәк тә Себер татарларында монголоидлык күзгә ташлана. Бу хәл инде Себернең, гомумән, монголоид дөньяга якынрак булуы белән аңлатыла. Новгород урысларыннан Тверь—Мәскәү җирендәгеләр, алардан да ерак себернекеләр аерылып торган кебек, бөтен татарның да йөз-кыяфәте бер-берсенә бик үк охшаган дип әйтеп булмый.

Сәясәттә һәм милләтара мөнәсәбәтләрдә соңгы елларда барлыкка килгән үзгәреш-яңарышлар — демократия, сүз иреге, халыкларның гомум уянуы белән беррәттән, тискәре яклар да күренә башлады. «Возрождение России» дигән демагогик сылтау астында урыста көчәеп киткән шовинизм, ә Рәсәйгә буйсынган халыкларда милли-азатлык хәрәкәте кебек уңай күренеш белән бергә деконсолидациягә, моңарчы болай да бүлгәләнгән һәм чәчелгән халыкны тагын да бүлгәләү, бер-берсеннән аерырга омтылу көчәйде. Бу — омтылу гына түгел, бу — астыртын да, ачыктан-ачык та алып барыла торган ифрат дәрәҗәдә куркыныч сәясәт. Йөз елларга сузылган самодержавие-чиркәү, дистә еллар дәвамында алып барылган Сталинның казарма социализмы идеологиясе, тоталитаризм инде болай да урыс булмаган халыкларга, бигрәк тә татарларга карата «разделяй и властвуй» дигән хыянәтчел политика үткәрде. Менә шушы хәтәр политиканың бөтен куркынычын аңлап бетермәгән һәм аңларга дәрте дә, дәрманы да булмаган кайбер милләттәшләребез, аянычка каршы, үз халкын аеру, бүлгәләү, санын киметергә тырышу өлкәсендә сатлык эш алып баралар. «Татар» исемен «болгар»га алыштырырга, Татарстанны «Болгарстан» итәргә ачыктан-ачык өндәүләр, керәшен, Әстерхан һәм Себер татарларын аерым халык ясарга йөрүләр — болар һәммәсе дә империячел фикер йөртү тегерменәнә шаулатып су коялар. Ә ул политика

бүгенге урыс «демократлары», күптөрле монархистлар. «либерал-демократлар» исеме астына яшеренгән неофашистлар житәкчелегендә тагын да куркынычрак, йөгәнсезрәк була бара. Бер унитар дәүләт (СССР) җимерелеп, аның урынына чынлыкта Россия хакимияте астында яшәргә тиеш булачак «Бәйсез Дәүләтләр Берләшмәсе» оешып, моңарчы Рәсәйгә буйсынып яшәүгә мәҗбүр булган, тик бервакытта да славян-урыс булмаган төрки һәм угро-фин халыкларын яңа коллыкка, яңа ассимиляция калыбына кертеп куярга тырышкан бер заманда безгә — борын-борыннан дәүләт тоткан, шәһәр мәдәниятенә, язма әдәбиятка, цивилизациянең башка казанышларына ия булган татарларга бүленешү түгел, киресенчә, бердәмлекне тагын да ныгытуны икеләтә, өчләтә арттырырга кирәк.

Бары тик бергәлектә генә без үзебезнең милли йөзебезне югалтмабыз, халык буларак сакланып кала алырбыз. Алай гына да түгел, милли-азатлык хәрәкәтебезне ахыр максатка кадәр җиткереп, тулы чын бәйсезлек яулап ала алырбыз.

«Социалистик Татарстан»,
1992, 31 гыйнвар.

440 ЕЛГА СУЗЫЛГАН ИНКЫЙРАЗ

Каләм! Кальбендә[1] ни сер бар — гаян ит[2],
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Түгеп күз яшьләренне бу кәгазьгә,
Ни моңлы уйларың бар — сөйлә безгә!..

Дәрдмәнд

«Инкыйраз»ны мин бөтенләй бетү, юкка чыгу итеп түгел, ә аның икенче мәгънәсендә — тәрәккыят-прогресстан үзгә булган регресс, ягъни артка китү, чигенү рәвешендә кулланып язам. Әйе, нәкъ менә дүрт гасыр ярым чамасы тукталыш, дәүләтеңнән мәхрүм булу, үзеңне басып алган дәүләткә буйсынып, җаның кыйналып, рухың мыскылланып яшәү...

Юк, мин язмама һич кенә дә елак тон бирәсем килми. Киресенчә, бүгенге үзгәреш, яңарыш, сүз иреге, Татарстанның бәйсезлеге өчен көрәш заманында киләчәккә булган өметләр зур. Әмма гасырларда онытылмаслык хәтер бар, күп халыкларга насыйп булмаган чын мәгънәсендә мең

---

[1] Кальбеңдә — күңелеңдә, йөрәгеңдә.
[2] Гаян ит — ачып сал.

еллык дәүләт тарихы бар, шул дәүләтчелеккә балта чапканда туган җиренең азатлыгы өчен газиз җаннарын биргән меңләгән вә ун меңләгән фидаиләрне өзелеп сагыну бар. Моң бар, рәнҗү бар, сагыш бар...

Бүгенге Бөек хәтер көнендә, соңгы дәүләтләребезнең берсе булган, шул ук вакытта урыс гаскәрләре тарафыннан иң беренче буларак басып алынган Казан ханлыгын, аның башкаласы булган борынгы Казанны искә төшергәндә, иң әүвәл шул дәүләт, шул газиз шәһәр хакында кыскача гына бер белешмә биреп үтик.

Борынгы Төрки каханлыгы, соңра Болгар һәм Алтын Урда дәүләтләренең сәяси, мәдәни вә этник дәвамы буларак 1445 елда мөстәкыйль дәүләт рәвешендә барлыкка килгән Казан ханлыгы Көнчыгыш Европаның зур дәүләтләреннән берсе булган. Тиз арада ул Шәрык һәм Көнбатыш илләре белән якын мөнәсәбәт урнаштыра, анда игенчелек, шәһәр төзелеше, һөнәрчелек, сәүдә эше нык үсеш ала. Болгар һәм Алтын Урда чорында киң колач җәйгән архитектура һәм гамәли сәнгать Казан ханлыгы чорында яңа баскычка күтәрелә. Гыйлем вә мәгърифәт, шигърият һәм халык авыз иҗаты яңа үрләр яулый.

Һәр тарафтан чиста сулар — чал Идел, бормаланып аккан Казан елгасы, тезелешеп киткән Кабан күлләре белән әйләндереп алынган Казан каласы үзенең хан сарайлары, күккә ашкан мәчет манаралары, шәһәр капкалары белән ерактан ук, тау башында бик матур булып күренеп торган. Монда Мәхмүтәк, Ибраһим, Мөхәммәтәмин, Сафагәрәй кебек кодрәтле ханнар, Нурсолтан һәм Сөембикәдәй зирәк вә чибәр ханбикәләр, Булат белән Нургали Шириндай атаклы карачы-биләр идарә иткән, Колшәриф кебек олуг сәет һәм мөхтәсибләр халыкка дин белеме, үгет-нәсихәт биргән, тугры юлга өндәгән. Мөхәммәдъяр, Гарифбәк, Өммекамал кебек шагыйрьләр вә шагыйрәләр илһамланып иҗат иткән. Монда исемнәре билгеле һәм әлегә билгесез булган башка зыялылар, күп санлы гаскәриләр, һөнәрчеләр, сәүдәгәрләр, бүтән төрле агай-эне яшәгән, дөнья куган, нәсел алыштырган. Бу — шулар, безнең бабайлар җире!

Тукайча әйтсәк:

> Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары...

Әмма Рус дәүләтенең өзлексез рәвештә Казанның эчке һәм тышкы эшләренә тыкшынуы: сарай интригалары оештыру, коткы таратулар, дәүләт переворотлары ясау, сатлыкҗан булган «курчак» ханнарны Казан тәхетенә утыртулар, ниһаять, урысның бөек кенәзләре һәм патшалары-

«Мондадыр безнең бабайлар түрләре, почмаклары...» З. Бәширов фотосы, 1992

ның, мәсәлән, Иван III, бигрәк тә аның оныгы Иван IV-Грозный, ягъни Явыз Иванның Казанга ясаган өзлексез һөҗүмнәре ханлыкның мөстәкыйль яшәешенә чиксез зур зыян китерәләр. 1552 елның 2 (15) октябрендә урысның

150 меңлек зур гаскәре Казанны яулап ала. Шәһәрне саклаучыларның күпчелеге батырларча һәлак була, исән калганнары, урманнарга күчеп, көрәшне дәвам иттерә. Алты елдан соң ханлыкны торгызу нияте уңышсызлыкка очрый. Шулай итеп, Казан җире көчләп, кан койдырылып Рус дәүләтенә буйсындырыла.

Менә шушы бик кыска гына әйтеп үтелгән, әмма һәркемгә мәгълүм булган тарихны — башкаласы алынып, дәүләте юкка чыкканны татар халкы онытмый, яраланган хәтерендә саклый.

«Гасырлар буена бу хәтерне сындырырга, аны халык аңыннан юарга маташтылар. Моны элегрәк самодержавие һәм чиркәү идеологиясе, аннары Сталин һәм аның иярченнәре төзегән казарма социализмы, аның Жданов һәм Суслов кебек идеологлары эшләде. Казан ханлыгын ниндидер вәхши дәүләт, көнчыгыш «деспотизмы»ның ачык чагылышы дип атадылар, ә татарларны русларга һәрдаим һөҗүмнәр ясап торган ярым кыргый халык итеп күрсәтергә азапландылар. Казан ханлыгы һәм аның башкаласы турында язганда күбрәк аның Рус дәүләтенә каршы бихисап «һөҗүмнәре» яктыртылды, шул булмаган яки булса да җавап рәвешендә барган «һөҗүмнәр»дән котылу өчен Иван IV нең (аның бөтен дөньяга билгеле «Грозный» атлы кушаматы да оныта язды һәм аны хөрмәтләп Иван Васильевич дип йөртә башладылар) «Казан походлары» нәтиҗәсендә Казан шәһәрен һәм ханлыкны яулап алуын (аны «Россиягә кушылу» сүзе белән алыштырдылар) прогрессив күренеш дип бәяләделәр. Моны үзәктәге тарихчылар гына түгел, үзебезнең Казан, хәтта татар галимнәре дә шулай дип яздылар. Дөресрәге, шулай диярга мәҗбүр булдылар. Элегрәк, башкача язганнары себер китте, НКВД подвалларында газиз җаннарын бирде».

Әлеге сүзләрне мин моннан нәкъ өч ел элек, 1989 елның 15 октябрендә «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Тарих шаһит» исемле мәкаләдә язган идем. Ялгышмасам, ул шушы авыр темага багышланган беренче язма булды. Нәкъ шул көнне Кремльдә, Сөембикә манарасы янында беренче тапкыр, «җирле властьлар» тарафыннан рөхсәт ителмичә генә, Хәтер көне үткәрелде. Җыйналган кеше дә әлләни күп түгел, карашлары да сак, күпләрнең йөзендә курку катыш аптырау, сагаю димме... Бауман районы җитәкчеләре килеп, халыкка таралырга да куштылар, әмма кешеләр китмәде, ни булса — шул булыр, дип, калдылар. Сүзләр сөйләнде, мөнәҗәтләр укылды, манара төбенә чәчәкләр куелды. Беренче чирканчык алынды, курку барьеры узылды. Икенче ел, 1990 елның 26 сентяб-

рендә, Сөембикә манарасына ай куелды, ә 15 октябрьдә исә манара янына меңләп кеше җыйналып, Коръән укылды. Хәтер көне зурлап уздырылды. Һәм, әлбәттә, бу көн узган 1991 елда күп халык катнашында тагын да зурлап, тантаналы рәвештә билгеләп үтелде, һәм ул тантана Ирек мәйданында булган мәгълүм вакыйгаларга ялганып китте. Ниһаять, өстендә ай торгызылган манара төбенә ике ел рәттән ураза һәм корбан гаете укылу нур өстенә нур булды.

Моны язып үтүемнең максаты шушы вакыйгаларны бүгенге Хәтер көнендә кәгазьгә кабат беркетеп кую гына түгел. Бу уңайдан менә нәрсәгә җаным әрнеп язам. Шушындый бер заманда «Казан ханлыгының Рус дәүләтенә кушылуы прогрессив күренеш булган» дип китаплар язып, Мәскәүгә барып диссертацияләр яклап йөрүчеләр бар. Элек язганнар инде, әйткәнемчә, шулай язарга кушканнар, чөнки идеологиясе, системасы шулай иде. Әмма ул ялган системага, ул черек идеологиягә 1985, бигрәк тә 1989 елда балта чабылды, хәбәрдарлык булып, һәркем җаны теләгәнен яза башлады. Соң, шулай булгач, бу заманда ничек итеп ялган язып, ялган сөйләп йөрмәк кирәк?

Мин бу хакта әйтми булдыра алмыйм, чөнки дистә еллар гына түгел, ә гасырлар буе язылган, халыкны агулаган сүзләрдән, ялган идеологиядән арыну заманы килде. Халыкларның ялгыш өйрәтелгән, ә безнең татарның исә тәмам мыскылланган, каһәрләнгән тарихын яңабаштан — дөрес итеп язар чак җитте. Бу дөреслек, иң әүвәл, шул каһәр суккан 1552 ел вакыйгаларын яктыртуга мохтаҗ. Менә шуңа күрә дә, дөньяга күз ачылган, куркудан узып барган бер заманда җәмәгатьчелеккә, халыкка тарихи дөреслекне бирергә тырышып йөргәндә, икенче берәүләрнең искечә фикер йөртүләрен, шуннан арынуга дәрте дә, дәрманы да булмаганлыгын, кешеләргә тарихтан ялган мәгълүмат бирүне дәвам иттерүләрен күрү аяныч та, оят та! Элегрәк ялган язган, кайберәүләре, теләмәсә дә, язарга мәҗбүр булган мәрхүмнәрнең авыр туфраклары җиңел булсын!

Болай дип язарга минем тулы хакым бар, чөнки мин үзем шул каһәр төшкән тоталитаризмның корбаны булган кеше: моннан нәкъ ун ел элек, 1982 елда, торгынлык тавының түбәсенә менеп җиткән бер заманда, мине пантюркизмда, панисламизмда да гаепләп (мин Болгар белән Алтын Урданың тел якынлыгы, дин берлеге хакында язганмын икән!), Мәскәүдә диссертациямне уздырмадылар. Казаннан бер «мөхтәрәм» татар галиме мин диссертация яклар алдыннан шунда барып, гыйльми совет әгъзалары

арасында минем хакта «националист» дип хәбәр тарата, начар фикер тудыра, киткәндә диссертациям турында ялган белән тулы шикаять тә язып калдыра. Әлбәттә, алар һәммәсе ул вакытта үзләренең кара эшләрен эшләделәр. Әмма мин шул кара елларда докторлык диссертациясе яклый алмый калуым белән горурланам! Үзгәртеп кору, яңача фикер йөртү чоры килде, аллага шөкер, моннан ике ел элек, мин диссертациямне яикладым. Шул кеше үзе кебек үк ялган язып йөрүче ике мөриде белән «Наука» нәшриятында чыгарга тиеш китабымны чыгартмау өчен дә, мең төрле киртәләрне үтеп китап басылып чыккач та, әллә никадәр ямьсез отзыв-рецензияләр язып йөрделәр, тик берни дә эшли алмадылар — китабым хакында икенче гадел затлар язган уңай рецензияләр дөнья күрде. Дөреслек үзенекен итте! Миңа Сөембикә манарасына ай куйдыртуны һәм Казан урамнарына күпләп татар исемнәрен бирүне башлап йөрүем өчен дә, халкыбызның гасырлардан килгән газиз исеме булган «татар»ны «болгар»га алыштыруга каршы көрәш алып барганым өчен дә, булсын урысыннан, булсын татарыннан, янаулар ишетергә дә, мыскыллы, дорфа хатлар алырга да туры килде. Ләкин мин андыйлардан гына курка торган кеше түгел! Болгар тарихын бозып, ялган язып йөрүчеләргә, бөтен татарның бөек дәүләте булган Алтын Урда тарихын һәм мәдәниятен күтәрергә теше-тырнагы белән каршы торучыларга, «татар»ны «болгар», «Татарстан»ны «Болгарстан» итәбез дип халкыбызның бөтенлегенә, бердәмлегенә хыянәт эшләүчеләргә, аның санын киметергә азапланучыларга, ниһаять, Казан ханлыгының Рус дәүләтенә «кушылуы» «прогрессив күренеш» булган, дип кеше алдап йөргәннәргә каршы, кем генә булуына карамастан, аяусыз көрәш алып барачакмын! Сүз уңаеннан шуны да әйтеп үтим: шушы хәерче, ялган вә пычрак белән тулган Рәсәйдә нинди «прогресс»ка ирешкәнлегебезне акыл шәрифләренә зыян килмәгән адәми затка аңларга вакыттыр бит инде.

Темадан читкә китте, дип уйламасагыз иде, чөнки болар һәммәсе халкыбызның каһәрләнгән тарихын яңабаштан, дөрес итеп язу кирәклегенә кайтып кала. Ә шул каһәрләнгән тарихның иң каһәрләнгәне — 1552 елда Казанны басып алу тарихы. Аның алдыннан дистә еллар буе Мәскәү хөкүмәте үткәргән пычрак сәясәтне бер мәкаләдә генә язып бетереп булмый, әлбәттә, бу турыда калынкалын китаплар язу кирәк. Әмма әлегә шуны искәртеп үтәм: Казан ханнарының Рус дәүләтенә өзлексез, «варварларча» һөҗүм итеп торулары турындагы сүзләр — уйдырма, чеп-чи ялган! Бу ялган, беренчедән, Рус дәүләтенең

Казанны басып алуын аклау өчен сөйләнсә, икенчедән, нәкъ менә татарның «вәхши»леген күрсәтергә кирәк иде, чөнки бу халык урыска корал көче белән буйсындырылса да, бервакытта да аңа кол булмады, телен, динен, чын мәгънәсендә күп гасырлык олуг мәдәниятен, матур гореф-гадәтләрен, ниһаять тарихи хәтерен югалтмады, чөнки бу халык кайчандыр урысның үзен буйсындырып торган бөек халык иде. Империя идеологиясе моны гафу итә алмады, шуңа күрә аның татарга карата алып барылган сәясәте, татар турында язган тарихы пычрак белән тулды.

Мин бер әйбергә аерым басым ясап үтәм. Бу язмам өчен мине берәү дә милләтара ызгыш уятуда гаепли алмас. Мин урыс халкын түгел, ә шул халыкның үзенә дә искиткеч зур газаплар китергән Грозныйларның хәбис сәясәтен гаепләп язам (нәкъ менә Иван Грозный һәм ул төзегән опричнинаның Россиядә алып барган репрессияләре хакында, соңгы елларда игълан ителгән мәгълүматларга таянып, «Тарих шаһит» дигән мәкаләмдә язган идем инде). Мин, соңыннан үзләре үк кызыл террор һәм канлы репрессияләр оештырган Ленин белән Сталин «халыклар төрмәсе» дип атаган Россиянең башка халыкларны яулап алуга корылган «разделяй и властвуй» дигән хыянәтчел политикасы турында язам. Нәкъ менә шул политика нигезендә, башта әллә ни зур булмаган Рус дәүләте, чагыштырмача тиз арада коточкыч дәү империягә әйләнә һәм шул империя төзелү бүгенге Татарстан җирендә, ул җирнең борынгы башкаласы булган гүзәл Казан каласын кара канга батырып яулап алудан башлана.

Казан ханлыгы төзелгәннән башлап аны басып алганга кадәр, 1552 елгы соңгы сугышны да кертеп, Рус дәүләте Казанга һәм Казан җиренә 15 поход оештыра, Казан ягыннан исә җавап рәвешендә 5—6 һөҗүм була. Менә сезгә Казан ханнарының Рус дәүләтенә «өзлексез», «варварларча» һөҗүмнәр ясап торулары! Минем сүзләремә ышанмаучылар үзләренең газиз вакытларын кызганмыйча һәм бөтен түземлекләрен җыеп, кырыкка якын калын-калын томнардан торган урыс елъязмаларының тулы җыелмасын һич иренмичә, бик җентекләп актарып чыгып, шунда тасвирланган тарихи вакыйгаларга үзләре фәнни анализ ясый алалар. Андый эшкә дәрт вә дәрманы булмаганнарга тарихи чыганакларны бик тә намуслы кул-

ланып язган берничә монографиянең дә ярдәмгә килүе ихтимал. Шулар арасында: Казан, соңыннан Ленинград археологы һәм тарихчысы М. Худяковның 1923 елда Казанда урыс телендә басылган «Казан ханлыгы тарихыннан очерклар» исемле күпләргә мәгълүм китабы һәм поляк эмигранты, тарихчы Я. Пеленскийның 1974 елда Парижда инглиз телендә дөнья күргән «Россия һәм Казан» дигән, әлегә җәмәгатьчелеккә бик үк таныш булмаган зур гына монографиясе. Намуссызлык турында намуслы кешеләр язган, гыйбрәт белән тулы тарих китаплары — укый күрегез!

Шулай итеп, 15 нче соңгы, татар халкының тарихи язмышын гасырларга хәл итәргә калдырган канлы сугыш — Явыз Иванның Казанга 1552 елгы походы... 1549—1550 елларның кышында Казанга оештырылган чираттагы поход уңышсызлыкка очраган була, шуңа күрә Мәскәү хөкүмәте яңа, соңгы сугышка ныклап әзерләнергә карар бирә. Иң әүвәл киләчәк походны тәэмин итеп торырлык яхшы тыл, хәрби база булдыру нияте белән Казаннан 30 чакрым гына ераклыкта, Зөя суы тамагында крепость төзергә булалар. Булачак крепостьның һәр корылмасын, һәр бүрәнә һәм детален җентекләп эшләп, башта үзләренең Углич шәһәре янында корып карыйлар һәм кире сүтеп, билгеләр куеп, Идел буйлап Зөя тамагына китерәләр. Шунда 1551 елның май-июнь айларында, 28 көн эчендә, әйтергә кирәк, Казанның «борын төбендә», аңа каршы сугышка әзерләнү өчен өр-яңа крепость барлыкка килә. Казан ханлыгының көнбатыш өлеше — Тау ягы, шулай итеп, җайлы гына Рус дәүләтенә буйсындырыла.

Яңа походка яшь Иван Грозный һәм аның хөкүмәте бик хасиятләп тотына. Иң әүвәл дипломатияне эшкә җигәләр, һәм ул шактый гына уңышка да ирешә. Нугай морзасы Исмәгыйль бине алдап-йолдап, юк кына бүләкләр белән кызыктырып, Кырым-Казан коалициясенә катнашудан баш тарттыралар, шулай итеп, Казан үзенең көчле тылыннан мәхрүм кала, ә бит Нугайның ул вакытта 300 меңле атлы гаскәре була... Кызганыч, бәгырьне кортырлык кызганыч!

Шуннан ике ел элек кенә, 1549 елның мартында ниндидер сәбәпләр аркасында Казанның атаклы ханы Сафагәрәй үлеп киткән була (аны үтергәннәр, дигән фикер дә

бар. Һәрхәлдә, «Казан тарихы» дигән мәгълүм язма авторының Сафагәрәй исерек килеш ваннада юынганда егылып үлгән дигән сүзенә мин ышанмыйм, моны аек акыллы мөселман ханына чын дөреслекне яшерү максатында яла ягу дип кабул итәм). Яшь хан итеп Сафагәрәйнең ике яшьлек улы Үтәмешгәрәйне куйсалар да, дәүләт белән аның исеменнән Сөембикә идарә итә башлый. Әмма казанлылар алдына Мәскәү ультиматум куя: йә Казан тәхетенә кире Шаһгалине чакыртып, Сөембикәне улы белән Мәскәүгә озатасыз, йә урыс гаскәренә шәһәр капкаларын ачасыз. Мәскәү бөтен Тау ягын басып алган, крепость төзеп, менә-менә Казанга яу белән килергә тора, ә Казанның аңа каршы торырлык мөмкинлеге аз. Дәүләт бәйсезлеге бәрабәренә Сөембикә ультиматумны кабул итә, әсирлеккә төшәргә әзер була. 1551 елның 11 (24) августында 31 яшьлек гүзәл Сөембикәне сөйгән халкыннан, кадерле шәһәреннән аерып, зар елатып, өч-дүрт яшьлек улы белән бергә Мәскәүгә алып китәләр.

Казан тәхетенә өченче тапкыр, инде аннан элек ике мәртәбә куылган «рус ставленнигы» (К. Маркс сүзләре), сатлыкҗан вә хәбис шәхес, Касыйм ханзадәсе Шаһгали утыра. Ләкин аның кем икәнлеген, нәрсә өчен куелганлыгын аңлаган казанлылар эшне тиз тоталар, аны өченче — соңгы тапкыр Казаннан куып җибәрәләр. Теге юньсез киткәндә дары мичкәләренә су салдыртып, чынында татар гаскәрен утлы коралсыз калдырып китә. Казанлылар үзләренә хан итеп Әстерханның Әхмәт хан нәселеннән булган Ядегәрне чакыралар. Яңа хан килгәч, Казанга дәрт керә, бөтен шәһәрдә сугышчан рух күтәрелә.

Казанны шул сатлык Шаһгалиләр ярдәме белән җайлы гына алып булмаганны аңлаган Мәскәү хөкүмәте бик җитди итеп, әйткәнемчә, соңгы походка җыена. 1552 елның июнендә патша Иван Грозный җитәкчелегендәге 150 мең кешелек гаскәр Казанга чыгып китә. Аның составына аеруча сугышчанлыгы, миһербансызлыгы белән аерылып торган стрелецлар полклары да кертелә. Нижний Новгородтан соң бөтен гаскәр берничә төркемгә бүленеп, август башында Свияжскига килеп җитә һәм шунда ярты ай чамасы ял итеп, сугышка әзерлек эшләрен тәмам иткәннән соң, Иделне кичеп, 23 август көнне Казанны камап ала.

Башта урысларның эшләре әлләни уңышлы бармый. Казан хөкүмәте шәһәрне саклау планын бик нык уйлап төзегән була: шәһәрнең үзендә 30 мең татар сугышчысы һәм нугайларның 2700 кешелек гаскәре урнаша, ә көнчыгыштарак, Биектау урманнары ягында Япанчы би җитәкчелегендә зур гына атлы гаскәр куела (кайбер чыганаклар буенча, 30 мең, икенчеләрендә — 10 мең). Япанчы урысларны, әнә шул көнчыгыштан, Арча кырыннан әйләнеп килүче төп көчләрен әледән-әле борчып тора, флангларына һөҗүмнәр ясый, Идел буенда калган азык-төлек һәм корал олауларыннан аерып ала. Тиз арада урысның хәрби советы җыелып, шәһәрне һәрьяктан тыгыз боҗра белән әйләндереп алырга карар кылына: Арча кырында кенәз Воротынский җитәкчелегендәге зур һәм алгы полк дигән төп гаскәр урнаша; Казан суының уң ярында, кремльгә каршы җирдә Андрей Курбскийның уң кул полкы, ә аннан елга буйлап өскә табарак Шемякинның запас полкы; Казан суының бирге ягында, Болак елгасы тамагында кенәз Серебряный җитәкчелегендәге сакчы полк (бу шуннан бер ел гына элек Сөембикәне һәм Казанның алтын-көмешләрен тотырып алып киткән бәндә була инде); Болак буйлап өскә таба — кенәз Микулинскийның сул кул полкы, ә тагын да арырак, Кабан күле буенда — сатлыкҗан Шаһгали гаскәре (кайбер хәбәрләргә караганда, анда 3 мең Касыйм татары булган). Ниһаять, соңыннан Печән базары исеме белән һәркемгә мәгълүм булган урында, Күрәеш бистәсе янындагы болынлыкта, Явыз Иванның 20 мең кешелек резерв полкы һәм ставкасы урнаша.

150 гә якын тубы да булган шушы зур көч, шулай итеп, Казан каласын төрле яктан ныклап камап ала. Беренче бәрелеш 26 август көнне була: безнекеләрнең бер төркеме, шәһәрдән чыгып, урысларга ташлана, озак һәм канлы сугыш була, тик алар, күп санлы урыс гаскәренә каршы тора алмыйча, шактый гына корбаннар биреп кире чигенәләр. Икенче көнне иртән урыс шәһәрне тупка тота, әлбәттә, яңа корбаннар була. Җитмәсә, Арча кырындагы төп көчләрне гел борчып торган Япанчы гаскәрен юк итәргә әмер бирелә, һәм ул эш Горбатый-Шуйский атлы кенәз җитәкчелегендәге 30 мең атлыдан һәм 15 мең җәяүледән торган зур бер гаскәргә тапшырыла. Япанчы би

тар-мар ителә. Шунда беррәттән әлеге илбасарлар Казан артына да чыгып китәләр. Арчага кадәр барып житеп һәм аны алып, шул яклардан искиткеч зур байлык талап һәм әсирләр җыйнап, Казанга әйләнеп кайталар — бу рәзил эшләр сентябрь башында эшләнә. Алып кайткан әсирләрне шәһәр ныгытмалары каршындагы казыкларга бәйләп куеп, аларны шәһәрдәгеләрнең бирелүләрен сорарга мәҗбүр итәләр. Әмма казанлылар: явыз дошман кулыннан һәлак булганчы, үзебезнең кулдан үлсеннәр ичмасам дип, теге бичараларга уклар атып, аларның соңгы сулышларын тизләтәләр — ходай ярлыкасын үзләрен!

Ул арада Казан суының теге ярында урнашкан гаскәрнең иң зур өлеше кала ягына чыгып, сакчы һәм сул кул полклары белән кушыла, ә Арча кырыннан зур һәм алгы полк дигәннәре шәһәр ныгытмаларына киң фронт белән якынлашып, Казанның иң зур капкалары саналган Хан һәм Арча капкаларына юллана. Шуя ике капка арасындагы хәрби башня төбен казыйлар һәм дары салып шартлаталар. Бу — Казан ныгытмаларын беренче тапкыр шартлату була, һәм ул эшкә инглиз инженер-химигы Бутлер житәкчелек итә. Соңыннан Иван Грозный аңа Казан жирендә зур имение бүләк итә, һәм шуннан Бутлеровлар фамилиясе башлана — атаклы химик Александр Бутлеров та шул нәселдән. Тик менә бер хикмәт килеп чыга бит әле — урта гасырлар химигы шартлаткан җирдә бүген аның ерак оныгы, дөньякүләм бөек химикка бакыр һәйкәл салып куйганнар! Очраклылык та, вә шул ук вакытта символикасы-ние белән закончалык та. Әнә бит ул урыс патшаларының тәхетедәй зур гына бер креслода горур гына утырып тора, рәхмәт төшкере. Гүя әйтәдер төсле: без сезне шартлаткан идек һәм әле...

Менә шул шартлау эшләре Казанның язмышын хәл итүдә мөһим роль уйныйлар да инде. Тагын бер шартлату 5 сентябрьдә була. Шуның алдыннан гына Грозный янына Казаннан Камай атлы бер сатлык морза килеп (ул әле урыслар Казанны камап алуга, аларга шәһәрдәге гаскәрләр санын җиткергән була), Казан елгасы буендагы чишмәгә халыкның җир асты юлыннан суга йөрүләрен чишә. Патша, Таһир мунчасы дигән зур гына бер мунчаның астыннан әлеге юлга таба казып кереп, шунда шартлаткыч салырга боера (мунча хәзерге Бауман урамының аргы

башындарак, «Цирк» тукталышыннан ерак түгел, Болак буенда урнашкан булган). Җир астын ун көн казып баргач, суга йөрүче татарларның тавышлары ишетелә башлый. Шунда унбер мичкә дары салып, иртәнге таңда шартлаталар: зур шартлаудан һавага очкан таш вә бүрәнәләр төшеп һәм җир астында калып, күп кеше үлә. Стена җимерекләре аша урыслар шәһәргә кермәкче булалар, әмма казанлылар аларны сыптырып чыгарып, бушлыкны төзәтеп куялар. Бердәнбер чиста су чыганагы, шулай итеп, ябылып кала (шунысы гыйбрәтле: әле безнең гасыр башларында да шул чишмә янына татарлар дога кылырга йөри торган булалар). Шәһәр халкы бүгенге Дзержинский урамы буйлап тезелешеп киткән пычрак күлләрдән су ала башлый — ул күлләр буенда мунчалар урнашкан була, шуннлыктан аның сулары эчәргә яраклы булмый. Шәһәрдә йогышлы авырулар башланып, кешеләр шешенеп үләләр. Тик шуңа да карамастан, безнекеләр урыс патшасының илчеләре бирелергә кушып әйткән сүзләрен тыңламыйлар, киресенчә, актык тамчы каннарына кадәр туган җирләрен сакларга ант итәләр.

30 сентябрьдә урыслар Арча капкасы төбендә тагын бер шартлату ясап, шәһәргә кермәкче булалар, әмма татарлар аларны җибәрмиләр. Икенче көнне, 1 октябрьдә, урыс гаскәре Казанны тупка тота, хәзергечә әйтсәк, артподготовка үткәрә. Ниһаять, 2 октябрь көнгә зур һөҗүм билгеләнә. Төнге сәгать икедә бөтен полклар үз урыннарын алып, соңгы штурмга сигнал көтәләр. Кояш чыгар алдыннан ике җирдә, Аталык һәм Нугай капкалары янында (бүгенге Бауман урамының теге башында, элегрәк Политик мәгариф йорты, хәзер Татарстан Фәннәр академиясе янында һәм бу башта, аптека тирәсендә) коточкыч шартлау хасил була. Барлыгы 48 мичкә дары салып шартлаткан шушы афәт нәтиҗәсендә йөзләрчә кеше һәлак булып, Казанны кара төтен каплап ала, шәһәр ныгытмаларына төзәтә алмаслык зур зыян килә. Урыслар ямьсез акырып-бакырып шәһәргә бәреп керәләр, ә татарлар, аллага тапшырып, тегеләргә ташланалар. Гасырлар буена көтелгән, соңгы тапкыр очрашырга тиеш булган ике көч, ниһаять, очраша. Коточкыч, күз күрмәгән, колак ишетмәгән сугыш, кисеш, суеш башлана. Сан ягыннан күп булган урыс татарны кысрыклый башлый, безнекеләр һәр



Казан суы тамагында табылган татар гаскәре башлыгының киеме һәм кораллары: алтынланган очлым (шлем), тимер көбә һәм алтынланган язулы калкан, аерым кылыч, XVI йөз. Татарстанның берләштерелгән Дәүләт музеенда саклана

урам, һәр йорт өчен сугышып, әкренләп Кремльгә таба чигенәләр.

Әмма шунда җиңү чак кына безнең якта булмый кала. Шәһәргә бәреп кергән кяферләр андагы байлыкны күреп, өйләрне, кибетләрне, амбар-келәтләрне таларга тотыналар, чын мәгънәсендә мародерлык башлана. Моны күргән татарлар чиксез ярсып һәм яңа көч-куәт белән кире урысларга ташланалар. Тегеләр: «Секут, секут!» — дип кычкыра-кычкыра, паникага бирелеп, кирегә йөгерә башлыйлар. Урыс өчен кризис хәле туа, әмма Иван Грозный шунда ук яуга 20 меңлек резерв гаскәрен кертә һәм кулына «изге байрак» тотып, Хан капкасы янына баса. Яңа көч кире шәһәргә бәреп керә.

Соңгы сугыш Кремльдә була. Ядегәр хан да, Колшәриф сәет тә чын мәгънәсендә фидакарьлек күрсәтеп, татарларны соңгы тамчы каннарына кадәр җиңүгә рухландырып торалар. Әмма көчләр тигез түгел, Иван яңа көчләр кертеп тора. Колшәриф һәлак була, татарлар соңгы терәк булган хан сараена чигенәләр, шунда ун меңгә якын сугышчы туплана. Соңгы өмет, соңгы омтылыш... Менә Ядегәр ханны әсир итәләр, һәм башсыз калган гаскәр Кремльнең иң төньяк-көнчыгыш почмагында урнашкан Алабуга капкасы аша Казан суына ташлана. Алар башта юлларында очраган урыс гаскәрен кысрыклыйлар, әмма капка янында Курбскийның зур отряды аларга каршы төшә. Казанлыларның бер өлеше урыс арасыннан кылыч-калкан белән үзләренә юл ярып, калганнары шәһәр ныгытмаларыннан аска сикереп, Казан суының уң ягына чыга алалар. Шушы соңгы, инде алты меңгә калган гаскәрнең күпчелеге артларыннан басып килгән күп санлы урыслар белән иң соңгы сугышта һәлак була. Калганнары яндырылган һәм канга батырылган шәһәрләре белән мәңгегә бәхилләшеп, елга аръягындагы кара урманга кереп юк булалар...

Сугыш туктала. Шул коточкыч вакыйгаларны тасвирлаган тарихи чыганакларны, иң әүвәл урысның үз елъязмаларын тетрәнмичә укырга мөмкин түгел. Шәһәрдә урыс гаскәре чын мәгънәсендә кеше суярга тотына; ирләр тулысы белән диярлек кырылып бетә, хатыннарны һәм балаларны әсир итеп, һәр урыска бүлеп бирәләр. Шәһәрдә адәм каны елга булып ага, мәетләр арасыннан атлап йөрү

кыенлаша, 2 октябрьдә[1] Явыз Иван шәһәргә керер алдыннан Нургали капкасы ягыннан өскә таба хан сараена хәтле булган 100 адымлык кына араны мәетләрдән көчкә арындыра алалар. Ашыгыч рәвештә Казан суына һәм Кабан күленә ташланган мәетнең туган җире өчен газиз җанын биргән татар сугышчыларының — исәбе-хисабы булмый. Бу — кешелек тарихында эшләнгән иң зур вәхшилекнең, иң кабахәт садизмның җан өшеткеч, бәгырь корыткыч чагылышы. Шуннан да кыргыйрагы, шуннан да куркынычрагы булганлыгына күңел ышанмый.

Әйе, бу җирдә моннан нәкъ 440 ел элек елга булып адәм каны — татар каны, безнең бабайлар каны ага. Бу җир — шул изге җаннарның газиз сөякләре белән тулган әрнүле, сыкранулы җир. Монда аяк атлаган саен җир астыннан гасырлар ыңгырашы ишетелә, монда, яралы йөрәкле бөек шагыйрь-философ Дәрдмәнд сүзләре белән әйтсәк:

Бабалар кабре янында күңел зар,
Аталар рухының армандәсе[2] бар...

Мин югарыда әйттем, урысның империясе төзелү чынында Казаннан, Казан җиреннән башлана, дидем. Әйе, бу шулай! Иң беренче булып Казан ханлыгы яулап алына, аннан соң башка татар дәүләтләре: Әстерхан (1556), Себер (1598) ханлыгы һәм әкренләп бүтән халыклар белән бөтен Себер җире. Соңга таба Касыйм ханлыгы бетерелә (1681), тырыша торгач, Кырым ханлыгын да яшәүдән туктаталар (1783). Шуннан китә... Балтик Буе (1721 дән 1815 елга кадәр), Көнбатыш Украина һәм Молдова (XVIII йөз ахыры — XIX йөз башы), Кавказ арты, ягъни Азәрбайҗан, Әрмәнстан һәм Грузия (1803—1864 еллар), төрле чорларда — XVIII йөздән алып XX йөз башларына кадәр Казахстан һәм Урта Азия. Болар барысы да, соңыннан алдап «добровольное присоединение к России», ягъни «Россиягә ирекле кушылу» дип аталса да, чынында кайда ялган дипломатия, кайда ут һәм кылыч белән, ә мөселман җир-

---

[1] Даталар, чыганаклардагыча, барысы да иске стильдә алындылар: 2 нче октябрь бүгенге календарь белән 15 октябрьгә туры килә.

[2] Армандәсе — теләге, өмете.

ләрендә исә икенче кулга тәре дә тотып басып алынган җирләр.

Тагын да күбрәк, шул яулап алу сәясәтенең бөтен асылын һәм психологиясен тирәнрәк белергә теләгән кешеләргә мин, күп санлы әдәбият тәкъдим итеп тормыйча, без гомер-гомергә табынып үскән һәм бөтен дөреслекне алардан эзләгән, чынында да зур акыл ияләре булган Маркс белән Энгельсның ике генә хезмәтен укып чыгарга киңәш бирер идем: аларның әсәрләренең 22 нче томына кертелгән «Рус царизмының тышкы политикасы» дигән хезмәтне (Ф. Энгельс) һәм ул томнарга кертелмәгән, бервакытта да Россиядә дә, соңгарак СССРда да басылмаган һәм басыларга, укыларга куркыныч булган, 1899 елда Лондонда инглиз телендә дөнья күргән А. Маркснын «XVIII йөзнең яшерен дипломатиясе» дигән әсәрен. Бу пычрак сәясәт, бу ялган дипломатия чынында Россия хакимиятенең дәвамы булып барлыкка килгән һәм бөтен дөньяда «тынычлык терәге» дип аталган СССРда дәвам итә: инде бәйсезлек алган Балтик буен, Көнбатыш Украинаны һәм Көнбатыш Белоруссияне янәдән басып алу (1939—1940 еллар), Венгриягә (1956), Чехо-Словакиягә (1968) армия кертү. Ниһаять, безнең барыбызның да күз алдында барган Әфган сугышы, шунда бер миллион әфганлыны юк итү, тагын да бер миллионын яралау, дүрт миллионын йортсыз-җирсез калдыру һәм шул вәхшилекне «интернациональ бурычны үтәү» дип атау...

Әйе, 1552 елдан башлап утсыз һәм утлы корал белән, башта кулга тәре тотып, соңыннан коммунизм төзү максатында «интернациональ бурыч» үтәлә! Ул пычрак эшләр өчен турыдан-туры җавап бирергә тиешле Иван Грозныйлар, Петр Беренчеләр, Елизаветалар, Екатериналар, Николайлар һәм Александрлар, Сталиннар, Брежневлар, тагын әллә кемнәр бүген юк. Ләкин әле җимерелә башласа да, бөтенлеге, «бөеклеге» өчен бернәрсә алдында да туктап калырга җыенмаган, үзенең «Памяте», атаманлы казаклары, иң элек татарга каршы булган сакаллы «демократ»лары белән, коточкыч зур армиясе һәм территориясе белән көчле Россия, Жириновскийлар бар...

Әмма башкасы да бар! Элеккеге СССРда гына түгел, «монолит» Россиянең үзендә үк күтәрелеп, көннән-көн көчәя барган милли-азатлык хәрәкәте бар, халыкның күп-



Әстерхан ханнарының таҗы. Мәскәүнең Дәүләт кораллар палатасында саклана

челеге белән бәйсезлек өчен «әйе!» дип җавап биргән Татарстан бар, аңа карап торучы читтәге миллионлаган милләттәшләребез бар, шул ук Грозныйлар, Сталиннар тара-

фыннан изелеп тә бүген уяна башлаган бүтән халыклар бар. Тарихи дөреслек бар, дүрт гасырдан артыкка сузылган инкыйразның бөтен дәһшәтлегеи, куркынычлыгын аңлау бар, бүгенге вә тагын да күп гасырларга калырлык Бөек хәтер бар!

«Мирас»,
1992, 10 сан.

ӘСТЕРХАНГА БАРСАҢ[1]...

Әстерханга барсаң, бар Казаннан,
Мәскәүләрдән юллар әйләнгеч...

Татар халык җыры

Әстерхан ханлыгы Олы Урда ханы Кече Мөхәммәтнең улы Мәхмүт тарафыннан оештырыла, һәм шуннан Түбән Иделдә татар ханнарының яңа нәселе — династиясе башлана. Мәхмүт хан акчалары Әстерхан, Үкәк, Дәрбәнд, Урда-Базар шәһәрләрендә сугылганнар. Әстерхан ханлыгының башлангыч чорына караган тарихи чыганаклар күп түгел, әмма ул бушлык соңгы вакытларда табылган бер кызыклы документ белән бераз тутырыла. Аны Истанбулның дәүләт архивында төрек-татар галиме Әгдас Курат табып ала һәм Мәхмүт ханның 1466 елның 10 мартында Төркия солтаны Мөхәммәт II гә язган хаты икәнен ачыклый. Хатның башында Мәхмүт хан әүвәлге Алтын Урданың Төркия белән яхшы мөнәсәбәттә булганын искә төшерә һәм, шул дуслыкны дәвам иткәндә әйбәт булыр иде, ди. Аның хатыннан кайбер юллар: «Моңарчы без мөһим, кичектергесез эшләрнең күп булуы сәбәпле, Сезгә үзебезнең илчебезне җибәреп, Сезне сәламли вә Сезгә исәнлек-саулыклар тели алмадык. Аллаһе тәгалә безнең ике арадагы дуслыкның торгызылуына, аның киләчәктә тагын да яхшырып китүенә хәер-фатихасын бирсен иде».

Алтын Урда тарихының зур белгече Мөхәммәт Сәфәргалиев хатта әйтелгән «кичектергесез эшләр»нең Әстерхан ханлыгын төзүгә бәйле булганлыгын фаразлый, һәм аның ул фикерен кире кагу кыен. Әлеге хаттагы хәбәрләр XV йөзнең 60 елларында Идел тамагында яңа дәүләт булган-

[1] «Ватаным Татарстан» гәзитендә басылды — 1993, 15 гыйнвар. Кыскартылып бирелә.

лыгына шик калдырмый. Сүз уңаеннан әйтеп үтик: Тверь купецы Афанасий Никитин үзенең 1466 елда Фарсыга сәяхәте вакытында Әстерханда туктый һәм аның «патшасы»ның (ханының) «үз урдасы», ягъни дәүләте булганлыгын яза. Афанасий хәзрәтләре ханның исемен атамый атавын, әмма аның белән көрәшкән Касыйм солтанны, ягъни ханзадәне искә ала, шуннан 10 елдан соң, ягъни 1476 елда, Әстерханга Италия сәяхәтчесе Контарини килгән чакта Касыйм инде хан булган була.

Кыскасы: 1460 еллар башында яңа татар дәүләте — Әстерхан ханлыгы оеша. Чыганаклардан күренгәнчә, аның чикләре түбәндәгечә: көнчыгышта — Идел, көньякта — Каспий диңгезе, көнбатышта — Чиркәс таулары, төньякта — Комания, ягъни әүвәлге Дәшти-Кыпчакның үзәк җирләре. Дәүләтнең халкы хайван асраучылык, сунарчылык, балык тоту, тоз чыгару, бакчачылык һәм, әлбәттә, бөтен татар дөньясына хас булганча, сәүдә белән шөгыльләнгән. Ханлыкның башкаласы Әстерхан шәһәре 1436—1452 елларда татарның көньяк җирләрендә яшәгән атаклы итальян сәяхәтчесе һәм сәүдәгәре Йосифат Барбаро һәм 1517, 1523 елларда Мәскәүдә булып, татарлар хакында бай мәгълүмат туплаган немец илчесе һәм сәяхәтчесе Сигизмунд Герберштейн хезмәтләрендә «бөек татар базары» дип атала. Түбән Иделнең ул замандагы зур сәүдә үзәге буларак, Әстерхан читкә ефәк, мех, тире, кыйммәтле балык, башка төрле товарлар чыгарган. Әстерханның сәүдә географиясе, тарихи чыганаклар буенча болай: Казан, Кырым, Россия, Әрмәнстан, Фарсы. Атаклы гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттута Әстерханда әле 1333 елда ук булып (шәһәрнең ул вакыттагы исеме Хаҗитархан), аның XIII йөздә Алтын Урда ханы Бәркә тарафыннан бер хаҗига тарханлык рәвешендә бирелгән авылдан үсеп китүе хакында язып калдырган. Хаҗитархан, күпләргә мәгълүм, Алтын Урдада акча сугу үзәкләренең дә берсе булган.

Әстерхан ханлыгының тышкы сәясәте башта Олы Урдага, ә инде ул 1502 елда таркалгач, Нугай Урдасына һәм Кырым ханлыгына бәйле була. 1552 елда Казан яулап алынгач, урыс гаскәре ике елдан Әстерханны да ала һәм ул вакыттагы хан, Нугайдан килгән Ямгурчыны тәхеттән төшереп, аның урынына Иван Грозныйның вассалы рәвешендә Дәрвиш Галине утырта. Яңа хан 1556 елда Мәскәү

йогынтысыннан чыгарга омтылыш ясый, әмма урыс, яңа гаскәр җибәреп, Әстерхан ханлыгын бөтенләй яулап ала.

Газетабызның былтыргы 31 гыйнвар санында Себер татарларына багышланган «Бергәнеке берәгәйле!»[1] исемле мәкаләдә мин хөрмәтле укучыларның игътибарын бер нәрсәгә юнәлткән идем: Алтын Урда җирендә барлыкка килгән татар ханлыкларындагы очлары-очка бәйләнеп беткән нәселләр, уртак нәселдән килүче ханнар, аларның берсенең бер ханлыкта, туганының яки туганнан туганының икенче ханлыкта утырулары, алай гына да түгел, бер үк ханның ханлыктан ханлыкка, тәхеттән тәхеткә күченеп йөрүләрендә бернинди тылмачка мохтаҗ булмаулары сәяси генә түгел, гомуми этник берлек хакында сөйли. Мисалга Олы һәм Кече Мөхәммәтләр, Дәүләтбирде һәм Гыязетдиннәр, Сәхибгәрәй һәм Сафагәрәйләр, ханбикәләрдән Нурсолтан һәм Сөембикәләр, бәкләр бәге булган Нугай һәм Идегәйләр һ. б. бик күпләр китерелде. Мин бу фикеремне бүген дә кабатлыйм һәм иң соңгы мисалларның берсе итеп быелгы 440 нчы Хәтер елында Казанның соңгы ханы, Әстерхан ханзадәсе Ядегәрне олылап искә алам.

Әйе, алар берсе дә күрше ханлыкта, күршесенең күршесе булган башка татар дәүләтләрендә тәрҗемәчеләрдән файдаланмаганнар. Ханнар һәм ханбикәләрнең, ханзадәләр һәм карачы-биләрнең, аларның күп санлы яраннары (свита) һәм гаскәриләрнең, вәкаләтле һәм һәртөрле вәкаләтсез илчеләрнең Казаннан Кырымга, Себердән Нугайга, Әстерханнан Бакчасарайга яки Казанга барганда тәрҗемәчедән файдаланганлыгы хакында тарихта бер генә бөртек тә хәбәр юк. Булсын сәүдәгәр, булсын һөнәрче, булсын башка төрле агай-эне, Бараба далаларыннан гүзәл Кырымга яки Казаннан Каспий буйларына килеп чыкканда тылмачка мөрәҗәгать итмәгән, кыскасы, татарга татар җирендә татар белән сөйләшү өчен тылмач кирәкмәгән...

Моның шулай икәнлегенә мин утыз елдан артык тарихи чыганакларны җентекләп өйрәнеп кенә түгел, ә Татарстаннан читтәге төбәкләрнең дә бик күп авыл вә шәһәрләрендә булып, татарның төрле этнографик төр-

---

[1] Шушы китапның «Бердәмлектә — көч» дигән бүлеген кара.

кемнәренә караган күп санлы кешеләре белән сөйләшеп, алай гына да түгел, Америкада булып, дөньяның төрле почмакларыннан җыйналган татарлар белән якыннан аралашу нәтиҗәсендә инандым. Борынгы Болгар һәм Сарай тирәләрендәге татар авыллары, туган җирем Казан арты, Тау ягы, мишәр җирләре, Башкортстан, Көнбатыш Себер, Касыйм, Кырым, һәм менә Әстерхан, шул җирләрдә борын-борыннан яшәп ятучы төрле яшьтәге, төрле фигыльдәге кешеләр — гап-гади әби-бабайлар, абый-апалар, яшьтәшләр, энекәшләр, сеңелкәшләр, сабый балалар... Гадәти диалекталь, мәдәни һәм антропологик үзенчәлекләр булса да, бер үк тел, бер үк матди вә рухи мәдәният, бер үк гореф-гадәт, болай гына әйтеп бирүе кыен булган, әмма әүвәл-әүвәлдән безнең татарга хас булган моң, сагыш, нечкә күңеллелек, аны башкалардан аерып һәм әллә кайдан күзгә ташланып торган чисталык, пакьлек, эшкә әвәслек, күндәмлек, ниһаять, бөтен бер татарны бүген берләштереп торучы аның борынгы, кодрәтле вә матур исеме — «татар» исеме.

Әстерханга барсаң, дустым, әйләнгеч юллардан, читят җирләрдән — Мәскәүләрдән йөрмә, тот та туп-туры Казаннан бар: телисең икән, поездда чабасың, бик ашыксаң — самолетта очасың, ә инде җәйнең матур көннәрендә вакытың булып, борынгы татар җирләренең матурлыгын күреп, чал Иделнең гүзәллегенә хозурланып, ял итеп барасың килсә, Казан-Әстерхан пароходына утырасың...

Шулай итеп, бүгенге котырган акчалардан курыкмыйча, халәтеңә карап кесәңне бераз калынайта төшеп, сәфәргә чыгып китә алсаң, Идел тамагында урнашкан борынгы татар шәһәре Әстерханны тамаша кыл. Шәһәр буйлап сәяхәтеңне мәчеттән башла, анда сәдакаңны биреп чыкканнан соң татар базарына юл тот, инде безнең якларда онытылып бара торган әүвәлге базар дөньясының һавасын сулап, татар агайлары белән дөнья хәлләрен сөйләшеп тор. Узышлый тагын бер базарга — «балык базары»на да сугыл, тере сазан һәм кипкән балык — вобла сатып ал, әлләни кыйммәт түгел, өеңә алып кайтырга һәйбәт күчтәнәч булыр. Татар иҗтимагый үзәгенең Әстерхан бүлегенә һәм «Идел» газетасы редакциясенә дә

кереп чыгарга онытма — әллә нихәтле яңалыклар ишетерсең, күп гыйбрәтләр алырсың.

Баргач-баргач, Әстерханның үзе белән генә чикләнмичә, далаларына чыгып, татар вә нугай авылларын да тамаша кыл. Тукайлар, Рәмиевләр замандашы булган, бераз гына наив, әмма сагышка, моңга бай татар шагыйрәсе, Әстерхан җирендә, борынгы Сарай калдыкларыннан ерак түгел, Идел буенда туып-үскән Газизә Сәмитованың туган авылы Ташлыярга да кереп чык. Аның замандашларының бүгенге оныклары булган әби-бабайлар белән сөйләшсәң, шагыйрәнең төрле шигъри юлларындагы сүзләргә тагын бер кат инанырсың:

Бармагына кигән алтын йөзек —
Казан кызларының бүләге.
Йөзеккенәңне ки дә чык урамга,
Янсын дошманнарның йөрәге.

. . . .

Әлхәмделиллаһи безнең җиремез.
Саг-сәламәт микән сезнең иленез?
Сагыштан үлмәгә йиттек, беленез:
Быел, зинһар, кунак булып килегез.

ҖИРЕБЕЗНЕҢ АЛТЫН УРТАСЫ[1]

Йорт[2] алар (татарлар) телендә урда
дип атала һәм урта дигәнне аңлата,
чөнки нәкъ аларның уртасында урнашкан...

Г. Рубрук, XIII йөзнең 50 елларында Алтын Урдада булган Фламандия сәяхәтчесе

Татар халкының урта гасырлар тарихы битләреннән гаделсезгә төшереп калдырылган, әмма бик игътибарга лаек олуг тарихы бар. Ул — Алтын Урда дәүләте тарихы. Алтын Урда (Җужи олысы) 1243 елның башында Бату хан, Венгрия якларыннан яудан кайтып, Идел буйларында

---

[1] 1993 елның 9—10 августында Казанда уздырылган «Алтын Урда: тарихы вә мәдәнияте» иселме Халыкара фәнни конференциядә сөйләгән докладның язмасы. «Ватаным Татарстан» гәзитенең 1993 ел, 13 август санында басылды.

[2] Монда — Алтын Урда ханының йорты, дөресрәге чатыры, ставкасы мәгънәсендә.

төпләнеп алгач, төзелә. Озакламый ул, Монгол империясеннән аерылып чыгып, мөстәкыйль дәүләт статусын ала һәм чын мәгънәсендә Евразиянең иң зур сәяси берләшмәләренең берсенә әверелә.

Алтын Урданың дәүләти мәйданы заманы өчен дә, бүгенге үлчәмнәрдән чыгып караганда да бик зур: көнчыгышта Иртеш елгасыннан — көнбатышта Кырымга, вакыты белән Дунай ярларына кадәр, төньякта Болгар һәм Казан киңлекләреннән — көньякта Хаҗитарханга һәм Дәрбәндкәчә сузыла. Бу олуг дәүләт үзе ике зур олыска бүленеп, көнбатыштагы иң зур өлеше — Ак Урда (Алтын Урда үзе), көнчыгыштагы кечерәк җирләр, ягъни Урта Азиянең һәм бүгенге Казахстанның көнбатыш өлкәләре — Күк Урда дип аталганнар. Бу бүленешнең нигезендә элек кыпчаклар белән угызлар арасыннан узган кабиләара чик ята.

Әгәр дә Алтын Урданы төзүчеләр булып чыңгызлы монголлар саналса, дәүләтнең төп халкын җирле, кардәш төрки кабиләләр — кыпчаклар, шулай ук болгарлар, угызлар, хәзәрләрнең токымнары, маҗарлар һәм Урта Азиядән күченеп килгән төрки телле татар кабиләләре тәшкил иткән. Татарларның бер өлеше көнбатышка әле монгол яулары башланганчы ук күченеп киләләр, ә икенчеләре исә XIII йөзнең 20—40 нчы елларында Чыңгыз хан һәм Бату хан җитәкчелегендә Көнбатыш Себерне һәм Көнчыгыш Европаны яулап алуда катнашалар. Шушы җирләргә хуҗа булганнан соң, 1242 елда монголларның төп көчләре кире үз илләренә, Үзәк Монголиягә кайтып китәләр, ә яуланган көнбатыш олыс белән идарә итү өчен Бату белән бергә бары тик 4 мең монгол хәрбие — ханның якыннары, югары дәрәҗәле гаскәр башлыклары кала. Ләкин алар да тиз арада — XIII йөз ахырларына таба — күп санлы төрки кабиләләр арасында йотылып бетәләр. Татарлар исә, киресенчә, үзләренә кардәш кыпчаклар белән катнашып һәм элеккеге төрки кабиләләрне (болгарларны, маҗарларны һ. б.) үзләренә алып, катнаш татар-кыпчак суперэтносы төзиләр. Бу зур этносны мәшһүр Л. Гумилев татар суперэтносы дип атаган иде, мин аңа башлангыч чор өчен кыпчак этнонимын да кушарга батырчылык итәм. XIV гасыр ахырына таба соңгысы, ягъни кыпчак исеме, әкренләп төшеп кала. XV йөз башыннан ул зур халык татар

дип кенә атала башлый һәм Алтын Урда таркалгач барлыкка килгән Казан, Кырым, Себер, Әстерхан, Касыйм ханлыкларында шушы татарлар халыкның төп өлешен тәшкил итәләр.

Һич арттырмыйча әйтергә була, яшәешенең куәтенә ирешкән чорында, ягъни XIV йөздә, бигрәк тә аның беренче яртысында, Алтын Урда белән тиңләштерерлек дәүләтне шул чор Евразия дөньясыннан искә төшерүе кыен булыр. Дөнья сәясәтенең игътибар үзәгендә торуы, хәтта шул сәясәткә тәэсир итә алу көче ягыннан аннан элегрәк яшәгән Габбасилар дәүләте (Багдад хәлифәлеге) белән генә чагыштырып булыр иде. Менә шушы олуг дәүләт искиткеч зур матди һәм рухи мәдәнияткә ия булган. Алтын Урда мәдәниятенең күчмә һәм шәһәр культураларының классик кушылма-симбиозы булганлыгына моңарчы игътибар ителде. Монда шуңа гына басым ясап үтик: бу кушылманың һәр ике төре дә төрки дөнья тудырган гаҗәеп бер байлыкның ачык чагылышы булып тора.

Алтын Урда шәһәр культурасы урта гасырлар цивилизациясенең бәһа биреп бетерә алмаслык өлеше саналган. Сарай, Гөлстан, Сарайчык, Үкәк, Бәлҗәмин, Болгар, Хаҗитархан, Үргәнеч, Мажар, Азак, Кефе (Феодосия), Судаг, Кырым (Солхат), Ак Кирмән, Ак Мәчет, башка шәһәрләр, һөнәрчелек һәм сәүдә үзәкләре буларак, һич арттырусыз, Шәрык дөньясына билгеле булганнар, дан тотканнар.

1333 елда Алтын Урданың күп шәһәрләрен үз күзләре белән күргән, кайберләрен аркылыга-буйга йөреп чыккан атаклы гарәп сәяхәтчесе Ибне Баттутаның дәүләтнең башкаласы Сарай шәһәре хакында язып калдырган сүзләре күпләргә мәгълүм: «Сарай шәһәре тигез җирдә урнашып, матур базарлар һәм киң урамнардан торган, кешеләр белән тулган гадәттән тыш зур һәм иң матур шәһәрләрнең берседер». Сәяхәтченең әйтүенчә, анда җамигъ мәчетләр генә дә унөч, ә башка төрлеләре гаҗәеп күп икән.

Гарәп, гомумән, Шәрык дөньясының күп атаклы үзәкләрендә булган шушы укымышлы затны гомерендә беренче тапкыр кала күргән авыл кешесенә тиңләп булмый, әлбәттә. Әле бит ул Сарай шәһәрен тасвирлау белән генә чикләнми, үзе булган ун шәһәрнең һәрберсенә гадел бәясен

бирә. Маҗарны, мәсәлән, төрки шәһәрләренең иң күренекләреннән, ди. Идел тамагында урнашкан Хаҗитарханны зур базарлары булган атаклы шәһәр дип атый, Үкәкнең матур йортларын күреп соклана һ. б.

Көнчыгышның башка төрки чыганакларына, шулай ук Европа тарихи-географик әдәбиятына тукталып үтәргә вакытыбыз булмаганлыктан, мин Алтын Урда чорына кадәр төрки дөньяда әле бер җирдә дә, беркайчан да булмаган дала урбанизациясенең кинәт, ифрат зур күтәрелеш алуына басым ясап үтәм. Бу урбанизация, бу шәһәрләшү процессы шәһәрләрнең, алардагы халык санының кинәттән артып китүе белән билгеләнә, аның бөтен төрләренең дә искиткеч зур үсеш алуында, ул шәһәрләрнең халыкара сәүдәдә төп позицияләрне тотуында ачык чагылыш таба.

Алтын Урда шәһәрләрендә гаҗәеп зур үсеш алган һөнәрчелек, аның иң әһәмиятле һәм иң таралыш алган төрләре, мәсәлән, архитектура-төзелеш, ювелир сәнгате, металлургия, корал эшләү, нәфис керамика, таш кисү, пыяла өрү — болар һәммәсе үзләренең эшләнү осталыгының затлылыгы, югары сәнгати зәвык кануннарына җавап бирә алулары белән дала һәм урман-дала Евразиясенең Алтын Урдага кадәр дә, аннан соң да булган мәдәнияте өчен чын мәгънәсендә үрнәк булып саналалар. Алтын Урда чорында — булсын үзәк олысының, булсын аңа буйсынган элеккеге цивилизация учакларының матди вә рухи мәдәнияте искиткеч зур, ә кайбер тармакларда тамырдан үзгәрешләр кичерә. Монументаль төзелеш, мозаика һәм майолика архитектурасы, калын ялтыравыклы, затлы савыт-саба, нәфис бизәкләү сәнгате, сусаль алтын техникасы куллану һ. б. күптөрле казанышлар, гомумән, Алтын Урда чорына карый. Боларга урта гасырлар татар дөньясында киң таралыш алган башка төрле яңалыкларны өстәп китү зарури: икътисади вә сәяси тотрыклылык, хәрби осталык, чик саклау, тамгачылык (таможня), салым җыю эшендәге эзлеклелек. Әлбәттә, болар һәммәсе дәүләтнең иң куәтле чагына, мәдәниятенең чәчәк аткан дәверенә карыйлар.

Алтын Урда цивилизациясе турында сөйләгәндә, урта гасыр татар әдәбиятының ядкәрләрен санап үтми һич мөмкин түгел. Сүз иң беренче чиратта Котбның «Хөсрәү вә Ширин», Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә», Хисам Кятибның

«Җөмҗөмә солтан», Сәйф Сараиның «Гөлстан» («Китабы «Гөлстан бит-тәрки»), «Сөһәйл вә Гөлдерсен» поэмалары, Насретдин Рабгузиның «Кыйссасел-әнбия» һәм Мәхмүт Галинең «Нәһҗел-фәрадис» исемле чәчмә әсәрләре хакында бара.

XIV йөздә һәм күбесе Сарай шәһәрендә язылган бу әсәрләрнең теле, белгечләрнең раславынча, Идел буе төркисе, ягъни урта гасырларның әдәби татар теле, алар — күп гасырлык әдәбиятыбызның асыл җәүһәрләре. Алтын Урданың нечкә хис вә тирән фәлсәфәгә нигезләнгән бай язма әдәбияты буенча тагын шуны ассызыклап үтәсе килә: бу әдәбият буш урында тумаган, аның борынгырак дәверләр, әйтик, Төрки каханлыгы, Караханилар дәүләте, Болгар чоры поэзиясеннән килүче бай традициясе бар. Бәркә хан (1258—1266) заманында кабул ителгән, Үзбәк хан идарә иткән чорда (1312—1342) дәүләт диненә әверелгән ислам дине һәм аның белән бергә кергән гарәп язуы Алтын Урда әдәбиятының чәчәк атуына искиткеч зур йогынты ясаганнар, алай гына да түгел, гарәп язуы әлеге әдәбиятның чын мәгънәсендә язма нигезен тәшкил иткән. Мәгълүм ки, бу әдәбиятның үсешенә күрше төрки халыкларның, мәсәлән, азәрбайҗан, Урта Азия төркиләре әдәбиятының да йогынтысы булган, хәтта кайбер әсәрләр ирекле, иҗади тәрҗемә рәвешендә дә туганнар. Әмма Алтын Урда әдәбияты — үзенең туувы, үсеше һәм халык күңелендә саклануы, гомумән, теле, аның байлыгы, грамматик калыплары белән чын мәгънәсендә татар әдәбияты. Юкка гына бу әдәбият, XIV йөзнең шигърият җәүһәрләре, татар поэзиясенең даһилары булган Тукай белән Дәрдмәнднең илаһи иҗатына зур йогынты ясамаган. Ә Тукай белән Дәрдмәнд — бөтен татар шигъриятенең иң бөек вәкилләре алар. Рөхсәт булса, фәкыйрегез ике генә мисал китерер иде. Хәрәзминең «Мәхәббәтнамә»сендәге мөнәҗәттән:

Иляһи, йакты кыйлгыл җанымызны,
Хәләлдән саклагыл иманымызны.
Текәндин, кьөдрәтең, пәйда кылыр гөл,
Хата күб килле мән коллдин, кичергел.

Кемгә ничектер, минем үземә бу сүзләрдән соң Ту-

кайның бөек «Туган тел»ендәге өзелеп әйткән сүзләре искә төшә:

> И туган тел, синдә булган иң элек кыйлган догам.
> Ярлыкагыл, дип, үзем һәм әткәм-әнкәмне, ходам.

Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан»ындагы:

> Бу кара тупрак эчендә ничәләр
> Йатырлар ошбу төн, көндез, кичәләр.
> Кеме солтан, кеме кол, кеме әмир,
> Кеме хуҗа, кеме бай, кеме фәкъир...
> Кеменең тупракын йилләр сүүреб,
> Кеменең сөнгәкләре көнгә корыб...—

дигән сүзләрне уку белән, мин, тарихчы һәм археолог буларак, Дәрдмәнднең «Каләмгә хитаб» шигырендәге әрнү тулы сагыш сүзләрен искә төшерәм, Болгар, Сарай, Казан, Бакчасарай шәһәрләрен саклаганда шәһид булганнарны күз алдымнан кичерәм:

> Бабалар кабре янында күңел зар,
> Аталар рухының армандәсе бар...
> Кара тупрак тулы мәзлум нидасы,
> Алар кемдер?.. Алар кемнәр фидасы?..

Мөхтәрәм әдәбият белгечләре мине гаеп итмәсеннәр иде, үзләреннән башка аларның бакчасына кереп, җимешләрдән авыз итеп вә хозурланып йөрүгә мин һич кенә дә батырчылык итә алмыйм. Әмма рухи мәдәният ул матди культураның тирән фәлсәфи һәм нәфис сәнгати чагылышы дип әйтергә бөтен хакым бар, гафу итегез, дистә еллар буе татар халкының күп гасырлык сәяси һәм этномәдәни тарихын өйрәнүче белгеч буларак вәкаләтем, хакым бар. Алтын Урданың югарыда кыскача гына бәяләнеп үтелгән олуг мәдәниятенең ике төп тармагы — матди һәм рухи культура, бер-берсе белән табигый, аерылмаслык бәйләнгән хәлдә, урта гасырлар цивилизациясенең, моңарчы кара көчләр тарафыннан җуярга тырышып та җуелмаган, иншалла, һич тә җуелмаслык ачык чагылышы булып, гасырлардан килеп, гасырларга калырлык горурлыгы булып торалар.

Әле бит безнең язма әдәбиятыбыздан башка, тагын да борынгырак, халыкның бөтен рухи халәтен, аның моңсагышларын, гасырларда җырларлык батырлыкларын үзендә туплаган гаҗәеп бай авыз иҗаты әсәрләребез бар. Гомер-гомергә болар үзләреннән соң булган шигърият-

кә — урта гасырларныкымы ул, әллә яңа чорның күтәрелеш әдәбиятымы — җан азыгы, тирән фәлсәфи моң биргәннәр. Әгәр дә мин башта Дәрдмәнднең:

Ни газизрәк — бу ватанмы?
Аh, туган каүмем газиз!
Ул мөкатдәс кан белән ул
Изге сөткә ни җитәр!..
Сөт калыр, ватан китәр!
Сөт калыр, ватан китәр! —

дигән, әле моңарчы бер генә шагыйрьдә, бер генә әдиптә дә очрамаган тарихи-эпик философиясен үземнең беркатлылыгым белән аңлап җиткерә алмаганмын икән, алар минем картая башлаган зиһенемә, мәшһүр «Идегәй» дастанын кабат укыгач, барып җиттеләр:

Җир китәрдә ни калыр?
Җиреннән тайган ил калыр;
Ил китәрдә ни калыр?
Ил киткәндә йорт калыр,
Йорт китәрдә сөт калыр,
Ак күкрәктән сөт имгән
Сүзе татлы тел калыр.

Мин боларны чыгышлары белән Үзәк Азия далаларыннан булган борынгы төрки татарларының — ә шул ук далалардан сөннәр-һуннар, алар белән бәйле булган, бүгенге татарның этносәяси тарихында якты эз калдырган болгарлар, хәзәрләр, соңра кыпчаклар һ. б. да килгәннәр — бай вә гыйбрәтле тарихларын якыннан өйрәнгәннән соң аңладым. Мин бу тарихи дөреслеккә чыгышлары белән татар җиреннән булып та, нужа бабай куып йөртеп, ватаннарын берничә кат алыштырган, бүген чит-ят җирләрдә, океан артында яшәп ятучы, әмма ана сөте имгән телләрен, шул сөт вә изге кан белән гомергә билгеләнеп куелган милли тамырларын, татар булуларын онытмаган һәм балаларына, оныкларына да оныттырмаган кан-кардәшләремне күреп кайтканнан соң инандым.

Кайбер академик фикерле, ортодоксаль тарихчы-галимнәр мине хисләргә, эмоцияләргә бирелүдә гаепләрләр. Әмма гасырларның кырыс кешесе Ленин үзе дә эмоцияне кеше хисенең гадәти чыгышы дип атаган иде, ә галимнең, тарихчының хисе — гасырлардан килгән дөреслекне бөтен ачылыгы, бөтен гыйбрәте белән аңлап, шул дөреслеккә

каршы алып барылган ялган сәясәтне әрнүле йөрәгең аша уздыру ул. Әлеге шул сәясәттән, тоталитар идеология сөременнән һич котыла алмаган, татарның борынгы тарихына, Алтын Урда дәверенә хыянәтчел ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы хыянәтчел карары күзлегеннән карап фикер йөртергә, дөресрәге, фикерсезлеккә өйрәнгән агайлар вә энекәшләр мине Алтын Урданы идеаллаштыруда гаепләрләр. Без ул гаепләүләрне даими ишетеп һәм шулар белән көрәшеп газиз гомерләребезне уздырып баручы, әмма бераз соңарып булса да хөр фикер заманына килеп кергән буын. Сүз идеаллаштыру, тарихны күпертеп күрсәтү турында түгел, ә «идеаллаштырасыз» дип дистә еллар буе өстән тукылып торган һәм әле бүген дә шуның чаткылары сүнмәгән, мәгънәсез сәясәткә каршы законлы рәвештә туган реакция, идеаллаштырмаган, киресенчә, җәберләнгән, мыскыл ителгән, каһәрләнгән тарих турында бара. Ә Алтын Урда тарихы, аның гаҗәеп бай матди һәм рухи мәдәнияте, исемен җисеменә туры китереп әйткәндә, цивилизациясе — дөнья тарихының, дөнья цивилизациясенең аерылгысыз өлеше; бу өлеш аның бөтен яшәеше, бөеклеге вә тарихи фаҗигасе белән билгеләнә.

ФАҖИГАЛЕ ТАРИХНЫҢ СӨЕКЛЕ ХӘТЕРЕ

Үзең өчен ни сөекле булса,
шуны халык өчен дә сөекле ит.

(Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләреннән.)

Мин бу язмамда татарның тарихи хәтерен саклауның кайбер мөһим мәсьәләләре хакында сүз алып бармакчы булам. Әмма аларга күчкәнче шул хәтерне халкыбызның йөрәгенә мәңгегә сеңдереп калдырган әрнүле вакыйгаларга мөрәҗәгать итмичә һич мөмкин түгел. Болар — 1552 елның көзендә Казанның урыс тарафыннан яулап алынуының сәбәпләре хакында минем тарихчы буларак ясаган нәтиҗәләрем. Алар моннан 442 ел элек булган дәһшәтле көннәрне тирән кайгы белән искә алып үтү өчен генә ясалмадылар, ә бүгенге көн һәм киләчәк өчен зур гыйбрәт булсын, дигән максатны да күз алдында тотып эшләнделәр.



1552 елда Казанны алу күренеше — Н. Рерихның 1911 елда язган картинасыннан Н. Хаҗиәхмәтов күчереп ясаган рәсем. Аста — татар һәм урыс сугышчыларының бәрелеше, унда — туплары белән урыс лагере

Соңгы вакытта кайберәүләр Казанның 1552 елда җиңелүен татарның күбрәк үзенә кайтарып калдырырга итәләр, ягъни фаҗиганең төп гаебе үзебездә, диләр. Бу фикер әле шушы көннәрдә генә, Казан ханлыгының фаҗигасенә һәм сабакларына багышлап уздырылган бер җыелышта, кайбер тарихчы һәм язучыларның шунда ясаган чыгышларында шактый күперенке яңгырады. Әлбәттә, шул чакта татарның үзенең дә гаебе булган, һәм ул бүгенге һәм киләчәк буын өчен ачы гыйбрәт булып кала — бу сәбәп турында без түбәндә әйтербез. Әмма 1552 елгы фаҗигане халыкның күбрәк үзенә кайтарып калдырырга тырышу, татарны кара канга батырган явыз көчне арткарак этәрү, алай гына да түгел, әлеге көчнең вәхшилеген, 1552 нче елдан соң бөтен татар дөньясын һәм башка халыкларны да басып алган иң кара империянең каралыгына күз йомарга тырышу булыр иде. Моннан дүрт гасыр ярымга якын элек булган зур җиңелүне татарның үзенә кайтарып калдыру 1552 елда бирелгән меңләгән корбаннарның җаннарын мыскыллау булып яңгырый.

Казан ханлыгы җимерелүнең төп, иң куркыныч сәбәбе — татарның шул замандагы иң явыз көч булган Урыс империячел дәүләте, аның иң пычрак сәясәте белән йөзгә-йөз очрашуы. XII гасырдан ук көнчыгышка булган һөҗүм-

нәре белән аерылып торган Урыс дәүләтенең тышкы сәясәте XVI йөзнең 40 нчы елларыннан ачыктан-ачык экспансионистик, татар җирләрен басып алу юлын тота. Җитмәсә, шушы сәясәтне оештырып җиткерүдә мөселман дөньясына, татарга карата үтә дә дошманлык күрсәткән сугышчан православие чиркәвенең роле искиткеч зур була. Әлеге чиркәү җитәкчелеге тудырган шовинистик, карагруһчыл публицистикадагы, хроника һәм елъязмалардагы «басурмане», «антихристы», «нечестивцы», «поганые», «татарва», «мерзость казанская» кебек сүзләр, Казан ханлыгын яулап алырга чакырган өндәмәләр (шул заман идеологларыннан И. Пересветов, урыс чиркәвенең һәм патша хөкүмәтенең башлыгы митрополит Макарий эшчәнлеге) урыс җәмәгатьчелеген татарга каршы күтәрүдә зур көч була. Язмыштырмы, юктырмы, әмма Татар дәүләте, дәүләтчелеге иң зур яулап алулар белән башланган XVI йөзнең корбаны була. (Йа Раббем, вакытлы булсын!) Нәкъ менә XVI гасырда Көнбатыш Европа Американы, ә Урыс дәүләте татар дөньясын һәм аның аша Азияне яулап алуны башлый.

Әмма шул ук вакытта Казан ханлыгының XVI йөзнең уртасына кадәр әлеге зур көчкә каршы тора алырлык, хәтта җиңәрлек тә үз көче була. 1469, 1506 һәм 1524 елларда Ибраһим, Мөхәммәтәмин һәм Сафагәрәй ханнар җитәкчелегендәге татар гаскәре урыс армиясен тар-мар китерә. Ә менә 1552 елда, шул вакыйгалардан үзгә буларак, бөтен ханлыкның җыелма гаскәре, гомумән, урта гасырга хас булганча, ополчение армиясе туплана алмый, чөнки шуннан бер генә ел элек Казаннан ерак та түгел Свияжск крепосте төзелеп, бөтен илнең көнбатыш яртысы Мәскәү тарафыннан тартып алынган, дәүләтнең иң зур су һәм коры җир юлларын дошман контрольгә алган һәм илнең башкаласы Казан шәһәре камалышта калган була. Димәк, җиңелүнең икенче зур сәбәбе — дошман һөҗүмен кире кага алырлык көч, бөтен илнең гаскәре җыйнала алмау. Ә 1552 елның көзендә урысның 150 мең кешелек армиясе белән сугышкан 30 мең татар — бу илнең җыелма гаскәре түгел, ә Казан шәһәренең гарнизоны гына (чагыштыру өчен: шул ук елның сентябрендә басып алынган һәм Казаннан бермә-бер кечкенә булган Арча шәһәренең 15 меңлек гарнизоны була). Дөрес, Казаннан көнчыгыштарак

Япанчы би җитәкчелегендә бер ополчение баштарак хәрәкәт итә, әмма ул да әле шул тирәдә генә тупланган аерым бер гаскәри төркем генә була. Һәм ул тиз арада тар-мар ителә.

Өченче зур сәбәп итеп мин Казандагы утлы корал арсеналының Мәскәү хөкүмәте кушуы буенча кара көчләр һәм сатлыкҗаннар тарафыннан юкка чыгарылуын атыйм. 1551 елның августында урыс кенәзе Василий Серебряный җитәкчелегендәге сугышчан төркем Сөембикәне әсир иткәндә Казанның бик зур байлыгын, шул исәптән дары запасын да алып китә, ә яңа тупланганына Мәскәү куштаны һәм сатлыкҗан Шаһгали 1552 елның февралендә Казаннан киткәндә су салдырта һәм тупларны юкка чыгара — аларның көпшәләренә эретелгән аккургаш тутыртa. 1552 елда, 1524 елгы сугыштан үзгә буларак, Казан тупларының гөрселдәмәве — бик тә аянычлы хәл, һәм 150 туптан торган урыс артиллериясе бернинди каршылыкка очрамый. Бу да — җиңелүнең зур сәбәбе.

Дәүләтнең иминлеген саклауда бик тә мөһим булган чорда, ягъни, 1540 нчы елларда һәм 50 нче еллар башында, татарның үзе арасында бердәмлек булмау — менә бу тагын бер зур, дүртенче сәбәп. Явыз Иван хөкүмәте һәм самодержавие чиркәү идеологиясе тарафыннан тудырылган Шаһгали, Киләхмәт, Нугай бие Исмәгыйль кебек сатлыкҗан-ренегатларның үз дәүләтенә, үз халкына каршы алып барган куркыныч сәясәте. Татарның бер өлешенең татарга каршы сугышуын да искә алырга кирәк. Монда сүз Шаһгали җитәкчелегендә Касыйм гаскәре хакында бара. Дөрес, андагы татар сугышчыларының санын кайбер тарихчылар арттырып җибәрәләр, 50 меңгә җиткерәләр. Бу — уйдырма, һәм ул бүген кайбер кара көчләргә татар белән мишәр арасында чөй тыгу өчен бер нигез дә булып тора. Шаһгалинең чынында 3 мең кешедән торган кечкенә генә бер төркеме була.

Ниһаять, соңгысы — Мәскәүнең пычрак дипломатиясе һәм башка хәбис эшләре нәтиҗәсендә Казан—Нугай, Казан—Кырым һәм Казан—Төрек берлегенең тудырылмавы. Шул ук вакытта илнең үзендә һәм аннан тышта да бердәмлек оештыруда Казан дипломатиясенең уңышсызлыгы, көчсезлеге. Татарның кайбер күренекле сәясәтчеләре, дәүләт эшлеклеләре һәм милли хәрәкәт җитәкчеләреннән

Булат һәм Нурали Шириннар, Боерган, Чура Нарык, Кучак, Гәүһәршадларның кирәк вакытта эшлеклелек, фидакарьлек күрсәтә алмаулары, кайберләренең исә, гомумән, сәяси йомшаклыгы, хәтта сукырлыгы. Нәтиҗәдә — иҗтимагый һәм сәяси көчләрнең бердәмлеге тупланмау, хан идарәсе, хөкүмәт һәм милли партияләр арасында каршылыклар туу.

Аянычка каршы, болар — хәзерге татар дөньясына да хас күренешләр, алар — тарихи да, бүгенге дә гыйбрәтләр. Бөек немец философы Гегель әйткәнчә, тарих безне, кызганычка каршы, бернигә дә өйрәтмәде.

Әгәр дә XX гасыр башында татарның үзенең бөек шәхесләреннән Г. Тукай:

Вактында жирне селкеттек,
Инде беттек, инде беттек,—

дип, ә Дәрдмәнд:

Кайсы юллар,
Нинди упкын
Тарта безне жан сорап? —

дип ачынып язганнар икән, ә Гаяз Исхакый исә, гомумән, татарның инкыйразы турында сүз алып барган икән, бүгенге көндә яртысына якыны урыслашып килүче татар дөньясы XX йөзне тәмамлаганда киләчәккә нинди ышаныч белән карый? Бүгенге татарның хәтере әле ул 1552 елның коточкыч фаҗигасен, шунда шәһид булганнарны баш иеп, җан әрнеп искә төшерү генә түгел, ә шул хәтерне яңартып, үзеңнекен халыкныкы, халыкныкын үзеннеке итеп, бөтен тышкы һәм эчке дошманнарга, сатлыкҗаннарга каршы һич курыкмыйча көрәшә алырлык көчләрне берләштерү, нәтиҗәдә, татар халкының нәкъ мең еллык үз дәүләтен торгызу. Сүздә генә, декларатив Конституциядә генә түгел, ә чынында!..

Татар халкының тарихи хәтерен саклау һәм ныгытуның бүгенге мөһим чаралары булып түбәндәгеләр тора дип уйлыйм:

1. Хәтер көнен рәсми рәвештә дәүләт бәйрәме дип игълан итү. Кайчандыр бу теләк республиканың Югары Советында яклау таба алмаган икән, ул мәсьәләне көн тәртибенә кабат (карар кылынганчы!) куярга. Әгәр дә

урысның чиркәүләрен «освящать» итүдә, «святой»ларын зурлап искә алганда Россия Президенты, Мәскәү мэры, Дума депутатлары катнаша икән, татарның Хәтер көнен билгеләп үтүдә Татарстан җөмһүрияте һәм Казан шәһәре җитәкчеләре, халык депутатлары (биш-алтысы гына түгел, ә күпчелеге!) булырга тиеш. Шулай иткәндә генә бу изге эшкә дәүләти юнәлеш бирергә, аны массакүләм чарага әйләндерергә мөмкин.

2. Казан шәһәрен һәм Казан ханлыгын саклап 1552 елда һәлак булган каһарманнарга мемориал-һәйкәл Казан яулап алынуга 450 ел тулган көннән, ягъни 2002 елның октябреннән дә соңга калмыйча төзелергә һәм ачылырга тиеш. Әгәр дә 1552 елда Казанны алганда һәлак булган урыс сугышчыларына һәйкәл төзүне моннан 170 еллар элек, ягъни 1823—1826 елларда патша хөкүмәте үз кулына алган булган икән, бүгенге һәйкәлне төзү эшен дә Татарстан хөкүмәте финансларга тиеш. Моңарчы әлеге изге максатта халыктан җыелган хәер акчасының диңгез тамчысы гына булып калуы бик ихтимал. Бу эшне оештыру һәм ахырына җиткерү өчен Дәүләт комиссиясе төзелергә тиеш.

3. 1551 һәм 1552 елларда Казаннан Мәскәүгә талап алып кителгән әйберләр кабат үз җиренә — Казанга кайтарылырга тиеш. Болар: Мәскәү Кремленең Кораллар палатасында сакланучы Казан ханнарының таҗы һәм башка кыйммәтле байлыклар. Дәүләт тарихи музеенда (Мәскәү) һәм Россия халыкларының этнография музеенда (Санкт-Петербург) тупланган ювелир сәнгате үрнәкләре һәм традицион этнографиягә кагылышлы ифрат та кыйммәтле башка әйберләр. 1552 елда алып кителгән һәм кайдалыгы әлегә билгеле булмаган Казан ханлыгының байрагын, башка төрле регалийларны, Казанның тупларын эзләп табу эшен оештырырга. Мәскәүгә алып китеп чукындырылган һәм андагы Кремльнең Архангель соборында урыс патшалары белән бөек кенәзләренең кабер-саркофаглары арасында ятучы Казан ханы Үтәмешгәрәй (Александр) һәм Ибраһим хан улы Ходайгылның (Петр Ибрагимович) калдыкларын алып кайтып, Казан Кремленә, Сөембикә манарасы янына күмәргә. Боларның һәммәсен дә башкару өчен җитәкчесе премьер-министр урынбасары дәрәҗәсендәге Татарстан хөкүмәт комиссиясен төзергә.

4. 1995 нче елның 1 октябрендә (яңача стиль белән 14 октябрь) Казан ханлыгы төзелүнең 550 еллыгын тантаналы рәвештә билгеләп үтәргә. Шул вакыйгага багышлап халыкара фәнни конференция уздырырга.

5. Казан Кремлен гыйльми реставрацияләүгә 1840 елгы Кремль рәвешеннән чыгып түгел, ә Казан шәһәренең милли дәүләт башкаласы булган чорына ук мөрәҗәгать итеп якын килергә.

Мөхтәрәм укучылар шушы максатта үзләренең дә эшлекле тәкъдимнәрен ясасалар, гомуми эшкә зур файдасы тияр иде.

«Ватаным Татарстан»,
1994, 15 октябрь.

«БӨЕК» РӘСӘЙГӘ БАШ ИЯРБЕЗМЕ?

«...утлы мичтә янарбыз, ләкин ерткыч кыяфәттәге Бөек Рәсәйгә баш имәбез».
Д. Мережковский, урысның диссидент язучысы һәм философы. XX йөз[1]

1. Яңа «демократия»нең «бөек»леге

Бүген Чечня утлы мичтә яна, әмма әлеге шул «бөек Россия»гә баш ими. Әйе, әйе, элеккеге Столыпин һәм Струвеларның, бүгенге Жириновский, Бабурин, Невзоров, Баркашов һәм әлбәттә, Ельцин, Грачев, Лобов, Егоров, Степашин, Ериннарның «бөек» һәм канлы Россиясенә!

Рәсәй Чечняны 1859 елда басып ала, шуннан 85 елдан соң, ягъни 1944 тә, чечен халкы СССР, чынында Рәсәй, җитәкчелеге тарафыннан туган иленнән куыла. Тагын 50 елдан соң — яңа үтеп киткән 1994 елның азагында — әлеге дә баягы шул «бөек Россия» мәйданы ягыннан үзеннән 960 тапкыр, халык саны буенча 150 мәртәбә кечкенә булган Чечня-Ичкерия җөмһүриятенә каршы чын сугыш башлый.

Әйе, саны ягыннан болай да күп булмаган, Сталин-Берия департациясеннән соң тагын да кимеп калган, мең

---

[1] Мережковский Д. С. Еще о «Великой России» // В тихом омуте. Статьи и исследования разных лет.— М.: «Советский писатель» нәшрияты, 1991.— 60 бит.

төрле авырлыклар белән туган-үскән иленә кире кайтып һәм искитәрлек тырышлыклар куеп җирен яңарткан, нәселен арттырган, ниһаять, соңгы вакыттагы гомум уяну-күтәрелештән соң чынлап торып бәйсезлек юлына баскан гаҗәеп батыр һәм горур чечен халкына каршы дөньяның иң зур армиясе булган Рәсәй армиясенең, аның яңа сугыш техникасының көче юнәлдерелде. Соңгы елларда бик мактанып һәм шапырынып бөтен дөньяга үзен демократик дәүләт дип игълан иткән Рәсәй бүген үз территориясендә булган кечкенә генә халыкны, аның җирен һәм башкаласын бомбага тота, ракета, артиллерия утын яудыра, танклар белән таптата, бернинди гаебе булмаган йөзләгән вә меңләгән кешеләрне — чеченнәрне, урысларны һәм башкаларны кыра.

Хәзер Ленинга таянып нәрсәдер әйтү гадәте бетеп китте. Бу шәхеснең кылган эшләре кешелек дөньясына зур зыяннар китерсә дә, әмма язган әсәрләре, бигрәк тә гомеренең соңгы елларында иҗат ителгәннәре, мөһим сәяси һәм фәнни әһәмияткә ия (эшнең сүздән аерылганлыгына зур мисал!). Укып хәтерлисездер, милли мәсьәләләргә багышланган соңгы мәкаләсендә ул, изелгән кечкенә милләтнең милләтчелегеннән изүче зур милләтнең милләтчелеген аера белергә кирәк, дигән иде. Соңгысын куштырнаклар эчендә «бөек» милләт дип атады һәм болай диде: «Хәер ул үзенең көчләве белән бөек, держиморда бөек булган кебек бөек» (Ленин В. И. Әсәрләрнең тулы җыелмасы.— 45 том, 358 бит.— Урыс телендә). Туры атып, төз тидергән сүзләр! Бүгенге Рәсәйнең «демократия»сен мин Ленинга ияреп төшеп, шовинизм демократиясе, держиморда демократиясе дип атар идем.

Димичә! Йә, карагыз: унитар дәүләткә чик куябыз, дигән булып, СССРны юкка чыгарды да, үзен суверен дәүләт дип игълан итте, ләкин аннан үрнәк алып шул ук суверенитет юлына басарга теләгән элеккеге автономияләргә әүвәл идеологик көрәш башлады, шуларның берсенә бүген басып ук керде. Әгәр дә гасыр башында Столыпин белән Струвелар «бөек Россия» империясенә сәяси-идеологик нигез салырга тырышкан гына булсалар, гасыр ахырында бөтен дөньяда колониаль система җимерелеп, шушы бер «бөек» илдә генә калган чорда — әлеге шул черек система бөтен җаны-тәне, теше-тырнагы белән үзенең гомердә булмаган «төзеклеген»,

«изгелеген» («Святая Русь»), «бөеклеген», «байлыгын» һәм, әлбәттә, әлегә танклар көче белән тотып торган «территориаль бөтенлеген» сакларга тырыша.

Әгәр дә 80 нче еллар азагы — 90 нчы еллар башында, ягъни СССР таркалып, КПСС беткән дәвердә, аларның соңгы җитәкчеләре сүз иреге, демократия, суверенитет өчен көрәшә башлаган Казахстан, Азәрбайҗан, Грузия, Литвага эчке гаскәрләр — МВД частьлары гына кертеп, «тәртип» урнаштырган булсалар, бүгенге «демократик» Рәсәй Ичкериягә өр-яңа хәрби техника белән коралланган армия кертте. Кертеп кенә калмады, чын, аяусыз сугыш башлады. Бу вәхшилекне «армия сәясәттән читтә булырга тиеш» дип әллә ничә тапкыр бөтен дөнья һәм Рәсәй җәмәгатьчелеге алдында игълан иткән, «милли мәсьәләләрне чишүдә армия бервакытта да катнашмаячак», дип вәгъдә биргән Рәсәй Президенты һәм кораллы көчләр башкомандующие Ельцин белән оборона министры Грачев эшләде. Йә, шуннан соң да бу «демократия»не нәрсә дип атыйсың?

Без Рәсәйнең башка халыкларны, аларның җирләрен басып алуы турында элегрәк тарих китапларыннан укып белдек, гәрчә ул китапларның күбесе бик тә шомартылып, шул Рәсәйнең бөекдержавачыл сәясәт-идеологиясе яктылыгында язылган булсалар да. Тора-бара, инде дөньяга күзебез ачылып, күп нәрсәгә тәнкыйть аша карарга өйрәнә башлагач, безнең заманда СССР, әйткәнемчә, чынында шул ук Рәсәй дәүләте оештырган авантюраларның нәрсә икәнен аңладык. Искә төшерик: «Бөек Ватан сугышы» (дөресе: Икенче Бөтендөнья сугышы!) тәмамланып 11 ел үтүгә, 1956 да, «данлы совет гаскәрләре» Венгриягә, тагын 12 елдан — 1968 дә — Чехословакиягә, тагын да 11 ел үтүгә, 1979 да Әфганстанга бәреп керделәр. Әгәр дә алар Европадан бик тиз генә «җиңү яулап» кайтсалар, тауташлар арасында урнашкан һәм заманында инглизләрнең арт сабакларын укыткан әфганнар белән сугыш тугыз елга сузылды. Бу батыр һәм горур халык бер миллион кешесен югалтса югалтты (яңадан бер миллионы җәрәхәтләнде, дүрт миллион йорт-җирсез калды) әмма урысның «легандар һәм җиңелмәс» кораллы көчләрен туган җиреннән чыгарга мәҗбүр итте. Ләкин 7 ел да тулмады, канга сусаган бу армия (күрәсез, ул уртача алганда ун елдан ун елга сугышып торырга «тиеш») тагын «данлы сугыш»ка

китте — бу юлы инде «үз җире»нең бөтенлеген, Конституциясен яклау өчен... үз халкына каршы! «Полководец»ы да нинди бит әле — Әфганстанда тыныч халыкны кырып, аның җирен кара күмергә әйләндерүдә «батырлык» күрсәткән өчен Советлар Союзы Герое исеме алган генерал!

Шушы арада гына «Известия» газетасында басылган «Новый год в Грозном» исемле бик әйбәт мәкаләсендә (5 гыйнвар, 1995 ел) Чечняда булган мәхшәрне үз күзләре белән күреп кайткан корреспондент И. Дементьева ачынып: «Да что же эта конституция такая, что из-за нее нужно убивать десятки тысяч людей?» — дип язды. Нинди булсын, Ирина ханым (гафу үтенәм, бәлки туташтырсыз. Мең рәхмәтләр Сезгә дөрес сүзегез, кан аккан җирдәге фаҗига турында язылган әрнүле язмагыз өчен!), бөтен сәясәте, яшәеше һәм халәте башка халыкларны яулап алуга нигезләнгән ул дәүләтнең нинди Конституциясе булсын, ди. Генсектан генсекка, президенттан президентка алышынып торган конституцияләрне күп күрдек инде без! Элеккеләре хет сүз чынлыгы өчен генә булса да халыкның күпчелеге тарафыннан тавыш бирелеп кабул ителде. Ә монысы «кабул итү»дә бөтен Рәсәй халкының азчылыгы катнашты, шуңа күрә законлы түгел аларның ул «Конституция»ләре, шуңа күрә аны яклап сугыш ачып йөрү дә — хыянәт. Тагын бер әйбер: хәтта Сталин конституциясендә дә «Право народов на самоопределение, вплоть до отделения и образования самостоятельного государства»ны раслаган маддә-статья бар иде. Ә менә бусында юк. Хәер, бик дөрес, булырга да тиеш түгел, чөнки ул «демократик» илнең «демократик» Конституциясе!

Безне яшь чакта, мәктәптә укыганда, В. Маяковскийның Америкада булып кайткач язган бер шигырен өйрәтеп интектерәләр иде. Шунда «иң талантлы совет шагыйре» Америка демократиясен крендель белән чагыштыра: буржуйларга аның кырые, ә хезмәт ияләренә уртасы. Безнең бәхетле илебездә хәл бөтенләй икенче иде бит — ярлылар бай, байлар ярлы булды. Менә шул, шагыйрь китергән чагыштыруны бүгенге Рәсәйнең «демократик» дәүләт структурасына, аның «дөрес» милли сәясәтенә күчерсәң, ничек килеп чыга икән: изелгән, вак милләтләргә крендельнең кырые, ә «бөегенә» уртасы, ягъни мәсәлән, бушлык кала түгелме? Якын киләчәктә, дип әйтүем.

2. «Начар» Христос белән «яхшы» Ерткыч, яки Котып диңгезеннән Һинд океанына кадәр

Мин Рәсәй дәүләтенең әле Х йөздән алып XX гасыр башына кадәр яулап алулары турында озын итеп сөйли алыр идем. Бүгенге язманың максаты ул түгел — әлеге тарихның, Рәсәйнең тышкы һәм эчке сәясәтенең бик тә мөһим бер ягына гына басым ясап үтмәкче булам.

Башка халыкларны яулап алып, киләчәк Рәсәй империясен төзүне 1552 елда Иван Грозный башлый. Әлбәттә, ул ике генә татар ханлыгын яулап алырга, өченче яуны башлап җибәрергә генә өлгерә һәм, дөресен әйткәндә, әле Европа белән искиткеч зур Азиянең нәрсә икәнен танырга да өлгермәгән бу урта гасырлар залименең ниндидер васыятьләр ясап калдырырга «интеллектуаль» дәрманы да җитми. Бу эшне «мәгърифәтле», «бөек» монарх Петр I башкара. Аның моннан 270 ел элек, ягъни 1725 тә, үләр алдыннан язып калдырган «Яшерен васыяте» хәзер күпләргә мәгълүм инде. Мин аны җентекләп тикшерергә җыенмыйм, ләкин бүгенге дәһшәтле вакыйгалар уңае белән бер генә өзек китереп узам (император фәрманының рухын төгәл җиткерү максатында ул өзекләр оригиналда китерелә).

Европаны яулап алу кирәклеген «раслап» киткәннән соң, империя атасы болай ди: «Для превращения Русского государства в мировую державу непреложным условием является перенос его столицы в Стамбул, являющийся ключом к Азиатским и Европейским сокровищам... Завершив дело с Турцией, являющейся предметом материальных интересов, появится возможность легко уничтожить Персию, обезглавить ее. Для этого вы не теряя времени, покорив Грузию и Кавказию, превратите персидских правителей в зависимых и послушных. А затем — обратить взор на Индию...»

Ә менә үләренә өч көн калганда империянең икенче, бу юлы рухи атасы булган кеше, урысның танылган язучысы Ф. Достоевский үзенең «Язучы көндәлеге»ндә (1876—1877 еллар), башта шулай ук Европаны «ашарга» кирәклеге турында язгач, болай дәвам итә: «Константинополь (Истанбул.— *Р. Ф.*) должен быть наш, завоеван нами, русскими, у турок и остаться нашим навеки... В Азию! В

Азию!.. Пронесется гул по всей Азии, до самых отдаленных пределов ее. Пусть в этих миллионах народов, до самой Индии, даже и в Индии, пожалуй, растет убеждение в непобедимости Белого (урыс.— *Р. Ф.*) царя и несокрушимости меча его...»

Монда комментарий биреп торуның кирәге юк. Һәркемгә ачыктыр: бер үк бөекдержавачыл, бөтен дөньяны яулау рухы, бер үк ерткыч сәясәт. Шушы «бөек» күрсәтмәләрне үтәү яктылыгында моннан 16 ел гына элек Һиндстан якларына сәфәр чыкканнар иде дә, юллары Әфганстан аркылы узганда «душман»нар җибәрмәделәр, кире беткереләре!

Шул ук рух һәм сәясәтне Дәүләт Думасына сайлаулар алдыннан телевидение буенча артык ешаеп киткән чыгышларында «мәшһүр» Жириновский да пропагандалады. Котып диңгезеннән алып Һинд океанына кадәр Рәсәйнең хуҗа булачаклыгы белән саташты. Ельцинның Чечнядагы сәясәтен бу кеше юкка гына бик тырышып якламый; хәер, бу яклашу, бу дуслык кара-каршы. Шушы арада премьер Черномырдин Чечня мәсьәләсен ничек хәл итү турында Жириновскийны чакырып сөйләште. Хәлләре мөшкел, алайса, хөкүмәтнең — киңәшергә адәм рәтле кешесе дә калмагач.

Ниһаять, яңа Рәсәйгә шовинистик рухның әйләнеп кайтуында тагын бер шәхеснең роле булмады түгел, ул — 20 ел Америкада яшәп, шуннан торып, Россиядә ничек бәхетле булырга кирәклеген өйрәтеп яткан һәм күпләрне бик тә сагындырып кайткан атаклы диссидент Солженицын. Заманында Сталин, НКВД террорын, ГУЛАГ лагерьларындагы афәтне үз җилкәсендә татыган, без аңа башта ихтирам белән караган һәм яңа демократ итеп уйлаган шушы талантлы язучы... шовинист булып чыкты. Хәер, мондый «демократия» белән бөекдержавачыл фәлсәфәнең бертуганнар булганлыгы хәзер шик тудырмый инде. Һәм, әлбәттә, күптән түгел А. Сахаров, Ю. Афанасьев, Г. Поповлар белән бергә яңа демократик хәрәкәт ясап җибәргән Ельцинның дәүләт башына менеп алгач икенче Ельцинга әверелүендә, аның үз сүзенә үзе хыянәт итеп, милли мәсьәләләрне танклар көче белән, кан коеп хәл итүдә әлеге урыслашкан яһүднең тәэсире булмый калмагандыр. Күрәсез, ул Рәсәйгә дә кешечә генә, ягъни самолет белән Мә-

скәүгә очып түгел, ә Тын океан ярларыннан башлап бөтен Себер аша халык белән очраша-очраша кайтты. Әйтерсең, «явление Христа народу», яңа бер «спаситель России».

«Спаситель», димәктән, 1 гыйнварда Грозныйга танклар атакасы барып чыкмагач («Танки горели, как спички»,— дип язды «Труд» газетасы), җидесендә шәһәрне коточкыч зур артиллерия утына тоту башланды һәм... шул ук көнне Мәскәүдә «Христос-спаситель» храмын бик тә тантаналы рәвештә ачып, зурлап бәйрәм итү булды. Үз сүзләре белән әйтсәк, «пир во время чумы». Алай гына да түгел, әлеге «Спаситель» чиркәве ачылуны Рәсәйнең берләшү башлангычы дип атадылар. Әйе, башланды, ләкин берләшә түгел, ә җимерелә!

«Чечен кризисы» дип атаган әйберегез Чечняныкы түгел, ә Рәсәегезнеке! Бөтен мактаулы империягез Җ. Дудаев җитәкчелегендәге кечкенә генә республиканың кечкенә, әмма ифрат та зур йөрәкле халкының бердәм көченә барып төртелде. Дуңгыз елының беренче көнендә үк Рәсәй, аның әхлакый чери башлаган армиясе хур булды — йөзгә якын танк һәм башка бронетехника берничә сәгать эчендә юкка чыкты. Танклар белән шәһәр эчендә сугышып булмаганын аңлар өчен, армия генералы, Советлар Союзы Герое һәм оборона министры булырга кирәк микәнни? Мондый хурлык башка берәр нормаль илдә булган булса, андый министр, ул гына түгел, Генеральный штаб, хәтта хөкүмәт җитәкчесе шундук отставкага киткән булырлар иде. Бездә андый «йомшак» гадәт юк шул, безнекеләр бик принципиаль, зур ихтыяр көченә ия, батыр кешеләр һәм алар дәүләт, аның структуралары белән идарә итәргә законлы рәвештә, гомерлеккә килгәннәр!

Ә Дудаев исә — бөтен Чечня Республикасы, ягъни андагы барлык халыкларның күпчелеге тарафыннан сайлап куелган законлы президент ул. Әгәр дә XIX йөздә Рәсәйгә каршы Кавказ сугышының җитәкчесе, Дагыстан һәм Чечня имамы Шамил тау халыкларының ул вакыттагы милли батырына әверелгән булса, бүген икенчесе, XX гасыр батыры булып дәүләт дәрәҗәсендәге рәсми кеше — президент һәм генерал Дудаев күтәрелеп чыкты. Һәм ул моңарчы бөтен дөньяны тетрәтеп торган зур империянең баштанаяк коралланган искиткеч зур армиясеннән курыкмаган каһарман булып, гасыр кешесе булып тарихка кереп кала-

чак. Моның өчен «бандформированиеләр»нең (рәсми Мәскәүнең ялган сәясәтенең билгеләмәсе), ягъни бандитларның башлыгы түгел, ә бөтен бер халыкны үз артыннан ияртkән көчле сәяси һәм хәрби стратег, образлы итеп әйткәндә, арыслан йөрәкле баһадир булырга кирәк. Җ. Дудаев бер Кавказның гына, Рәсәйнең генә түгел, ә бөтен дөньяның җәмәгатьчелеген, дәүләт башлыкларын шаккатырды. Дудаев һәм Ичкерия халкы дөньяны Рәсәй турында, аның милли сәясәтенең ялганлыгы, череклеге турында җитди итеп уйланырга мәҗбүр иттеләр. Бүгенге Мәскәү ялчылары булган Галазов, Автурханов, Хаҗиев, Завгаев кебек кавказлыларны Җ. Дудаев белән чагыштыру чебенне филгә тиңләү булыр иде.

Чечняга корал бирүнең бүген гаепле кешеләрен эзлиләр — кайберәүләр, Е. Гайдардыр, диләр (ул 1992 дә ярты ел гына Рәсәй хөкүмәте башлыгының вазифаларын үти һәм сәясәт белән түгел, ә икътисади мәсьәләләр белән шөгыльләнә); икенчеләре бу эшне СССРның соңгы оборона министры А. Шапошниковка сылтыйлар. Экс-министр 8 гыйнварда Рәсәй телевидениесенең «Вести» программасы буенча чыгышында бу мәсьәләгә ачыклык кертте: Рәсәй армиясенең Чечня җирендәге коралының һәм хәрби техникасының яртысы Җ. Дудаев хөкүмәтенә шул ук Рәсәйнең бүгенге оборона министры Грачев приказы белән тапшырылган. А. Шапошников шул приказның номерын ук атады. Шуннан соң да рәсми Мәскәү бүгенге хәрби министр коралландырган Чечня Республикасының гаскәрен «незаконные воинские формирования» яки тагын да зәһәррәк итеп «бандформирование» дип бәяли.

Бу чын мәгънәсендә үзең казыган чокырга үзең үк егылып төшү була түгелме соң инде? Хәер, Рәсәйнең андый чокыры турында гасыр башында бая телгә алынган зур философ Д. Мережковский бик ачык итеп әйткән иде: «Мы упали в яму, которую рыли другим. В то время, как думали, что вселенная — труп, мы сами были уже почти труп; в то же время, как мечтали «русским Христосом» воскрешать вселенную, от нас самих уже отступил Христос». Чокыр, хәтта упкын турында элегрәк Ф. Достоевский да бик уфтанып, ачынып язды: «Вся Россия стоит на какой-то окончательной точке, колеблясь над бездной». Бу

афәттән котылуда Достоевский Христоска да ышанмый, хәтта аңа кул селти: «Мы не с тобой, а с ним», ди. «С ним»ы ерткыч («зверь») дигән сүзе.

3. Безгә, татарларга, нишләргә?

Әгәр дә мин югарыда Рәсәйнең үзенең үк акыл ияләренең сүзләренә мөрәҗәгать итеп, хәшәрәт җаннар турында сүз алып барганмын икән, бу һич тә гади урыс халкы — заманында Явыз Иван опричнинасыннан газап чиккән күп санлы мәскәүлеләр һәм Рәсәй авылларының крестьяннары; И. Болотников, С. Разин, Е. Пугачев восстаниеләрендә катнашкан өчен җәзаланып үтерелгән меңләгән мужиклар; Себер шахталарында вакытсыз дөнья куйган, Рәсәйнең акыллы затлары булган декабристлар һәм совет чорының Сталин, Ягода, Ежов, Вышинский, Ульрих, Берияләр терроры вакытында һәлак булган, ГУЛАГ лагерьларында черегән миллионнар; Беренче һәм Икенче бөтендөнья сугышларында, Әфганстан һәм Чечня авантюраларында газиз гомерләрен биргән һәм бернинди гаепләре булмаган йөз меңләгән, миллионлаган карт һәм яшь солдатлар — урыслар, башка милләт кешеләре турында сөйләмим. Мин шулай ук бүгенге гап-гади эшчеләр һәм крестьяннар, М. Горбачев реформасыннан соң сүз иреген, демократиянең беренче адымнарын атлый башлаган прогрессив интеллигенция, бүген ничек итеп көнне көнгә ялгарга икән дип баш ватып яшәүче күп санлы пенсионерлар, тәрбиясез, булышчысыз калган ярлы-ябага, качаклар, урам чатларында, кибет ишеге төпләрендә хәер сорашып торучы саилчеләр, моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән бомжлар турында да сөйләмим. Мин гасырлар дәвамында Җир шарының алтыдан бер өлешен диярлек басып алган, күп халыкларның үз милли дәүләтләрен юкка чыгарган, үзенә дә, шул халыкларга да беркайчан да җүнле тормыш кора белмәгән, «инородец», «нацмен»нарның шактыен чукындырган, урыслаштырган, шул халыклар арасында геноцид, ягъни аларны әкренләп милләт буларак юк итү сәясәте үткәргән, бөтен яшәеше һәм фигыле, сәясәте һәм идеологиясе башыннан ахырына кадәр чеп-чи ялганга корылган Рәсәй империясе, аның сәяси хуҗалары турында сөйлим.

«Он (урыс халкы.— *Р. Ф.*) создал огромную империю, или, вернее, она создалась на нем. Но ведь эта империя — не крепкое правовое государство: она похожа скорее на полупрозрачное тело химеры, в котором явь смешана с бредом...» (Д. Мережковский) – менә нәрсә ул Рәсәй империясе, элеккесе дә, бүгенге яңасы, «демократия»гә корылганы да. Мәгълүм ки, мифологияләрдәге «химера» ул — арыслан башлы, кәҗә гәүдәле, аждаһа койрыклы һәм авызыннан ут чәчеп торучы куркыныч җанвар. Ниһаять, мин менә шул җанварның бүгенге хуҗалары турында яздым.

1993 елда Чаллыдан бертуган Кашаповлар ярдәме белән чыгарылган «Золотая Орда и татары. Что в душе у народа» исемле, күләме ягыннан кечкенә генә булган китабымда мин мондый сүзләр дә язган идем: «Кому-кому, но мне не нужна такая Россия – Россия Грозного, Ермака, Конашевича, Пуришкевича, Столыпина, Ежова, Жириновского, Васильева, Анпилова, Константинова, Стерлигова, Румянцева (боларга өстәп, бүгенге көн «геройлары» булган Ельцин, Грачев һәм язмабызның башында күрсәтелгән башка сугыш чукмарларын санап китәргә була). Мне нужна Россия Льва Толстого, Николая Лобачевского, Василия Радлова, Михаила Худякова, Михаила Артамонова, Николая Бердяева, Анны Ахматовой, Андрея Сахарова, Льва Гумилева, Андрея и Петра Григоренко, Семена Липкина, Юрия Афанасьева... Мне нужна Россия подлинно демократическая, Россия мудрая, Россия великодушная как к своему, так и другим народам, способная относиться к ним как равная к равным».

Без бүген бер көн бер елны алыштыра торган, кискен иҗтимагый-сәяси вакыйгаларга һәм хәвефле хәлләргә ифрат бай булган, иртәгесе көн нәрсә алып киләсен чамалап та булмый торган гаҗәеп катлаулы заманда яшибез. Бер ел эчендә генә яңа шәхесләр белән очраштык, элеккеләренең ул вакытта без аңлап бетермәгән якларын күрдек. Аларның күбесе Ичкериядәге афәт унае белән уртак фаҗига вакытында калкып чыктылар. Мин бүген сәясәтчеләр Сергей Ковалев, Егор Гайдар, Гавриил Попов, Григорий Явлинский, язучылар Анатолий Приставкин, Сергей Залыгин, Юрий Карякин исемнәрен аерып күрсәтәм. Болар арасында «икенче Сахаров» — С. Ковалев — аерым урын алып тора. Һәм, әлбәттә, бөек гражданин-академикның

хатыны Елена Боннер да читтә калмады. Алардан башка Чечняга каршы оештырылган авантюраны кайбер атаклы академиклар, Дума депутатлары һәм Федерация Советы әгъзалары, телевидение һәм газета хәбәрчеләре, башка бик күпләр гаепләп чыктылар. Гомум иҗтимагый протестка кайбер хәрбиләр дә кушылды. Солдат аналарының Мәскәүдәге протест-митинглары һәм пикетлары көннән-көн массакүләм төс алып бара. Рәсәйнең үз прогрессив җәмәгатьчелеге, Американың һәм кайбер башка илләрнең ышанычлы, чын демократик даирәләре Россия телевидениесенең Чечня вакыйгаларына объектив карашы өчен ВГТРК житәкчесе О. Попцовны урыныннан алу турында Ельцин ниятен бик гаепләп чыктылар.

Чечняга каршы сугыш күпләр өчен көтелмәгән хәл генә түгел, ә бертөрле тетрәнү, милли мәсьәләдә ныклап урын алган элеккеге стереотипның җитди үзгәрә башлавы булды. Рәсәй үзенең милли сәясәт өлкәсендәге моңарчы алып барган эшчәнлегенә әйләнеп карап, ул сәясәтне тамырыннан үзгәртергә тиеш.

Дөрес, җәмәгатьчелек, аның сәламәт интеллектуаль көчләре бу мәсьәләдә үзгәрешләр ясарга тырышып карасалар да, хакимиятнең гасырлардан килгән зур, дәүләт сәясәтеннән — бөекдержавачыл идеологиясеннән — һәм шул нигездә кылыначак гамәленнән баш тартуы бик тә шикле. Моны Рәсәй президентының, хөкүмәтенең, Куркынычсызлык советының, көч министрларының, генералитетның төп составының, Мәскәү, Санкт-Петербург, тагын кайбер шәһәр башлыкларының һәм башка реакцион көчләрнең Чечня авантюрасын яклаулары, агрессив сәясәттән аерылырга теләмәүләре күрсәтеп тора. Заманында «600 секунд» телевизион тапшыруы белән күпләргә таныш булган Невзоров дигән әфәнде күптән түгел генә Дәүләт Думасы трибунасыннан: «Это наша земля, ее нельзя отдавать чеченцам», — дип кычкырды. «Наша земля» дигәне Чечня Республикасы була инде. Бу — урысның үз сүзе белән атаганда, «бред»ы гына түгел, ә «махровый» (иң оятсыз) шовинизм фанатизмы! Чечня басып алынганнан соң Рәсәйдә шовинизм шаукымының күтәрелеп китү куркынычы да юк түгел.

Шул ук вакытта бөтен дөньяда Рәсәйнең Ичкериягә булган агрессиясенә караш үзгәрә, киң протест рәвешен

алып бара. Американың һәм Европаның зур илләренең дәүләт җитәкчеләре «Чечня мәсьәләсе — Россиянең эчке эше», дигән битараф карашларын дәвам итсәләр дә, Көнбатыш һәм Көнчыгыш дөньяның абруйлы көчләре бу мәсьәләдә көннән-көн прогрессив юлга баса баралар. Узган ел АКШ Конгрессына сайлауларда җиңеп чыккан Республикачылар партиясенең күпчелек вәкилләре Россиягә булган мөнәсәбәтне яңадан карауны таләп итәләр. Россияне Европа Союзына әгъзалыкка алу мәсьәләсе дә зур каршылыкка очрады, хәтта туктап калды. Хәер, әле Чечня сугышына кадәр үк, былтыр, Будапештта булып узган СБСЕ конференциясендә бу ил чынында берүзе, изоляциядә калды. Дөньяда яңа салкын сугышның башлану мөмкинлеге туды. Бүген мөселман дөньясында Рәсәйгә карата туган бик җитди оппозицияне әйтеп тә торасы юк.

Мондый хәлдә безгә, татарларга, ни эшләргә соң; дигән сорау туа. Каһарман чечен халкыннан үрнәк алырга, дияр идем мин. Юк, юк, бу һич тә коралга тотынырга дигән сүз түгел!

Ә чынлабрак әйткәндә? Мин сәясәтче дә, бүгенге җәмгыятьнең сәяси тормышын өйрәнүче политолог та түгел. Мин — татар халкының һәм Татарстанның дәүләт вә мәдәният тарихын тикшерүче профессиональ тарихчы. Менә шул күзлектән чыгып, бу мәсьәләгә үземнең карашымны белдерәсем килә.

Татар халкының, башлангыч чоры 552 елдан (Төрки каханлыгы оешкан вакыттан) — 1552 елга кадәр килүче (Казан ханлыгы яулап алынган ел; башка татар ханлыклары өчен тагын да озынрак), ягъни мең елдан артык вакытны эченә алган, бик зур тарихи вакыйгаларга һәм бөек шәхесләргә, югары мәдәнияткә бай дәүләтчелек тарихы бар. Бу — шул дәверләрнең беренчел чыганаклары белән расланган һәм кире кага алмаслык хакыйкать! Татарстан Республикасының халыкара хокук субъекты булган суверен дәүләт икәнлеге аның Конституциясендә билгеләп куелганлыгыннан законлы файдаланып, республикабызның хакимият органнары, хокук саклау оешмалары, милли-азатлык хәрәкәте һәм сәяси партияләр җитәкчеләре, массакүләм информация чаралары һ. б. структуралар вә даирәләр татар халкының һәм Татарстанның дәүләтчелеген, ныклы фәнни нигезгә таянып, һәрвакыт һәм кирәк булган

һәр җирдә — халыкара оешмаларда, зур, абруйлы илләрнең җитәкчелеге, Мәскәү хакимияте эшелоннарында, дөнья һәм Рәсәй җәмәгатьчелеге алдында өзлексез, принципиаль һәм курыкмыйча якларга тиешләр. Якларга гына түгел, көрәшергә тиешләр.

Дөресрәге, тиешбез! Татарстан — чик буенда диярлек һәм урманлы биек таулар, тирән тарлавыклар арасында урнашкан Чечня да, бүгенге татар чечен дә түгел, шуңа күрә безнең көрәшебез дә икенче төрле булырга тиеш. Ул — чын демократик (!) парламент булдырып, цивилизацияле юл белән, Рәсәйдәге изелгән халыкларга үрнәк күрсәтеп, күп гасырларга сузылган тарихи дәүләтчелек традициябезне яңартып, үзебезнең, сүздә генә түгел, асылда мөстәкыйль дәүләтебезне булдыру. Моның өчен татар халкының тарихи байлыгы да, интеллектуаль көче дә җитәрлек. Тукай халкыбызны «зур ул, көчле ул» дип шигъри яңгыраш өчен генә әйтмәгән.

Курку барьерын узып (шуңа күрә мин, чечен халкыннан үрнәк алырга кирәк, дидем дә!), безнең татар 1918 елда большевизм тарафыннан бастырылган милли хәрәкәтен яңадан торгызырга тиеш. Моның өчен массалык кирәк, ягъни халыкның (эшчеләрнең, авыл халкының, яшьләрнең, интеллигенциянең) күпчелеге булганда гына чын, теләгән уңышка ирешеп булачак. 1991 елда күтәрелеш ала башлаган халыкның бер өлешен җитәкләүдә ул вакыттагы милли хәрәкәт лидерлары файдалы эш эшләде, ләкин алар арасында соңгы вакытта туган ыгы-зыгы, таркаулык нәтиҗәсендә бүгенге татарның төп өлеше (кабатлап әйтәм — эшчеләр һ. б.) хәзер алар тирәсендә тупланмаганнар. Әмма әлегә таркалып бетмәгән ул оешмаларны, теләсәләр берләштерә алырлык, үзенең интеллектуаль дәрәҗәсе белән алардан бер башка югары торырлык һәм халыкны үз артыннан алып бара алырлык, бердәмлеккә (!) нигезләнгән яңа хәрәкәт, яңа лидерлар, хәтта лидер кирәк.

«Ватаным Татарстан»,
1995, 20 гыйнвар.

АКСАК ТИМЕР, ТУКТАМЫШ ҺӘМ ИДЕГӘЙ

Мин бу язмамны моннан 600 еллар элек Аксак Тимер яуларына каршы аяусыз сугышларда шәһид булган меңләгән вә йөз меңләгән татарларның якты истәлегенә багышлыйм.

Автор

1. Җиһангир

«Аллаһе тәгаләнең ихтыярыннан башка җир йөзендәге халыкларның берсенә дә мин зыян китермәдем».

Аксак Тимер. Автобиографиядән

«Аксак Тимер туганда ук йодрыкларын кысып, учлары тулы кан белән туды».

Аксак Тимер турындагы тарихи хикәяләрдән

«Аксак Тимер гаскәрләре Сарайны алып, ут төртеп яндырдылар һәм бөтен шәһәрне җир белән тигезләделәр».

Шәрәфетдин Йәзди. «Зафәрнамә» (Җиңүләр китабы). XV йөз башы

1391 елның 18 июнендә Иделнең сул ягындагы Кондырча елгасы буенда Урта Азиянең Тимериләр, ягъни үзбәкләр дәүләте башлыгы әмир Тимербәк (Аксак Тимер) белән Алтын Урда ханы Туктамыш арасында зур сугыш була. Тарихи чыганакларда ул олуг, бүгенгечә әйтсәк, бөек сугыш дип атала — анда һәр ике яктан да икешәр йөз мең сугышчы катнаша.

Сугыш татарлар файдасына башланып китә һәм җиңү чак кына алар ягында булмый кала. Әмма Аксак Тимернең яңа хәрби доктринасы өстенрәк булып чыга һәм соңгы чиктә ул җиңә. Җиңмәс иде — хәлиткеч бер мизгелдә Туктамышның берничә зур гаскәр башлыгы ханга хыянәт итә. Җиңелүнең беренче карашка кечерәк саналган, әмма чынында мөһим тагын бер сәбәбе була. Аксак Тимер соңыннан үзенең «Законнар җыелмасы»нда: «Мин дошманның байрак йөртүчесен сатып алдым, ул миңа, ике якның да гаскәре сугышка кергәч, үзенең байрагын ташларга сүз

бирде»,— дип яза. Ә байракның сугышта әһәмияте бик зур — ул гаскәрнең, аның бөтенлегенең һәм куәтенең символы санала. Теге сатлыкҗан чыннан да Аксак Тимер кушканча эшли, һәм Туктамыш армиясендә хәлиткеч сәгатьтә өметсезлек, каушау башлана. Гаскәр башлыклары арасындагы хыянәтчеләрнең дә Җиһангир тарафыннан сатып алынган булулары бик ихтимал.

Шәрәфетдин Йөзди хәбәрләренә караганда, йөз мең татар сугыш кырында ятып кала. Хәер, дошман гаскәре дә зур югалтулар кичерә, 18 төмән, ягъни унар мең сугышчыдан торган хәрби берләшмә башлыклары, һәлак була. Аксак Тимернең дә гаскәре, шулай итеп, сугыш кырыннан бик нык өтекләнеп чыга.

Әмма шул ук Тимер, Иделдәге зур гына бер утрауда 26 көн ял итеп, кәеф-сафа корып алганнан һәм гаскәрен тәртипкә китергәннән соң, татар җирләрен таларга әмер бирә. Искиткеч зур байлык һәм бихисап әсир тупланып, Урта Азиягә, Сәмәркандка озатыла. Менә шул таланган ганимәт-байлыкның һәм әсир ителгән татарларның саны: дүрт миллион сарык, 40 мең баш эре мөгезле терлек, ярты миллион ат һәм... ярты миллион кеше. Бу саннар XVI йөзнең төрек тарихчысы Әхмәт бине Лотфулланың (күбрәк Мөнәҗҗим башы дип мәгълүм) «Җәмигъ әт-дөвәл», ягъни «Династияләр җыелмасы» исемле хезмәтендә тупланган. Өч томнан торган бу зур китап күп санлы гарәп, фарсы һәм төрки чыганакларга таянып язылла. Татарның мәгълүм тарихчысы Зәки Вәлиди раславынча, Мөнәҗҗим башының тарихи хезмәтенә урта гасырларда киң таралган «Дәрбәнднамә» исемле атаклы язма да нигез була, ә дөньякүләм мәшһүр ориенталист, академик И. Крачковский исә бу хезмәткә зур бәя бирә. Мөнәҗҗим башының китабына махсус тукталуымның сәбәбе вә максаты — 1391 елгы сугыш уңае белән анда күрсәтелгән саннарның дөреслегенә вә ул чордагы татарның фаҗигасенә укучыларны ышандырырга тырышуым, чөнки Аксак Тимернең эшчәнлеген мактауга багышланган хезмәтләрендә кайбер үзбәк һәм урыс тарихчылары бу саннарга күз йомарга яки аларны инкарь итәргә маташалар.

Әмма шундый зур югалтуларга карамастан, Алтын Урданың әле көче күп була, һәм беренче зур җиңелүдән соң югалып калган Туктамыш, тиз арада хакимиятне ку-

лына алып, яңадан шул санда гаскәр туплый. 1395 елның 15—16 апрелендә Төньяк Кавказның Тәрек (Терек) елгасы буенда Аксак Тимер белән аның соңгы, хәлиткеч сугышы була. Туктамыш үз көчен тулыландыру максатында Мисырга, Төркия һәм Литвага ярдәм сорап мөрәҗәгать итә, чөнки бу илләр белән Алтын Урда арасында күптәннән яхшы мөнәсәбәт урнашкан була. Кайбер тарихчылар шул соралган ярдәмнең булганлыгын икърар итсәләр дә, чыганакларда хәрби яки башка төрле булышлык ачык күренми. Аксак Тимер белән ике арада солых төзү мөмкинлеге дә юкка чыга. Бу дәһшәтле сугыш та, Кондырча буендагы кебек үк, Туктамышның җиңелүе белән тәмамлана. Моның төп сәбәпләренең берсе булып, күрәсең, Аксак Тимер гаскәренең сан ягыннан бермә-бер артык булуыдыр — кайбер тарихчылар анда 400000 сугышчы булганлыгын язалар. Әлбәттә, дүрт ел эчендә генә беренче сугышта биргән коточкыч зур корбаннардан соң Туктамышка элеккесенә караганда икеләтә зур армия төзү һич мөмкин булмый. Шулай ук Алтын Урдада гасыр ахырына таба көчәеп киткән эчке көрәшнең дә зыяны тимичә калмый.

Сугышта кабат җиңелгәч, Туктамыш үзенең аз санлы гвардиясе белән төньякка, Болгар җирләренә кача. Аны куа китеп һәм ханга яңа гаскәр тупларга комачаулау максатында, Аксак Тимер Алтын Урданың иң күп халыклы шәһәрләрен, цивилизация үзәкләрен җимерә. Төньяк Кавказдагы Мажар, Идел буендагы Үкәк, Бәлҗәмин, Әстерхан, Гөлстан, дәүләтнең башкаласы Сарай (Сарай-Бәркә яки Сарай әл-Җәдид), Кырымдагы Иске Кырым (Солхат), Дон тамагындагы Азак, гомумән, Алтын Урданың үзәк җирләрендәге шактый шәһәре җимерелә, кайберләре җир белән тигезләнә, халкы кырыла (соңгырак татар тарихы чыганакларында шәһри Болгарга да зур зыян килгәнлеге турында языла). Бу шәһәрләрдә, бигрәк тә Сарайда эшләнгән ерткычлыклар турында шул чор язмаларын тетрәнмичә укырга мөмкин түгел. Үтә дә зур залимлек, садистлык дәрәҗәсенә җиткән вәхшилек әлеге шәһәр урынын археологик казулар вакытында да ачыклана: кеше гәүдәләренең туралган, ягъни башлары, куллары һәм аяклары киселгән калдыклары һ. б. табыла.

Шушы ике коточкыч сугыштан соң Алтын Урдага, аның бөтенлегенә, дәүләт вә хәрби куәтенә әйтеп бирә

алмаслык зур зыян килә. Кайчандыр — Бату, Бәркә, Үзбәк, Җанибәк ханнар заманында — дөньяны тетрәткән бу олуг дәүләт чын мәгънәсендә үзенең җимерелү чорына керә һәм 1395 елдан соң ул элеккеге куәтен беркайчан да һәм берничек тә кире кайтара алмый. Дәүләтнең житештерү көчләре җимерелә, иң зур цивилизация учаклары юкка чыга, бәһа биреп бетерә алмаслык байлык талана, миллионнан артык халык яуда һәм шәһәр-авыллар җимерелгәндә кырыла, әсирлеккә алып кителә. Ә исән калганнарына яңадан аякка басарга һәм әкренләп дәүләтне ничек тә булса торгызырга гадәттән тыш зур, кеше ышанмаслык тырышлык, ихтыяр көче һәм сәләт кирәк була һәм бу эш өлешчә эшләнә дә.

Татар халкының олуг тарихында әрнү вә газап белән искә алырлык дәһшәтле ике вакыйга, ике матәм көне бар. Аның берсе — 1552 елның 2 (яңа стиль белән 15) октябре, ягъни Казан ханлыгының Явыз Иван гаскәре тарафыннан басып алынган, шул дәүләтнең юкка чыккан көне. Монысы халкыбыз тарафыннан соңгы елларда кабат зурлап билгеләнеп үтелә башлады. Икенчесе, дөресрәге, беренчесе була инде — 1395 елның 16 (яңача 29) апреле — бөтен татарның уртак, олуг дәүләтенә яңадан, чынлап торып аякка баса алмаслык итеп зур зыян, гомум афәт килгән көн. Дөрес, Алтын Урда, дәүләт буларак, ул вакытта әле юкка чыкмый, аның җирләре дә, 1552 елдан үзгә буларак, җиңүче халык тарафыннан колонизацияләнми. Әмма шул көннән башлап бөтен татар дөньясы үзенең әүвәлге куәтен югалта; татар дәүләтчелеге, соңрак аның тарихында күтәрелеш, хәтта яңарыш дәверләре булып алса да, батыш чорына керә.

Әлбәттә, Казан ханлыгы безгә вакыт ягыннан да якынрак, аның башкаласы Казан шәһәре, гәрчә аның шул заман милли йөзеннән бик аз нәрсә калган булса да, бүгенге татар дөньясының мәркәзе, ышанычы булып тора. Шуңа күрә 1552 елгы фаҗига Казан татарлары күңеленә күбрәк кереп утырган. Ә Алтын Урда дәүләтен безгә озак еллар буе оныттырырга тырыштылар, берничә буын аның тарихын белми генә түгел, чынында шул данлы тарихтан хурланып үсте.

Рәсәй үзенең «возрождение»сен, ягъни яңарышын булдыруны соңгы вакытта бик мактанып бөтен дөньяга

игълан итте. Татарның үз яңарышы булдырылырга тиеш, чөнки аның тегеңә караганда күпкә озын, күпкә пакь һәм саф тарихы бар! Ул бай тарихның барлык чорлары да халык күңелендә лаеклы урын алырга тиеш. Бөеклеге бөек булып, фаҗигасе фаҗига булып! Шундый зур фаҗигане берсе — 1395 елның 16 апреле. Быел, 1995 елның яңа стиль белән 29 апрелендә шул әрнүле вакыйгага нәкъ 600 ел тула. Онытмыйк моны, татарлар, сөекле милләттәшләр! Тарихын онытканның бәхете дә, киләчәге дә юк!

Урта Азия җиһангиры Аксак Тимер (җиһангир - «дөньяны яулаучы» дигән сүз) бер Алтын Урданы яулап кына калмый, ә Һиндстанга, Иран, Гыйрак, Мисыр, Төркиягә, Кавказ артына, кыскасы, бөтен Азиянең ярты җиренә талау һөҗүмнәре ясый. Ул булган җирләрдә яндырылган, җимерелгән һәм таланган шәһәрләр, авыллар, җәйләүләр, оазислар, меңләгән вә йөз меңләгән корбаннар, тураклаган җаннар, елга булып аккан адәм каннары кала. Аксак Тимер гаскәре башкарган вәхшилекләр хакында ак кәгазьгә язарга кулың күтәрелмәс. Шулай да бер-ике генә булса да мисал китермичә йөрәк түзми. 1387 елда Иранның Исфахан шәһәрен алгач, каршылык күрсәткәне өчен бөтен шәһәр халкын сую башлана һәм нәтиҗәдә 70 мең киселгән кеше башыннан, җиһангир әмере белән, берничә биек манара өелә; 1395 елда Месопатамиядәге Амид (Дийар Бәкер) шәһәрен яулап, андагы атаклы затларны адәм әйтеп ышанмаслык авыр газапларга дучар итеп, тураклап ташлыйлар; шул ук елны Ван күле буендагы әрмән крепостен алып, бөтен булган хатын-кызны һәм бала-чаганы әсир итәләр, ә калган халыкны биек стеналар өстеннән аска ыргыталар — анда җәфаланып үлгән мәетләр шулкадәр биеклеккә өелә ки, соңыннан ташлаганнары үлми башлый, тик аларын балталар һәм кылычлар белән тураклап чыгалар. 1398 елда Һиндстанга бәреп кергәч тә, шунда әсир ителгән йөз мең кеше җәзалап үтерелә. И-и-и, саный китсәң!..

Менә шушы «җиһад» («изге сугыш!») корбаннары турында язылган чыганакларны укыгач, Аксак Тимернең автобиографиясеннән бая эпиграф итеп китерелгән сүзләр кабат искә килеп төшә: әйе, Җир йөзендәге халыкларның берсенә дә ул «зыян китермәгән!» Китергән икән, анысын инде «Аллаһе Тәгаләнең ихтыяры» белән генә эшләгән!

Йа, Ходa, бөек вә изге исемең алдында никадәр оятсызлык, вәхшилек һәм хәбислек!

Аксак Тимер чыгышы белән Барлас исемле, соңыннан төркиләшкән (ярым татарлашкан, ярым үзбәкләшкән) элеккеге монгол кабиләсеннән. Кечкенәдән үк башкисәр булып үсә, әкренләп тирәсенә үзе кебек үк кансыз вә нәҗес, пычрак җанлы юлбасарларны туплый һәм, олы юлга чыгып, кәрван талап йөри башлый. Тора-бара үзенең шәхси батырлыгы һәм хакимлек итүгә сәләте белән тирәюньдә генә түгел, еракларда да дан казана. Кайда хәрби осталыгы, кайда мәкерлелеге белән үзенең сәяси көндәшләрен әкренләп җиңә бара һәм 1370 елда, элеккеге Монгол империясеннән аерылып чыккан Чыгытай олысының үзәгендә, ягъни Аму-Дарья белән Сыр-Дәрья елгалары арасындагы бай җирдә (урта гасырларда Мәварәннәһер исеме белән мәгълүм) Тимериләр дәүләте төзи. Чыгышы белән Чыңгыз ыруыннан булмаганлыктан, хан яки шаһ дәрәҗәсенә ирешә алмый, ләкин әмир титулы белән шул дәүләтнең башлыгы була һәм 36 ел идарә итеп, 1405 елда 69 яшендә үлә. Кабере — Сәмәркандта, Гүр Әмир исемле шәхси дөрбәдә.

Яшьлегендә, әле юлбасарлык белән шөгыльләнгәндә, Тимер авыр яралана — уң кулына һәм уң аягына төзәлмәслек җәрәхәт ала. Нәтиҗәдә кулы корый, ә аягы гомерлеккә аксак булып кала. Аксак Тимер дигән исеме дә шуннан килә — бу төрки телдә шулай, фарсыча Тимерләнк, аннан европалаштырып Тамерлан дип тә атыйлар, ә фәнни әдәбиятта күбрәк Тимур исеме белән мәгълүм. Шул яраланган кулы белән аягында әкренләп сөяк туберкулезы башлана һәм алар һәммәсе дә аңа гомере буена газаплар, вакыты-вакыты белән түзә алмаслык авырулар китерә. Антропологлар һәм медиклар Аксак Тимернең артык дәрәҗәдә усаллыгын, үтә дә явызлыгын әнә шул мәңгелек җәрәхәтләре, чире белән дә бәйлиләр. Чулаклык, корыган куллылык исә еш кына тираннарның юлдашы ул (моның соңгы ачык мисалы — Сталин).

Ә, гомумән, урта гасырларның ике зур тираны буларак, җитмәсә татар халкының тарихында әйтеп бирә алмаслык кара эз калдыруы, хәтта берничә гасырга аның язмышын хәл итеп куюы белән Аксак Тимер һәм Явыз Иван (Иван Грозный) бер-берсенә бик охшашлар. Аларның беренчесе

1391, бигрәк тә 1395 елда бөтен татарның бердәм, зур дәүләтен — Алтын Урданы коточкыч җәрәхәтләп китсә, аның таркалуына төп сәбәпче булса, икенчесе шул дәүләт нигезендә оешкан Казан ханлыгын 1552 елда яшәүдән туктата. Шушы ике залим татар халкының чын мәгънәсендә меңьеллык дәүләтчелегенә балта чаба, бу олуг халыкны менә ничә гасырлар инде газап чигәргә мәҗбүр итә. Аларның тагын бер охшашлыклары — икесе дә үз халкының милли геройларына әйләнәләр. Явыз Иванны православие чиркәве изгеләр рәтенә теркәргә ниятли, ә Ташкент шәһәрендә Аксак Тимергә һәйкәл куярга җыеналар...[1]

2. Туктамыш хан

«Ул (Туктамыш) сәләтле, батыр, яхшы мөгамәләле, чибәр хан иде. Аның гадел һәм әйбәт холыклы булганлыгы һәркемгә мәгълүм».

«Мөнтәхәб әт-тәварих Могыйни» («Могыйн елъязмаларының җыентыгы») исемле фарсы язмасыннан. XV йөз башы

«Туктамыштай олы хан...
Азамат ир Туктамыш...»

«Идегәй» дастаныннан, XV йөз

XIV йөзнең 50 еллары азагында Алтын Урда дәүләтендә җитди кыенлыклар — хакимият өчен көрәш, ыгы-зыгы, чуалыш башлана. Сәяси хәлнең кискенләшүенә табигый бәла-казаның килеп чыгуы өстәлә. 1346 елда Кытай якларыннан чума авыруы таралып, күп җирләрне басып ала, хәтта Көнбатыш Европага кадәр барып җитә. Әмма шушы коточкыч афәттән Урта Азия һәм Каспий буйлары белән чикләнгән Алтын Урда аеруча зур зыян күрә. Бер Кырымда гына, мәсәлән, 85 мең кеше үлә, ә Сарай, Хаҗитархан һәм Үргәнечтә (Харәзем) шулкадәр күп халык кырыла ки, урыс елъязмаларында әйтелгәнчә, «үлгәннәрне күмәргә кеше табып булмый». Бу сүзләрдә арттыру булса да, алар татар җиренә килгән ул зур бәлане бик яхшы

[1] Мондый һәйкәл куелды да инде. Заманында ярты дөньяны кара канга батырган шушы «милли герой»ны яхшы атка атландырып, К. Маркс һәйкәле урынына бастырып куйдылар.

чагылдыралар. Шул заманның тарихи чыганакларында «Великий моф» (мур—үләт), «кара үлем» дип аталган шушы эпидемияләрдән соң Алтын Урда әле шактый вакыт ныклап аякка баса алмый, тик Җанибәк хан идарә итүнең соңгы елларында гына Иран белән ике арада инде күптәннән барган сугышны дәвам иттерергә үзендә көч таба.

1357 елда Җанибәк үлгәч, тәхеткә аның улы Бирдебәк утыра, тик ул ике елдан соң үтерелә. Шул вакыттан алып, ягъни 1359 елдан башлап 1380 елга кадәрге 20 ел эчендә, Сарайда 25 хан идарә итә; аларның кайберләре хәтта берәр ай гына «патшалык» итеп алырга өлгерә. Алтын Урда тарихында бу бик тә аянычлы, күңелсез, оят булса да әйтик, татар татарның башын ашаган заман. Бу фетнә-чуалышлар турында гарәп-фарсы тарихи географиясендә һәм урыс елъязмаларында ачык итеп язылган.

Әмма 1380 елда Сарай тәхетенә Туктамыш хан утыргач, Алтын Урдада низаглар туктый. Туктамыш бу вакытта 30—32 яшьләрендәге сәләтле һәм инде тәҗрибә туплап килүче сәясәтче була (аның туган елы төгәл билгеле түгел, 1340 еллар азагы—1350 еллар башы булырга тиеш). Туктамыш, Алтын Урданың һәм аннан соң барлыкка килгән бөтен татар ханлыкларының ханнары кебек үк, Чыңгыз ханның улы Җуҗи династиясеннән, аның да унөченче улы Тукай-Тимер нәселеннән (Туктамышның үзенең дә 13 улы һәм 2 кызы була). Яшь хан Алтын Урда өчен авыр вакытта—урыс белән Куликово сугышы булган елда, шул сугыштан соң, 1380 елның көзендә тәхеткә утыра. Җитмәсә, шушы чорда дәүләтнең көньяк-көнчыгыш өлеше булган Күк Урда Алтын Урдадан аерылып чыгу юлына баса башлаган була.

Мәгълүм ки, Алтын Урда ике өлештән торган: Кырымнан алып Идел аша Җаек һәм Иртеш елгаларына кадәр булган җирләр, ягъни дәүләтнең иң зур өлеше Ак Урда дип, ә Каспий һәм Арал диңгезләре аралыгындагы җирләр—Урта Азиянең һәм хәзерге Казахстанның көнбатыш өлеше—Күк Урда дип аталган. Дәүләт белән Мөхәммәт хан (чыганакларда күбрәк Орос хан исеме белән бил-

геле)[1] идарә иткән 1370 елларда Күк Урда мөстәкыйльлеккә юл тота башлый. Хан Алтын Урданың бөнлеген саклау максатында моңа каршы көрәш башлый, хәтта әлеге шул көнчыгыш олыс әмирләренә карата репрессия чаралары да үткәрә, мәсәлән, сепаратизм юлына баскан Мангышлакның хуҗасы Туйхуҗаны үтертә. Аның яшь улы Туктамыш, үзенә хәвеф янаганны аңлап, 1376 елда Сәмәркандка, Аксак Тимер янына качып китә.

Аксак Тимер — бу вакытта әле ул дөньяга билгеле полководец та, күп җирләрне яулаган тиран да түгел — яшь ханзадәне бик җылы каршы ала. Киләчәктә җиһангир буласы затның үзенең алга куйган уй-планнары була: аның дөньяны басып алу юлында зур һәм көчле Алтын Урда тора, һәм шул дәүләтне үзенә буйсындыру өчен Сарай тәхетендә аның үз кешесе кирәк була. Ә андый кеше — Алтын Урда ханы булырга хаклы һәм кыен вакытында Аксак Тимердә яклау тапкан яшь вә сәләтле Туктамыш.

Шулай итеп, Тимерләнк Туктамышны зур хөрмәт белән кабул итә, алай гына да түгел, әле ул үзе яулап алмаган Сәйран, Утрар, Сыганак шәһәрләрен (соңгысы Күк Урданың сәяси үзәге була) ханзадәгә «бүләк итә». Әлеге шәһәрләргә Аксак Тимернең, әлбәттә, хакы булмый, һәм Орос хан Туктамышны ул үзәкләргә якын җибәрми — аның уллары өч тапкыр яшь ханзадәнең гаскәрен тар-мар итәләр (бу гаскәр дә Туктамышка Тимерләнк тарафыннан бирелгән була). Бары тик дүртенче сугышта гына Туктамыш Орос ханның улы Тимермәликне җиңә — хан үзе бу вакытта үлгән була инде. Шушы җиңүдән соң Тимермәлик кешеләре күпләп Туктамыш ягына чыгалар, шулар арасында Орос ханның уң кулы, дәүләт идарәсендә икенче кеше саналган Казан баһадур, Галибәк һәм башка атаклы әмирләр вә бәкләр була. Чынында, Алтын Урда гаскәрләренең иң зур өлеше Туктамыш кулына күчә.

---

[1] Гарәп-фарсы тарихи географиясе һәм Алтын Урда акчаларында шулай; бүгенге хәрефләр белән транскрипциясе «Орыс хан» буладыр (Нәкый ага Исәнбәт бу сүзне «ачык», «якты», «гүзәл» мәгънәсендә аңлата). Урыс елъязмаларында ул «Урус-хан» итеп бирелгән, бу — шул Оросның урысча транскрипциясе һәм, әлбәттә, аның урыска бер катнашы да юк. Аларда сирәк булса да очрый торган «Урусов» фамилиясе безнең татар белән бәйле.

Җиңү белән рухланган Туктамыш 1380 елның көзендә көнбатышка юнәлә, башта Харәземне, аннан Сарайн ала. Шуннан алда гына Куликово сугышын уңышсыз тәмамлаган бәкләри бәк Мамай, Сарайны ташлап, көнбатышка кача, ләкин Туктамыш аны куып җитеп тар-мар итә.

Мамай кечерәк бер гаскәре белән Кырымга юнәлә, әмма генуэзлылар, ягъни Кырымның яр буендагы шәһәрләрендәге элекке антик чордан ук килүче итальяннар, аны Туктамышка тотып бирәләр. Мамай үтерелә, Кырым бөтенләе белән Туктамыш ягына күчә.

Яңа хан бөтен Алтын Урданы, ягъни Харәземнән алып Кырымга кадәр булган зур дәүләтне үз кулына ала. Бөтен илне ныгытуда иң беренче эшләреннән берсе итеп ул Куликово сугышыннан соң Сарайга буйсынудан баш тарткан Мәскәүнең бөек кенәзе Дмитрий Донскойны яңадан хан кулыннан ярлык алырга һәм ясак түләргә мәҗбүр итә. Бу болай була. 1381 елда Туктамыш Мәскәүгә илчеләр җибәреп, урыс кенәзләренең Алтын Урдага килеп ярлык алырга тиешле булуларын исләренә төшерә, әмма Донскойдан тискәре җавап ала. Бер елдан соң Туктамыш Мәскәүгә яу белән бара, юлда аңа Нижний Новгород кенәзе Дмитрий һәм Рязань кенәзе Олег үз гаскәрләре белән кушылалар — болар Мәскәүгә оппозициядә булган булалар. Өч көн камап торганнан соң Туктамыш Мәскәүне ала һәм зур байлык туплап кайта. Шулай итеп, Төньяк-Көнчыгыш Русь дип аталган урыс дәүләте яңадан Алтын Урдага буйсына, ә төньяк-көнбатыштагы Новгород җирләре һәм көньяк-көнбатыштагы элеккеге Киев Русе бу вакытта Литвага буйсынулы булалар; әмма шул ук Литваның бөек кенәзе Владислав Ягайло бу җирләр өчен Сарайга ясак түләп тора. Шулай итеп, бөтен урыс җире чынында элеккегечә татар йогынтысына эләгә.

Туктамыш үз дәүләтенең иминлеген ныгыту буенча зур эш җәелдереп җибәрә. Аңа хәтле булган 20 еллык сәяси ыгы-зыгыга, хакимият өчен көрәшкә чик куела. Әүвәлге көч-куәтенә, халыкара дәрәҗәсенә вә данына зыян килә башлаган Алтын Урда дәүләте яңадан үз хәленә кайта. Шәһәр һәм дала дөньясы кабат җанланып китә, зур-зур сәүдә юллары, аларның атаклы үзәкләре янәдән тулы тормыш белән яши башлыйлар, акча сугу эше тагын да көчәеп китә — бу хакта соңгы нумизматик мәгълүматлар

бик ачык сөйли. Моннан берничә ел элек кенә без Татарстанның Апас районы, Каратун станцасыннан ерак түгел очраклы рәвештә табылган акча хәзинәсенә юлыктык (аны Мазиково авылыннан бульдозерчы егетләр яңа юл төзегәндә актарып чыгарганнар). Хәзинә 25 меңнән артык көмеш дирһәмнән — жужи, ягъни Алтын Урда акчаларыннан тора. Бу — моңарчы дөньяда билгеле булган шундый хәзинәләрнең иң зурысы. Андагы акчалар 1380 елларда Туктамыш хан исеменнән Сарай әл-Җәдид (Сарай-Бәркә), Сарай яки Сарай әл-Мәхрүс (Сарай-Бату), Азак, Урда, Урда әл-Җәдид, Харәзем, Кырым, Кырым әл-Җәдид, Хаҗитархан, Сарайчык, Мажар шәһәрләрендә сугылганнар. Күрәсез, монда Алтын Урданың төрле олыс-өлкәләрендәге иң мөһим цивилизация үзәкләре. Кыскасы, бөтен илнең икътисади хәләте ныгый, тотрыклана.

1380 елда, хакимияткә килү белән, Туктамыш акча реформасы уздыра. Бу — 1310 елдагы Үзбәк ханның акча алыштыруыннан соң үткәрелгән икенче зур реформа. Нәкъ 70 ел элек эшләнгән кебек үк, бөтен иске акчалар гамәлдән чыгарылып, өр-яңалары әйләнешкә кертелә. Ә аларны сугу өчен көмешкә бердәм үлчәү берәмлеге билгеләнә. Шуны истән чыгармаска кирәк, бу эш дәүләтнең барлык акча сугу үзәкләрендә дә башкарыла, ә аларның саны исә утыз икегә житә. Алтын Урда тарихының зур белгече, археолог һәм нумизмат Г. А. Федоров-Давыдов раславынча, XIV йөзнең 80—90 елларында сугылган акчаларның 60—100 процентын Туктамыш акчалары тәшкил иткән. Аңлашылса кирәк, бу эшләрне башкару өчен экономик куәтнең житәрлек дәрәҗәдә булуы мәҗбүри. Бу сезгә инфляция батгагына чумган бүгенге Рәсәйнең чиксез санда кәгазь («агач!») акчалар «штамповать» итеп ятуы түгел, ә ил байлыгына нисбәтле көмеш акча сугу! Һәм бу эшләр зур ихтыяр көченә ия булган, тәвәккәл, зирәк татар ханы Туктамыш тарафыннан эшләнә.

Шул чор татар аристократиясе Туктамышны «олуг хан», ягъни бөек хан дип бәяли, ә бу дәрәҗәгә элеккеге кодрәтле ханнар булган Үзбәк белән Җанибәк тә лаек булмаганнар. Дәүләттән читләрдә дә Туктамышның дәрәҗәсе шактый зур була. Без югарыда фарсы географы һәм тарихчысы Могыйнның Туктамышка биргән бәясе белән танышкан идек инде. (Элегрәк ул язма фәндә «Искәндәр



Каратун хәзинәсеннән бер уч акча — Туктамыш хан исеменнән Алтын Урда шәһәрләрендә сугылган көмеш дирһәмнәр. Аста, уң як почмакта — чагыштыру өчен бүгенге 1 сумлык акча

анонимы» дип мәгълүм иде, соңыннан аның авторының әлеге Могыйн икәнлеге ачыкланды: тулырак исеме Могыйнетдин Натанзи.) Аңа өстәп 1404 слда Сәмәркандта һәм Тимериләр дәүләтенең башка шәһәрләрендә дә булган,

Аксак Тимер турында бай мәгълүмат туплаган, хәтта берничә тапкыр аның үзе белән дә сөйләшкән Испания илчесе Рюи Гонсалес де Клавихо сүзләрен дә китерергә була. Клавихо Туктамышны «Тарталиянең императоры, кодрәтле һәм батыр кеше» дип атый, аны төрек солтаныннан да өстен куя. Аксак Тимер исә үзенең «Законнар җыелмасында» Алтын Урданы «Олуг татар иле» дип бәяли.

Мөхтәрәм укучыларда мондый сорау тууы ихтимал: ни өчен соң Аксак Тимер шундый бөек дәүләтнең бөек ханын җиңә алган? Мин мона каршы сорау куяр идем: ни өчен Александр Македонский, Аттила, Сәләхетдин, Чыңгыз һәм Бату ханнар, Александр Невский, Искәндәрбәк (Скандербег), Наполеон, Жуковлар җиңгәннәр, күбесе үзләренең гаскәрләреннән зур һәм яхшырак коралланган армияләрне тар-мар иткәннәр, ә кайберләре ярты дөньяны, тулы континентларны яулап алганнар? Моңа тәгаен генә җавап биреп буламы? Әлбәттә, юк! Яңа хәрби стратегия һәм тактика, полководецлык таланты, хәтта даһилыгы, гаскәр саны, алдынгы хәрби техника, халыкара хәлнең һәм эчке шартларның уңай килүе, тышкы сәясәттәге һәм хәрби разведкадагы мөмкин булган һәм булмаган чараларның (сатып алу, котыртулар, ялган дипломатия һ.б.) бөтенесен дә куллана алу... Шуларның һәммәсенең җыелмасы, хәтта берәрсенең өстенлек алуы гына да хәл иткән зурзур сугышларны.

1391 һәм 1395 елгы сугышларда татарларның җиңелүенең, югарыда санап үтелгәннәрдән тыш, тагын бер бик тә мөһим, хәтта хәлиткеч сәбәбен әйтергә кирәк. Алтын Урда армиясе үзенең төзелешендә һәм сугышны алып баруында Чыңгыз ханның элеккеге хәрби стратегиясен һәм тактикасын дәвам иттерә: флангларлардан, ике яктан иң яхшы атлы гаскәрләр белән дошманны әйләндереп алу һәм артына төшеп юк итү. Аксак Тимер исә көнчыгыш дөнья өчен әр-яңа хәрби алым куллана — үз гаскәрен ул җиде «кул»га бүлә (аларны соңыннан урыс тарих фәнендә корпуслар дип атыйлар): берәр «кул»ны ике флангка калдыра, дүртесеннән төп, хәлиткеч көчне ясаучы үзәк гаскәр төзи, соңгы жиденчесен резерв итеп тота. Туктамыш гаскәре ике яктан дошманны чолгап алырга өлгергәнче, Аксак Тимернең үзәк көче уртага бәреп керә һәм каршы якның сафын икегә бүлеп алып, кысрыклый баш-

лый. Соңгы, хәлиткеч һөҗүмне резерв ясый һәм сугыш, шулай итеп, дошман файдасына тәмамлана. Менә бу яңалык бөтен Шәрыкның шул замандагы иң зур армияләрен җиңүдә төп рольләрнең берсен уйный. Кызганычка каршы, Чыңгыз һәм Бату ханнарның заманында иң алдынгы саналган хәрби сәнгате XIV гасыр ахырына искереп өлгерә.

Татар тарихы чыганакларында һәм халык авыз иҗаты әсәрләрендә әйтелгәнчә, Аксак Тимернең шәһри Болгарны да җимерүе дөрес булса, Туктамыш, Каманы кичеп, тагын да төньяккарак күчкән булырга тиеш. Хәер, аның Казан артында булганлыгы хакында шундагы кайбер топонимнар сөйли, мәсәлән, Биектау, Балтач һәм Мамадыш районнарындагы аерым авыл һәм елга исемнәре.

1396 елда Туктамыш Кырымга килеп чыга һәм аны үз кулына төшерә, бу эштә аңа татарның атаклы Ширин нәселеннән булган кырымбәкләр ярдәм итәләр. Әмма бер елдан соң Алтын Урданың яңа ханы Тимеркотлык белән Идегәй Кырымга бәреп керәләр һәм Туктамышка каршы сугыш башлыйлар, җитмәсә, андагы татар аристократиясен үз ягына аудару максатында яшь хан аларга зур өстенлекләр бирә, яңа тарханлык ярлыклары өләшә.

Шулай итеп, Туктамыш Кырымда яклаучысыз кала һәм Киевка, Литваның бөек кенәзе Ватаутас (Витовт) янына килә. Янә бер елдан соң, 1398 елда, Днепрның сул кушылдыгы Бурсыклы (Ворскла) елгасы буенда бер яктан Витаутас белән Туктамыш, икенче яктан Тимеркотлык һәм Идегәй гаскәрләре арасында зур сугыш булып, Идегәйләр җиңә.

Туктамыш үзенең гаскәре белән Күк Урдага китә, аннан Себергә күчеп, Обь елгасына Чулым һәм Томь сулары кушылган җирдә зур гына олыс төзи. Татар тарихи чыганагы булган «Дәфтәри Чыңгызнамә»дә ул «Туктамыш йорты» дип атала («йорт» монда ил, дәүләт мәгънәсендә). Алтын Урданың үзәгендә, Идел йортта, хакимияткә кире кайтырга мөмкинлеге калмаган Туктамыш хан, шулай итеп, дәүләтне торгызуга әүвәл Кырымда, анда да булмагач, Себердә соңгы тапкыр талпыныш ясап карый. Шәрәфетдин Йәзди хәбәрләренә караганда ул, Аксак Тимергә илчеләр җибәреп, солых тәкъдим итә, һәм җиһангир: Кытайга яудан кайткач, Җуҗи олысын

янадан кулга төшерәм һәм аны Туктамышка кире кайтарам дип ышандыра. Әмма ул уйлар тормышка ашмый кала — 1405 елның башында Аксак Тимер үлә.

Тагын бер елдан, 1406 елның кышында, Туктамыш белән Идегәй арасында соңгы, 16 нчы сугыш була. Бу юлы Идегәй җиңелә, әмма ул бераз соңрак Туктамышның үз гаскәреннән читтәрәк вакытын туры китереп, аңа һөҗүм итә һәм үтерә. Бу хакта гарәпнең атаклы тарихчысы һәм сәяхәтчесе, XV йөз башларында Алтын Урдага сәяхәт кылган Ибне Гарәбшаһ хезмәтендә язылган.

Шулай итеп, заманында олуг дәүләтнең бөек ханы булган, үзенең бөтен сәләтен һәм дәртен Алтын Урданың иминлеген, көчен вә бердәмлеген арттыруга биргән, тик шул изге эштә дошманнары һәм үзенекеләр (татарлар!) тарафыннан чиксез зур каршылыклар һәм зыяннар күргән атаклы Туктамыш хан 60 яшен дә тутырмыйча, дәүләтен торгызырга соңгы талпыныш ясап, гадел көрәштә һәлак була. Татарның җан әрнеткеч, бәгырьләрне телгәләрлек, ачы, фаҗигале язмышы инде бу...

3. Идегәй

«Ул (Идегәй) кара кучкыл йөзле, урта буйлы, тыгыз һәм таза тәнле, батыр, куркыныч кыяфәтле, зур акылга ия, юмарт, ачык елмаюлы, тапкыр һәм зирәк кеше иде».

Ибне Гарәбшаһ. Аксак Тимернең биографиясеннән, XV йөз

Инде әйтелгәнчә, Аксак Тимер яулары нәтиҗәсендә Алтын Урдага чиксез зур зыян килә. Әмма әле бу дәүләтнең киң мәйданы, җимерелүдән сакланып калган күп кенә шәһәрләре, шулар арасында илнең беренче һәм соңгы башкаласы саналган Сарай-Бату исән була. Ниһаять, Алтын Урданың легендага әверелгән әүвәлге куәте, шөһрәте вә даны зур була. Менә шуларны торгызуда соңгы һәм уңышлы талпыныш ясаган кеше буларак, тарих мәйданына Идегәй килеп керә. Әйе, дастан вә риваятьләргә кергән, халыкның каһарман улына әйләнгән атаклы Идегәй — татарның зур сәяси һәм дәүләт эшлеклесе, талантлы гаскәр

башлыгы, әмма ифрат дәрәҗәдә каршылыклы һәм фаҗигале тарихи шәхес.

Идегәйнең гадәти булмаган шәхес икәнлеге аның турында югарыда эпиграф итеп китерелгән Ибне Гарәбшаһ сүзләреннән дә бик яхшы күренә. Чыгышы белән ул элеккеге монгол, соңыннан татарлашкан «мангыт» кабиләсеннән; кайбер чыганакларда «ак мангыт» дип тә атала. Мангытлар исә нугай татарлары килеп чыгышының этник нигезен тәшкил итәләр.

«Идегәй» дастанында Идегәйнең атасы Котлыкыя дип әйтелә. Әмма тарихи язма чыганак булган һәм югарыда телгә алынган «Мөнтәхәб әт-тәварих Могыйни»дә Идегәй Балтача улы дип атала, ә Могыйннан бераз гына соңрак язган фарсы тарихчысы һәм географы Хафиз Абру хезмәтендә ул Балынмак дип бирелә — бу шул Балтачаның варианты була («Котлыкыя» исә икенче бер охшашрак исем, мәсәлән, Орос ханның беренче улы Токтакыя белән буталган булырга мөмкин).

Балтача Орос ханның икенче улында, безгә таныш булган Тимермәликтә бәкләри бәк булып хезмәт итә. Туктамыш, Тимермәликне җиңгәч, Балтачага үз ягына чыгарга тәкъдим итә, әмма тегесе катгый рәвештә ваз кичә. Чыганакларда әйтелгәнчә, ул Туктамышка: «Әгәр дә миңа яхшылык эшләргә теләсәң, минем башымны кисәргә әмер бир»,— ди, һәм Балтача җәзалап үтерелә.

Әтисенең үтерелүе Идегәйгә бөтен гомере буена Туктамышка үчлек сакларга, алай гына да түгел, чын мәгънәсендә кан дошманына әверелергә нигез була. Әмма бу вакыйга Идегәйнең Алтын Урда ханына каршы булган сәясәтен билгеләүдә берләнбер сәбәп булмый. Чын сәбәп тирәндәрәк: үзендә зур сәяси сәләт барлыгын сизгән Идегәй дәүләт белән идарә итәргә омтыла, ләкин хан буларак түгел, чөнки Җүжи нәселеннән килмәгәнлектән, аның тәхеткә утырырга хакы булмый. Идегәй «таҗсыз хан», ягъни күндәм ханнарны тәхеткә утыртып, Алтын Урданың чын хуҗасы булырга ниятләнә. Әлбәттә, үзе дә зур сәяси көчкә ия булган, җитмәсә, шәхси дошманына әйләнгән Туктамыш һич кенә дә бу эшкә ярамый.

Идегәйнең Алтын Урда ханына үз кандидатурасы була: ул да булса — аның сеңлесенең улы Тимеркотлык, ә аның исә Сарай тәхетенә бөтен хакы бар, чөнки ул — Җүжи

нәселеннән булган Тимермәликнең улы (аңлашылса кирәк, Идегәйнең сеңлесе Тимермәликнең хатыны, ханбикә була). Бу вакытта әле Идегәй — Урта Азиядә, Аксак Тимер янында: Туктамыш кебек, ул да Орос ханнан куркып Сәмәркандка качып китә, аны да Аксак Тимер бик җылы каршы ала. Ник дисәң, монысын да киләчәктә Алтын Урдага каршы көрәштә файдаланмакчы була. Җиһангирның теләге башта тормышка аша сымак: 1391 елда Туктамышка каршы булган сугышта Идегәй аңа ярдәм итә — ул, Тимеркотлык һәм аның энесе Күнҗә углан (ханзадә) Аксак Тимер ягында гаскәр башлыклары һәм Алтын Урдага юл күрсәтүче сыйфатында катнашалар.

Сугыш тәмам булып, Тимерләнк үз иленә кайтып киткәч, Идегәй Тимеркотлык белән Идел-Җаек буенда калалар (Күнҗә генә җиһангир белән китә, ләкин ул да соңыннан Алтын Урдага кайта, хәтта 1395 елгы сугышта Туктамыш ягында гаскәр башлыгы буларак катнаша; димәк, аның юлы элекке дусларыннан аерыла). Тимеркотлык та башта Аксак Тимергә кушылмакчы булып, татар җирендә гаскәр туплый башлый, тик Идегәй аңа бу эшнең Алтын Урда өчен хыянәт эшләү икәнлеген аңлата. Тимеркотлык үзенең гаскәре белән Идел-йортта, Идегәй ягында кала. Аксак Тимер исә, Идегәйнең аны алдаганын аңлап, аның янына илчеләр җибәрә һәм кире кайтуын таләп итә, әмма Идегәй аның әмеренә буйсынмый һәм бөтенләйгә Алтын Урдада кала.

1395 елда Аксак Тимер, бигрәк тә 1398 елда Идегәй тарафыннан җиңелгәч, Туктамышның Сарай хакимиятенә кире кайту мөмкинлеге бөтенләй бетә, җитмәсә, шуннан бер генә ел элек, ягъни 1397 дә, Идегәй Тимеркотлыкны Алтын Урда ханы итеп куйган була. Бурсыклы елгасы буендагы сугышта Идегәйнең хәрби таланты бөтен тулылыгы белән ачыла һәм Алтын Урдада аның чикләнмәгән хакимлеге башлана. Тимеркотлыктан соң (1397—1399) тәхеткә утырган Шадыбәк (Күнҗәнең улы, 1400—1408) һәм Булатсолтан (Шадыбәкнең улы, 1408—1411) Идегәйнең сәясәтен үткәрүче шундый ук күндәм ханнар булалар.

Менә шушы 15 еллык (1397—1411) вакыт — Идегәйнең Алтын Урда белән тулысынча идарә иткән чоры. Аның сәяси һәм хәрби осталыгы искиткеч югарылыкка ирешә һәм нәкъ менә Идегәй җитәкчелегендә Алтын Урда дәү-

ләте үзенең куәтен кире кайтарырга җитди талпынып ясый. Җитмәсә, 1405 елда Аксак Тимер үлеп китә һәм аның варисларына татар иленең әлләни кирәге калмый — аларга үзләренең дәүләт эшләрен хәл итәргә кирәк була. Шулай итеп, Җуҗи олысының дөньякүләм дәрәҗәсен күтәрергә кабат мөмкинлек ачыла, һәм ул эшне Идегәй шактый уңышлы башкара.

1409 елда ул Мәскәүгә хәрби поход оештыра. Хәер, ул вакыйга урыс тарих фәнендә, гадәттәгечә, артык күпертелеп күрсәтелә; татарларның вәхшиләрчә, канлы һөҗүме дип бәяләнә. Чынында исә Идегәй Мәскәүне камап кына ала, тик Урда тәхетенә яңа дәгъвачы барлыкка килгәнен ишетеп, урыслардан өч мең сум йолым (выкуп) ала да кире Сарайга кайтып китә. Бу хакта урыс елъязмаларында әйтелә. Ә менә шул чорларны яктырткан гарәп-фарсы чыганакларында Идегәйнең Мәскәүгә явы турында бер сүз дә юк. Шуңа күрә, әлеге поход мәсьәләсе шактый ачык булып кала.

Мәскәү белән мөнәсәбәттә Идегәйнең мөһим уй-планнары була, ул да булса — Алтын Урдага каршы урыс-литва берлегенең оешуына комачаулык итү. Бу эшне Идегәй шактый оста башкара һәм монда аның икенче бер — дипломатик сәләте калкып чыга. Бу эштә Идегәй җитәрлек дәрәҗәдә хәйләкәрлек күрсәтә. Юкка гына урыс елъязмаларында ул: «Идегәй бөтен Урданың бөек кенәзе, кодрәтле, нык һәм бик тә батыр кеше» дип аталмый. Шунда ук аның хәйләкәр һәм мәкерле («лукавый и злохитрый») кеше икәнлеге дә әйтелә. Бу гаҗәп тоелырга тиеш түгел, чөнки күп кенә атаклы дәүләт эшлеклеләре үз илләренең көч-куәтен арттыру максатында сәяси, хәрби һәм дипломатик көрәшнең барлык мөмкин булган вә булмаган чараларын да кулланганнар (һәм бүген дә кулланалар).

Идегәйнең оста дипломат булуы Тимериләр белән ике арадагы мөнәсәбәтне җайга салуда да бик яхшы күренә. 1409 елда анда хакимияткә Аксак Тимернең улы Шахрух килә һәм Сәмәрканд белән аерым идарә итүне үзенең улы Олугбәккә тапшыра — соңгысы Шәрыкның бөек астрономы һәм мәгърифәтчесе буларак мәгълүм. Идегәй тарафыннан җибәрелгән илчелек Урта Азиянең шушы прогрессив дәүләт эшлеклеләре белән уңышлы сөйләшүләр алып бара. Нәтиҗәдә Алтын Урда белән Мәвәраннәхр арасындагы

элеккеге киеренкелек бетерелә, җитмәсә, Аксак Тимер тарафыннан әле 1387 елда ук вәхшиләрчә җимертелгән Харәзем, өлешчә торгызылып, Алтын Урдага — аның көнчыгыш өлеше булган Күк Урдага кире кайтарыла.

Әмма 1411 елда Сарай тәхетенә Тимеркотлыкның улы Тимер утыргач, Идегәйнең хакимлегенә чик куела. Бу углан да дәүләт тажын Идегәй кулыннан ала, әмма үзенең хуҗасына, җитмәсә, олы агасына буйсынмый, мөстәкыйль идарә итә башлый. Тик ул икенче елны ук ни сәбәптәндер үлеп китә, һәм тәхеткә бер-бер артлы Туктамышның уллары — Җәләлетдин, Кәримбирде, Кәпәк, Җәгъфәрбирде утыралар. Әлбәттә, алар Идегәйгә каршы ачыктан-ачык көрәш башлыйлар. Идегәй башта Харәземгә, аннан Кырымга китә һәм үзенең шактый какшаган властен беркадәр торгыза ала. Әмма әле кайчан гына чиксез хакимият белән файдаланган шушы кодрәтле шәхеснең кояшы байый, дан йолдызы сүнә.

Идегәйнең соңгы сугышы Туктамышның улы Кадыйрбирде белән 1419 елда Җаек буенда, Нугай Урдасының башкаласы Сарайчыктан ерак түгел җирдә үтә. Бу коточкыч сугыш була. Кадыйрбирде үзе үлсә дә, аның якыннары 67 яшьлек Идегәйне кисәкләргә тураклап ташлыйлар. Шулай итеп, урта гасыр татар дөньясының серле һәм искиткеч каршылыклы, зур шәхесе һәлак була. Аның татар ханы Туктамышка булган кан дошманлыгы, ул гына да түгел, мин-минлеге Алтын Урданың язмышы хәл ителгән җаваплы бер вакытта сәяси зирәклектән өстенрәк булып чыга. Үзенең әүвәлге, яшьлек ялгышларын Идегәй, бәлки, аңлагандыр да... Җимерелеп барган дәүләтнең элеккеге куәтен арттыру эшендә ул искиткеч зур тырышлыклар куя, әмма... соң була!

Идегәйнең тормышы һәм үлеме бик тә гыйбрәтле. Ул кодрәтле һәм җиңелмәс полководец була. Дәһшәтле орышларда ятларны да һәм, аянычка каршы, үзенекеләрен дә кыра. Әйе, әйе, үзенекеләрен — татарларны да: ул аларны, ялгышып, дошманнары дип уйлый һәм алар белән гомере буе сугыша. Бер яктан, бөтен татарның уртак дәүләте булган Алтын Урданы торгызуга күп көч куйса, икенче яктан, ирексез рәвештә, аның таркалуына зур өлеш кертә. Идегәй — кодрәтле дә, фаҗигале дә шәхес. Нәкъ менә та-

тарның үзе, аның олуг дәүләте Алтын Урда кебек үк, кодрәтле вә фаҗигале...

ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елгы мәгълүм карары белән тыелган «Идегәй» дастаны соңгы елларда татар һәм урыс телләрендә басылып чыккач, без бик куандык. Һәм дөрес тә, дастанның дөньяга чыгуы бик тә кирәкле эш булды. Татар халкы үзенең олуг вә гыйбрәтле тарихының мөһим бер дәверен кире үзенә кайтарды. Әмма эйфориядән арынып, без ул бөек һәм катлаулы шәхеснең бөтен ягы турында да дөреслекне белергә тиешбез. Җитмәсә, дастанда Идегәй тормышы һәм эшчәнлегенең бер өлеше — аның Туктамыш белән мөнәсәбәте генә яктыртылган һәм, әйтергә кирәк, берьяклы яктыртылган (үткән ел гына Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында куелган «Идегәй» спектаклендә дә тарихи-сәяси һәм тарихи-этник хаталар тулып ята. Бу мәсьәлә икенче мәкалә язуны таләп итә).

Немецның бөек философы Гегель: тарих кешеләрне, кызганычка каршы, бернигә дә өйрәтмәде, дип язды. Идегәйнең ачы язмышы бүген безне, татарны, үзебез турында бик тә җитди итеп уйланырга мәҗбүр итә. Берничә йөз ел буена безне кара, империячел көчләр дә басып торды, әмма үзебез дә хөсетлек (көнчелек) һәм кинәлек (үчлек) аркасында, бердәмлек булмау нәтиҗәсендә бер-беребезгә каршы көрәштек. Җитәр, татарлар! Безнең мең ярым елдан артык, ягъни VI йөзнең уртасыннан ук башланган һәм күпләргә, хәтта «бөек» халыкларга насыйп булмаган дәүләтчелек тарихыбыз бар. Ул тарих — дөньякүләм мөһим сәяси вакыйгаларга, олы һәм данлыклы шәхесләргә, зур үсешкә ирешкән матди вә рухи мәдәнияткә бай тарих. Бу — безнең катлаулы һәм бөек үткәнебез дә, киләчәккә булган олуг өметебез дә. Бүген кара көчләр башка милләтләргә каршы көрәш башлаган шомлы бер дәвердә безгә үзебезнең тарихыбыздан сабак та, үрнәк тә алып, Тукай әйтмешли, «бер җан, бер тән булып» берләшергә кирәк!

«Ватаным Татарстан»,
1995, 3, 18 февраль.

ТАТАР ХАЛКЫ ҺӘМ ТАТАРСТАН ТАРИХЫНДАГЫ ИҢ ӘҺӘМИЯТЛЕ ДӘВЕРЛӘР, ВАКЫЙГАЛАР, ТАРИХИ ШӘХЕСЛӘР

Безнең эрага кадәр 100—75 меңьеллыклар — Идел буена һәм бүгенге Татарстан җиренә беренче борынгы кешеләрнең килеп утыруы.

Безнең эрага кадәр IX—III йөзләр — Көнчыгыш Европа һәм Идел-Кама буйларының иң атаклы археологик культураларыннан булган Ананьино культурасы дәвере.

Безнең эраның IV—VIII йөзләре — төрки кабиләләргә кагылышлы Имән Кискә культурасы чоры.

375 ел — дөньядагы иң зур төрки кабиләләр саналган сөннәр (һуннар) берләшеп, Иделдән Рейн елгасына кадәрге җирләрне биләгән зур империя төзелү. Империянең иң кодрәтле җитәкчесе — Аттила (434—453 елларда идарә итә).

552—745 еллар — Төрки каханлыгы яшәгән еллар. VII гасыр башыннан икегә бүленеп, Көнчыгыш Төрки каханлыгы халкының зур өлешен борынгы татар («утуз татар», «тукуз татар») кабиләләре тәшкил итә.

632 ел — 650 еллар башы — Азов диңгезе буенда Кубрат хан җитәкчелегендә Бөек Болгар дәүләте яшәгән дәвер.

650—965 еллар — Хәзәр каханлыгы чоры.

VIII—X йөзләр — Көнбатыш Себердә борынгы татар кабиләләре җитәкчелегендә төзелгән Кимәк каханлыгы заманы.

IX йөз ахыры — X йөз башы — Идел буенда Болгар дәүләте төзелү.

922 (һиҗри белән 310) ел — Болгар илендә Алмас би (эльтебер-илтабар) җитәкчелегендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителү.

1236 ел — Болгарның монгол гаскәрләре тарафыннан басып алынуы һәм мөстәкыйль дәүләт буларак яшәүдән туктавы[1].

1243 ел башы — татарның бөек дәүләте Алтын Урда (Җуҗи олысы) төзелү. Дәүләтнең иң атаклы ханнары: Бату (1243—1255), Бәркә (1256—1266), Үзбәк (1312—1342), Җанибәк (1342—1357), Туктамыш (1380—1396), Олы Мөхәммәт (1422(?), 1424—1438); кодрәтле әмирләре — бөек мирзалары: Нугай, Мамай, Идегәй (соңгысының яшәгән еллары 1352—1419).

1380 ел, 8 сентябрь — Алтын Урда белән Рус дәүләте арасындагы Куликово сугышы.

1420—1430 еллар — Нугай Урдасы оешу.

1430—1440 еллар — Алтын Урданың таркалуы.

1429—1598 — Себер ханлыгы яшәгән еллар.

1434—1502 — Олы Урда (Бөек Урда) яшәгән еллар.

1443—1783 — Кырым ханлыгы яшәгән еллар.

1452—1681 — Касыйм ханлыгы яшәгән еллар.

1459—1556 — Әстерхан ханлыгы яшәгән еллар.

1445 ел, 1 (14) октябрь — Казан ханлыгы оешу.

Дәүләтнең иң атаклы ханнары: Мәхмүтәк (1445—1465), Ибраһим (1467—1479), Мөхәммәтәмин (1487—1497, 1502—1518), Сафагәрәй (1524—1549); зирәк ханбикәләре: Нурсолтан һәм Сөембикә; бөек кенәз-карачылары: Булат һәм Нурали Шириннар, олуг сәет һәм шагыйрь Колшәриф.

---

[1] Болгар дәүләте башлыкларының династияләре хакында төгәл тарихи мәгълүматлар юк.

1506 ел, 25 июнь (8 июль) — 60 меңлек татар гаскәренең 100 меңлек урыс гаскәрен тар-мар итүе.

1551 ел, 11 (24) август — Сөембикәне улы Үтәмешгәрәй хан белән Мәскәүгә әсирлеккә алып китү.

1552 ел, 2 (15) октябрь — Казан шәһәре һәм ханлыгының Иван Грозный (Явыз Иван) армиясе тарафыннан яулап алынуы.

1556 ел — Сөембикәнең туганы, Нугай бие Гали Әкрам җитәкчелегендә Казан ханлыгын торгызуның уңышсызлыкка очравы.

1615—1619 еллар — Җангали җитәкчелегендә татарның милли-азатлык көрәше.

1670—1671 еллар — татарларның Степан Разин восстаниесендә азатлык өчен көрәшүе.

1708 ел — Казан губернасы төзелү.

1755 ел — Батырша җитәкчелегендә татарның милли-азатлык көрәше.

1774 ел 12 (25) июль — Пугачевның Казанны алуы.

1804 ел — Казан университеты ачылу.

1886 ел, 13 (26) апрель — 1913 ел, 2 (15) апрель — татар халкының даһи шагыйре Г. Тукай туган һәм үлгән көннәр.

1905—1907 еллар — татарда милли-азатлык хәрәкәтенең яңа, зур күтәрелеш чоры. Хәрәкәтнең җитәкчеләре, татар халкының бөек шәхесләре: Исмәгыйль Гаспралы (1851—1914), Рәшит Ибраһимов (Рәшит Казый, 1852—1944), Галимҗан Баруди (1857—1921), Риза Фәхретдинов (Риза Казый, 1859—1936), Габдулла Буби (1871—1922), Муса Биги (1875—1949), Йосыф Акчура (1876—1935), Гаяз Исхакый (1878—1954), Садрый Максуди (1879—1957).

1905—1906 еллар — Бөтенроссия мөселман съездлары (3) үткәрелү.

1905—1914 — «Иттифак эл-Мөслимин» партиясе яшәгән еллар.

1917 ел — татарда милли-азатлык хәрәкәтенең яңа этабы, Бөтенроссия мөселманнарының яңа съездлары үткәрелү (Мәскәү, 1—11 май; Казан, 21—31 июль).

1917 ел, декабрь — Уфа шәһәрендә Милләт Мәҗлесе үткәрелеп, «Идел-Урал штаты» төзелү (1918 елда большевиклар тарафыннан таркатыла).

1920 ел, 27 май — Татарстан АССР төзелү.

1990 ел, 30 август — Татарстан Республикасының (Татарстан ССР) суверенлыгы игълан ителү.

1991 ел, июнь — Татарстан Республикасының беренче Президентын (М. Ш. Шәймиев) сайлау.

1992 ел, 21 март — Татарстан Республикасының бәйсез дәүләт булып яшәү кирәклеген раслап, Татарстанда бөтенхалык референдумы үткәрелү.

1992 ел, 6 ноябрь — Татарстан Республикасының Конституциясе кабул ителү.

ЭЧТӘЛЕК

I. Мәдәният һәм сәнгать

Кичке азан 5
Туган як тегермәннәре 23
«Үпкәнеңнән бирле, әнкәй...» 30
Халык көйләре һәм Илһам Шакиров 37
Бер рәсемнең тарихы 48
Матурлыкка йөз белән 50
Хәтер 55
Күңелемдә җылы хисләр 62

II. Тарих һәм заман

Борынгы Сарайга сәяхәт 70
Болгар шәһәрләре буйлап 76
Борынгы Болгарда ислам дине кабул ителүгә 1100 ел 83
Айсолтаннар илендә 88
Ташлар һәм тарихи мирас 97
Сөембикә манарасы 106
Хәтеребезне яңартыйк 120
Без — бер халык 125
Алтын Урда һәм татар тарихы 135
Бердәмлектә — көч 146
440 елга сузылган инкыйраз 154
Әстерханга барсаң... 171
Җиребезнең алтын уртасы 175
Фаҗигале тарихның сөекле хәтере 182
«Бөек» Рәсәйгә баш иярбезме? 188
Аксак Тимер, Туктамыш һәм Идегәй 201
Татар халкы һәм Татарстан тарихындагы иң әһәмиятле дәверләр, вакыйгалар, тарихи шәхесләр 221

Научно-популярное издание

Равил Габдрахманович Фахрутдинов

ВЕЧЕРНИЙ АЗАН

(На татарском языке)

ИБ № 6663

Редакция мөдире *С. Шамси*
Мөхаррире *К. Миңлебаев*
Рәссамы *И. Азимов*
Бизәү мөхаррире *Д. Җәләлетдинов*
Техник мөхаррире *Ф. Кәбирова*
Корректоры *Г. Мусина*

Җыярга тапшырылды 13.09.96. Басарга кул куелды 17.06.97. Форматы $84 \times 108\ ^1/_{32}$.
Типогр. кәгазе № 2. «Тип Таймс» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 11,76.
Шартлы буяу-оттиск 12,18 Нәшер-хисап табагы 12,73. Тиражы 5000 экз. Заказ Е-474.

Татарстан китап нәшрияты. 420111, Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111, г. Казань, ул. Баумана, 19.

Татарстан газета-журнал нәшрияты типографиясе
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.